1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

№ 11 / 2022

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

рәнҗемә миңа, КЫЗЫМ

«СТРАУС ХАЛӘТЕ» ***чынбарлыктан*** *качу*

баланнарга *бал керде* БАЛАН БӘЛЕШЕ

Ленара МОЗАФФАРОВА:

«Кеше өчен иң кадерле нәрсә – вакыт».

PRESSA

Әниемнең туй күлмәге...



Әниемнең туй күлмәге...
Сезнең гаиләнең матур
бер ядкаре.
Кадерле кешегезнең
яшьлегеннән бер кайтаваз.
Аның иң бәхетле бер көненең
шаһиты.
Сакланамы ул сездә?
Аны кулга алгач, йөзе балкып
киткән әниегез нәрсәләр искә
төшерә, нинди истәлекләр
сөйли?
Бездә яңа проект: әниегезнең
туй күлмәген киеп көзге
алдында бөтерелгән
мизгелне сурәтләгән
фотосурәтләрегезне көтәбез.
(«Минем кыз чагым син,
кызым!» – дип әйтәдер
әниегез сезгә карап.
Яратып, сөенеп, аз гына
моңсуланып...)
Тагын – аларның туй көненнән
бер мизгел дә көтәбез!

Әтием белән әнием бер авылдан булганга күрә, бер-берсен яхшы белгәннәр. Туйда бөтен гореф-гадәтләр үтәлгән: килен төшкәч, мендәргә басып бусагадан атлап керү; бал-май, ипи каптыру; киленгә су юлы күрсәтү. Туйга йөз кунак килгән, ишегалдында җырлап-биеп, таң атканчы бәйрәм иткәннәр.
Туй күлмәген мәҗлескә кадәр кияүгә күрсәтергә ярамый, диләр. Минем әти-әни аны икесе бергә барып сайлап алган. Киләсе елга бергә гомер итүләренә 25 ел була. Әниемнең туй күлмәге заманы өчен бик кыйммәтле, затлы булган. Шуңа күрә аны әнидән соң да берничә кеше киеп, гаилә тормышын башлап җибәргән. Шөкер, бар гаиләләр дә матур тормыш итәләр. Күлмәге бәхетле булган, күрәсең.

Илгизә ГАЛИУЛЛИНА.
Зәй районы Югары Мәлем авылы.
Фото: Анна АРАХАМИЯ.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2022



Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зәлия Ахунова, Ирада Әюпова,
Зилә Вәлиева, Гөлүсә Батталова,
Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова,
Альбина Насыйрова, Алсу Нәбиева,
Сәрия Сабурская, Гүзәл Сәгыйтова,
Нурия Һашимова, Рафаэль Шәвәлиев.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Баш мөхәррир урынбасарлары 222-09-78
Мәликә Әсәтуллина
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Алсу Шакирова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррире
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Рекламаның эчтәлеге (фото, текст) аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Ленара Мозаффарова
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Лилия Гәрәева
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Павел Фадеев

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 26.10.2022 ел.
Чыгу көне: 2.11.2022 ел.
Заказ О-3212
Тираж 8331

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: ПО279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+

27 НОЯБРЬ — ӘНИЛӘР КӨНЕ



Фото: Рушан Хәялиев

Баш мөхәррир сүзе



Журнал битләрендә узган «Фотообъективта – әни» проектын укучыларыбызның күбесе, мөгаен, хәтерлидер әле. Бәйгегә килгән ул фотосурәтләрдән без соңрак күргәзмә оештырдык. Аның ачылышы вакытында бер журналист миңа сорау бирде: «Сезнең өчен әни нәрсә ул?»
Дөресен әйткәндә, югалып калдым... Төгәл җавап та бирә алмадым. Чыннан да, минем өчен Әни ул нәрсә?..

Быел олы кызыбыз тәүге мәртәбә әни булды. Дүртебез – мин, ирем, кызым һәм әле дөньяга килгән оныгыбыз – бүлмәдә үзебез генә калгач, кызым яшь тулы күзләре белән карап: «Сезнең мине ничек яратканыгызны әле генә аңладым», – дип әйтте. Әйе, Әни ул – бу дөньяда бернәрсә белән дә үлчәргә мөмкин булмаган ЯРАТУ...

Үсмер балаң сине ишетмичә, дөресрәге, ишетергә теләмичә, бүлмә ишеген шап итеп ябып кереп киткәндә дәшми калу... Димәк, ТҮЗЕМЛЕК...

Тагын... «Ялкын» журналының рәссамы Зифа Мөхәммәтҗанова бердәнбер кызының чит илгә кияүгә чыгуын бик авыр кичерде. Бер катта эшләдек, редакцияләребез янәшә иде ул чорда. Бүлмәбезгә кереп: «Без – әниләр – җәя, ә балалар – ук. Табигать законнары шулай корылган: аларны үзебез үк атып җибәрәбез. Берәүләрнеке якынга гына төшә, икенчеләрнең угы еракка-рак оча, шунда тамыр җибәрә», – дип әйткәне әле һаман да истә. Үзен тынычландырыр өчен дә сөйләгәндер. Күпме КӨЧ һәм ЗИРӘКЛЕК Әниләрдә...

Әниләр гомер-гомергә САБЫРЛЫК үрнәге булды. Кызганыч, бүген бу сүзгә яңа төсмерләр өстәлде. Улларын озатучы Әниләрнең сабырлыгы башка...

Әни ул АКЛЫК, ПАКЬЛЕК һәм ДОГА... Бик күп дога!

Барлый башладым да туктап калдым... Юк, мөмкин эш түгел бу. Барысын да санап чыгу, дим. Аннан бу сорауга һәркемнең җавабы үзенекедер...

Яратып,
Лариса МАЛИКОВА

Безнең тышлыкта

«Уңышларымның сере тагын шундадыр: «Күп функцияле үзәк» директоры булырга беркайчан ашкынмадым. Максатым – кул астындагы хезмәткәрләремнең эш урынын саклап калу иде бит. Ихлас иде бу теләгем!»

10

Тәрәзә
Гөлнур Хәсәншина

14



Тәрбиядә идеальлеккә омтылырга кирәкми икән!
Чулпан Галиәхмәтова

16



Очкычларга канат куйганда
Алсу Шакирова

24



Үкенечле язмыш
Тәэминә Биктимирова

Заман һәм без

Сынау — 6
Чулпан Галиәхмәтова

Татар дөньясы

Кодагыйлар да бер уйда — 20
Фәния Насыйхова

Ата-ана догасы — 27
Рөстәм хәзрәт Хәйруллин

Мәдәни тормыш

Саумы, сары канатлы җил! — 28
Хәйдәр Гайнетдинов

Авазларым – сары кыңгырау — 29
Наилә Яхина

Китап акылны тәрбияли — 34
Гөлнур Сафиуллина

Яшәеш

Колхоз кызы Әлфия — 40
Лилия Гәрәева

«Башын комга батыра...» — 43
Гүзәл Хисмәтуллина

«Рәнҗемә миңа, кызым...» — 44
Мәдинә Авзалова

Таулар иленә сәфәр — 52
Гөлназ Хөҗҗәтова

Хуҗабикә

Игътибар үзәгендә – миңнәр — 56

Кичке алтыдан соң... — 58


Кытай кызларының матурлык сере — 59

30



«Кичер мине, әни!»
Разит Сибатов

48



«Мөхлисә апа, чыгып ал!»
Эльмира Закирова

60



Балан бәлеше
Айгөл Мөбарәкшина тәкъдим итә

»

СЫНАУ



Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

Көтеп яши торган вакыйга түгел иде бу. Бөек Ватан сугышы ачысын үз йөрәге белән тойган әби-бабаларыбызның бердәнбер теләге «Дөньялар гына тыныч булсын!» иде. XXI гасырда нинди сугыш инде, цивилизациянең югары ноктасына җиттек, варварлар кебек бер-беребез өстенә мылтык күтәреп чабып йөри торган заман түгел, монда яңа мәдәният, яңа технологияләр, барысы да өстәл артына утырып сөйләшүләр белән хәл ителә торган чор дип, аларның бу ихлас теләкләрен без, яшь буын, самими, хәтта беркатлы дип бәяли идек. Әмма уйлап карасаң, без уйлаган цивилизация җәмгыятьтә юк исәбендә икән бит. Замана технологияләре белән дан тоткан, бөтен дөнья (шул исәптән, Россия дә) сокланган Америка Кушма Штатлары инде ничә илнең тынычлыгын алды, Израиль һаман Газ секторына һөҗүм итеп тора. Әлеге илләрдәге вазгыять бездән ерак торганга, күпләр бу хакта уйланмады. Кызганыч, әмма дөньяда хәрби бәрелешләрнең туктаганы юк. Донецк һәм Луганск Халык Республикаларында килеп туган вазгыять сигез ел буе тыныч юл белән хәл ителә алмаганлыктан, Россия быел 24 февральдә махсус хәрби операция үткәрү турындагы карар кылырга мәҗбүр булды. Илнең яңа тарихында беренче тапкыр өлешчә мобилизация игълан ителде. Хәрби хезмәттә булганнарны, запастагы хәрбиләрне җыя башладылар. Халыкның тормышы хәрби операциягә кадәр һәм аннан соңга бүленде. Халык үзе үзгәрде. «Илгә килгәнне ил белән күтәрәсең инде. Кирәк булгач, барасың» дигән фикерләр дә, «Мин – патриот, әмма хакимият белән килешмим», – дип, биштәрен асып илдән чыгып китүчеләр дә бар. Язылачы язма кемнең хаклы булуын, кемнең ялгышуын ачыклау турында түгел. Һәр кешенең үз дөреслеге. Әмма шуны онытмасак иде: Ватаныбыз берәү генә, без шушы илдә яшибез, тамырларыбыз шушында һәм башка Ватаныбыз юк. Шуңа күрә дә илнең бөтенлеге саклану – үтә дә зарур.

Әлеге язма ил игълан иткән хәрби операциянең халыкны ничек үзгәртүе хакында. Беренчедән, соңгы 20 елда онытылып барган патриотизм рухы күпләр өчен кире кайтты. Икенчедән, кешеләр арасында бер-берсенә карата ярдәмчеллек көчәйде. Хәрби операциягә киткән егетләргә теләктәшлек күрсәтү, ярдәм итү очраклары көннән-көн арта. Матбугат битләрендә уңышка ирешүчеләрне, йолдыз дип саналган җырчыларны яңа геройлар – бүгенге көннең чын геройлары алыштыра.



«Без булмасак, кем?..»

Капитан Раил Гайнетдинов, **өлкән лейтенант Рафил Гайнетдинов**, кече сержант Искәндәр Гайнетдинов.

«Улларыгызның язмышын хәрби хезмәт белән бәйләгәнегезгә үкенмисезме?» – дип сорыйм Балтач районы Түбән Субаш авылында гомер итүче Фәгыйль абый белән Гүзәлия ападан. «Үкенмибез, алар чын ирләр булып, үз вазыйфаларын үтиләр ич инде. Үзләре дә: «Без дә сакламасак, кем саклар сезне», – диделәр. Илне элек-электән ирләр саклаган. Бу – аларның бурычы. Ә безнекеләрнең илне саклау – һөнәрләре. Улын хезмәткә озаткан әти-әниләргә сабырлык бирсен. Уллары исән-имин кайтып, шатланып-куанышып күрешсеннәр. Илләр тыныч булсын», – ди герой егетләрнең әти-әнисе.

Алар гаиләсендә биш бала үскән. Бишесе дә спорт белән «җенләнгән». Башкача мөмкин дә түгел, әтиләре Казан педагогика институтында физкультура, хәрби укытучы һөнәрен ала. Авылына кайтып, мәктәптә укыта башлый, запастагы өлкән лейтенант. Ул вакытта Субаш мәктәбе спорт буенча иң көчле мәктәпләрнең берсенә әйләнә. Спорт белән янып яши Фәгыйль абый. Мәктәп укучыларын гына түгел, авыл яшьләрен дә тарта. Малайлары ярышларда беренчелекне бирми, нык булып үсә. Олы улына Казан танк училищесына керергә әти кеше үзе тәкъдим итә. Куәтле Союз таралып, Россиядә кыйммәтләр үзгәргәннән соң, кабат офицерларга йөз белән борылган чак. Раил бернинди авырлыкларсыз имтиханнарын тапшырып курсант була. Раилдән соң туган икенче уллары Рафил спортта үтә көчле булуына карамастан: «Абый янына барам», – дип, ике елдан соң танк училищесына укырга керә. Кызыл дипломга тәмамлаган яшь офицер Раилне башта Новосибирскига, аннан Таҗикстанга җибәрәләр. Рафил тагын абыйсы артыннан китә. Өченче уллары Искәндәр Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясен тәмамлап, хәрби хезмәт үтәргә абыйлары янына китә һәм контракт белән хезмәт итүче хәрбигә әйләнә. Анда хезмәт иткәннән соң, Раилне – Чиләбе өлкәсенә, Рафилне – Самарага, хәрби туризм белән шөгыльләнүче Искәндәрне Тольяттига кайтаралар. «2006 елдан, Раил танк училищесына кергәннән бирле хәрби тормыш, солдатлар тормышы белән яшибез», – ди әниләре Гүзәлия апа. Уллары турында сөйләгәндә дә, кайда нинди хәрби часть – барысының да саннарын әйтеп сөйләшә. Аларның илне саклау һөнәрен сайлаганнарын аңлый, шуңа күрә дә уллары кайда гына булса да, догасыннан ташламый. Ә хәрби егетләрнең тормышларында куркыныч вакытлар да күп була. Таҗикстан да куркынычсыз урын түгел түгелен, Раил белән Рафил Сириягә командировкага киткәндә аеруча борчыла ана. Ут эченә китәләр бит! Андагы бәрелешләрне телевизордан күрсәтеп торалар. Уллары өчен бер борчылсалар, алар җаваплылыгында булган егетләр өчен янә хафаланалар. «Аллага шөкер, бөтен солдатларымны исән-сау алып кайттым, берсен дә югалтмадым». Сириядән кайткан Раилнең беренче сүзе шундый була.

Ил хәрби операция игълан итү чигенә җитәр дип башына да китерми ата белән ана. Уллары үз хәрби частьларында гына хезмәт итәрләр дип уйлыйлар. Гүзәлия апаның аларга бер генә сүзе була: «Хәрби хезмәткә килгән егетләрне җәберли күрмәгез. Нәкъ минем шикелле әниләр җибәрә улларын армиягә. Сез миңа газиз булган кебек, алар да әниләренә газиз. Командир икәнсез, аларга әти дә, әни дә сез...» Әмма солдатларны тыныч тормышта гына түгел, кабат хәрби бәрелешләр вакытында да сакларга туры килә улларына. Рафил белән Искәндәр хәрби операциягә китә.

– Рафил Белоруссиягә хәрби өйрәнүләргә киткән җиреннән хәрби операциягә кушылды. Гел сөйләшеп тордык. Шалтыратмый башласалар, борчыла идем, – дип сөйли Гүзәлия апа. – Беренче баруында Искәндәр яраланган. Мәскәүдәге Бурденко госпиталендә дәваланып аякка баскач кына безгә хәбәр итте. Борчырга теләмәгәндер инде, ә без, киресенчә, ут йотып тордык. Рафилнең җәй көне бик озак вакыт бер хәбәре булмады. Ул чактагы кичерешләрне әйтеп, аңлатып булмый. Эчтән калтырап торасың инде. Кеше сораса да, әйбәт хәбәрләре килә дисең, ә үзеңнең кычкырып елыйсыларың килә.
Олы улым белеште: бар да яхшы, анда элемтә юк дип әйткәннәр. Ай ярым бер хәбәре юк, и Ходаем, тавышын булса да ишетәсем килә, дип, уйлана-уйлана өстәл янында утыра идем беркөн, шул мәлдә телефон шалтырады. Рафил! Иң шатлыклы мизгелем иде ул! Абыйсы артыннан ук, ялалары төзәлеп, тагын утка кереп киткән Искәндәр улым шалтыратты. Яралангач, калырга мөмкинлеге дә булгандыр инде, ә ул: «Барам, анда дусларым калды. Яралангач, ут эченнән алып чыктылар мине, ничек аларны ташлыйм», – диде. Гомумән, «Без бармасак, кем барыр? Илне саклар өчен белем алдык!» – диде улларым. Шулай ут йотып яшәгәндә төшемә гел солдатлар керә башлады. Куам икән шуларны. 13 август – ашлык алган көн иде ул. Олы килен шалтырата. Сүзен дә әйтә алмый, елый. «Үзең әйт инде әнигә», – дип, телефонны Раилгә биргәч, «Кайсысы?» – дип сорап, елап җибәрдем. Рафил һәлак булган! БТРлары танкка каршы минага эләккән. Август башында гына видео элемтә аша сөйләшкән идек. Сакаллар басып бетергән, ябыгып та киткән иде. «Улым, нишләп сине ялга кайтармыйлар?» – дидем. «Әни, офи-

церлардан берүзем калдым. Бар да әйбәт, кайгырма», – диде, әмма тавышында ниндидер бер моңсулык бар иде. Саубуллашыр алдыннан: «Якты дөньяларда бер күрешербез әле», – дип әйтеп куйган иде. Күрешергә язмаган икән менә... Бу хәбәрне ишеткәч тә ышанмадык әле. Берничә көн узгач Ульянга кайтардылар, барып алдык. «Шунда табуттагы кечкенә тәрәзәдән йөзен күргәч кенә ышандым», – диде Фәгыйль дә. Рафил улымны озата кайтучылар: «Мондый офицерлар Россиядә бик әз», – дигәннәр. Иптәшләре: «Әйдә, кайт отпускка» – дигәч тә, «Мин солдатларымны ташламыйм», – дип әйткән бит ул... Абыйсының үлеме турындагы хәбәрне Искәндәргә ничек җиткерик икән дип аптырадык. Ә ул белгән... «Минем абый шушында булырга тиеш», – дип әйткәч, «Ты, что, не знаешь что ли, он же двухсотый (200 нче груз – һәлак булган хәрбиләрнең җәсәден ташыганда кулланыла торган шартлы кодлы билгеләмә – *Ч. Г.*)», – дигәннәр. Ул шул хәлдә бәрелешкә кереп китә һәм яраланып контузия ала. Атышларга эләккәнен белгәч, инде монысы исән микән, юк микән дигән уй бер минутка да күңелдән чыкмады. Тавышын ишеткәч кенә исәнлегенә ышандык.

– Язмыштан беркая китеп булмыйдыр инде ул. «Рафил бик тиз туды», – ди әнисе, Ходай гомерен дә шуңа тиз алгандыр инде. Монда булмаса, бәлки, башка җирдә үлгән булыр иде... – ди Фәгыйль абый сабыр гына. «Ходай биргән гомердер инде... Аллаһы Тәгалә дә «шулай булса, шулай булыр иде», дип әйтергә кушмаган бит. Син чын мөселман кешесе икән, дингә ышанасың икән, биргән сынауларны дөрес итеп кабул итәргә тиешсеңдер. Сабые гына ятим калды», – ди күз яшьләрен сөртә-сөртә Гүзәлия апа.

Хәрби дуслары ял алгач, Рафилнең каберенә кайталар икән. Барысы да бер сүздә: «Анда безнең дуслар калды, китәбез...» Бүгенге көндә олы уллары Раил Чиләбедә хәрби частьта хезмәт итә. Искәндәр әлегә дәвалана. Дүртенче уллары үзләре янында. Аш-су остасы булып эшли. Кызлары Энҗе дә спорт юнәлешен сайлаган. Туризм буенча һөнәр ала. «Дүртенче улымны да хәрби итәсем килгән иде, сәламәтлеге буенча үтмәде. Үзенең дә теләге бар иде дә соң...» – ди әти кеше. Армиягә барасым килә дигән яшьләр хәзер бик аз, гаҗәпләнеп Фәгыйль абыйга карыйм.

– Минем малайлар армиядән куркабыз димәде, барабыз дип тордылар. Тәрбиядән килә инде. – ди Фәгыйль абый тыныч кына. – Хәрбиләрне әзерләргә, гомумән, әзер булып яшәргә кирәктер инде ул. Безнең заманда армиягә бармасаң, кешегә дә санамыйлар, ә хезмәт итеп кайткач, хәтта өлкән абзыйлар синең белән ике куллап күрешә иде. Советлар Союзы таркалгач, илгә берни кирәкми башлады бит. Мәктәпләрдә дә хәрби дәресләрне бетерделәр, армиянең, хәрбиләрнең абруе төште. Кешелекле, белемле командирлардан күп нәрсә тора шул! Ике буын диярлек бернинди патриотик тәрбия алмый үсте. Нинди зур тәрбия бит ул! Тәртипкә өйрәтә. Ә илне без сакламыйча, кем саклый соң? Ил таралса, нәрсә булыр соң?!

Батыр егетләр үстергән әти-әнинең үз хакыйкатьләре әнә шулай ныклы. Һәм ул хөрмәткә, соклануга лаек түгел дип кем әйтә ала?!.



«Уен эш түгел...»

«Әфганстаннан кайтканыма инде 30 елдан артты, әмма әле һаман төшкә керә. Мин киткәндә әти белән әнинең чәчләре кап-кара иде, кайтуыма агарып беткән», – дип искә ала яшьлегендә хәрби бурыч үтәвен Арча районы Яңа Кенәр авылында яшәүче Динар Гарифҗанов. Элек әти-әнисе телевизор карашында улым күренми микән дип утырса, хәзер Динар абый үзе шул хәлдә. Аның ике улы, контракт төзеп, хәрби операциядә булып кайткан. Беренче гаиләсендә туган улы тагын китмәде микән дип уйлый. Соңгы очрашуларында улы китәргә теләге барлыгын әйткән булган. Хәзер элемтәгә чыкмый икән. Икенче улы әле ялга кайткан. Тагын китәргә ниятли. Төпчек малае да мобилизациягә эләгергә мөмкин. Хәрби операция турында сөйләргә яратмый уллары. Аларны аңлый: үзе дә яратмады. Ут эчендә йөргән кешене ут эчендә булып кайтканнар гына аңлый. Җитмәсә, Динар абыйга мылтык тоттырып, утка кертеп җибәргәндә бары 18 яшь була. Хәрби әзерлек узганнан соң, Әфганстанга алып китәләр. «Беренче вакытта бик куркыныч иде, бер ел шунда булганнан соң өйрәнелде. Әле вакытында да кайтарып җибәрмәделәр. Өч-дүрт айга тоткарладылар. Шулай итеп, Әфганда мин төгәл ике ел булдым», – ди ул.

«Балалар жәл, әлбәттә, уен эш түгел бит, илне сакларга кирәк», – ди ул Россия игълан иткән хәрби операция турында. Юньләп корал тотмаган егетләрне җыюларына гына борчыла.

– Армия хезмәтен бер елга калдырып, контракт белән хезмәт итүчеләрне булдырып боздылар, – ди чын күңелдән ачынып әфганчы. – Минем уртанчы малай да, кече малай да армиядә булып кайттылар. «Без анда балалар бакчасындагы кебек кенә булдык», – диделәр. Барып та җитмәделәр, кайтып та төштеләр шул. Коралны бер тапкыр тоттырганнар да, шуның белән бетте. Бер ел хезмәттә нәрсә генә өйрәнеп була инде? Хәзер шул егетләрне хәрби операциягә җыялар. Җитмәсә, яшьләр җайлы гына яшәргә тели. Ач калудан куркалар, диләр, без коры паек урынына хәрби припаслар тутыра идек. Шул хакта уйладык, тамак хакында түгел. Повестка килә икән, барырга инде. Мин дә, служаклар да шулай уйлый. Безгә берни куркыныч түгел, утны кичкән кешеләр бит инде без. Ә менә яшь егетләргә әле бит дары исенә өйрәнәсе бар...

«Мобилизацияләнгән егетләргә кулларым белән дә, күңелем белән дә ярдәм итәм»

Хәрби операция башлануга ук хәрбиләргә ярдәм итү кампанияләре оешты. Гуманитар ярдәм төялгән йөк машиналары Донецк, Луганск якларына юл тотты. Мобилизация игълан ителеп, уллары, ирләре, күршеләре хәрби хезмәткә алынган хатын-кызлар, җыелып-җыелып, кул эшләренә тотынды. Район саен диярлек апалар җыелышып носки бәйлиләр, яшьләр, берләшеп, акча җыеп, хәрбиләргә кирәкле көндәлек әйберләр, дарулар сатып алып җибәрә. Ярдәмгә алынган һәр кеше иң элек нәкъ менә үз җирлегеннән киткәннәргә теләктәшлек күрсәтергә тырыша. Питрәч районы Шәле авылында яшәүче Гөлүсә Мифтиеваның авыл халкын җыеп балаклава тегүен социаль челтәрләрдә күреп алдык. Безнең белән сөйләшергә бик озак күндердек. «Мин бу эшкә үземне күрсәтү өчен түгел, бераз булса да ярдәм итү йөзеннән тотындым», – диде ул. Шулай да, үгетли торгач, ризалашты. Шәлегә юл тоттык. Авыл мәдәният йортында бер төркем апалар кечкенә генә бер цех оештырган диярсең. Кайсысы тукыманы үлчи, кемдер өлге кисә, икенчеләре тегә, әзер әйберләрне төреп пакетларга тутырып торалар. «Гөлүсәнең ике туган апасы мин. Казаннан кайтып ярдәм итәм, – ди Алсу Мусина. Ул киселгән өлгеләрне Казанга алып китеп, балаклаваларны тегеп алып кайта. – Хәзер шундый авыр чор, һәр кеше үзе булып калырга тиеш дип саныйм. Анда киткән егетләргә ничек тә ярдәм итәсе килә бит. Минем өйдән хәрби операциягә китүче булмаса да, һәрберебезнең ирләре, абый-энеләре, әтиләре бар. Һәрберебезнең бабалары Бөек Ватан сугышында катнашкан. Телефон тотып, теләсә нәрсә карап вакыт уздырганчы, нигә әле ярдәм итмәскә дип уйладым. Шуны да әйтер идем: илдәге вазгыять халыкны якынайтты. Чаптык та чаптык, туганнар белән күрешергә дә вакыт юк иде бит. Гөлүсә белән дә күрешергә вакыт таба алмый идек. Уртак фикер безне туплады. Хәзер көн саен элемтәдә без. Теккән әйберләрне авыл егетләренә җибәрдек. Районда хәрбиләргә ярдәм итүче волонтер егет бар. Аңа җибәрәбез.





«Мондый эш башлауларына шатландым. Яшьләрнең миһербанлы, ярдәмчел булганнарына йөрәгем сөенде», – ди Фидания апа Хөснетдинова. Үзе тегүче булып эшләгән, хәзер лаеклы ялда. Классташы Минзәлия апа Гыйбашева белән икәүләп яшьләргә ярдәм итәргә килгәннәр. «Кирәкмәгән эш дип әйтүчеләр дә бар. Кирәк, бик кирәкле эш бу! Андагы балаларга кирәк бит. Догалар укып, теләкләр тели-тели эшлибез менә. Исән-сау гына әйләнеп кайтсыннар», – ди алар.

Гөлүсә социаль челтәрләрдәге тегүчелеккә багышланган күптөрле төркемнәрдә утырган. Шуларның берсендә ярдәм итү максатыннан балаклавалар тегү турында хәбәр була. Гөлүсәнең дә бик ярдәм итәсе килә. «Уртак борчу, уртак бурычыбыз», – дип уйлый ул. Һәм үзе дә тегәргә уйлый. Бәлки миңа кушылучылар булыр дип, социаль челтәрләргә пост урнаштыра. Аның бу тәкъдимен авылда битараф булмаган кызлар күтәреп ала. Флис тукымага заказ бирүен белгәч, аңа ярдәм итү өчен акча да күчерәләр. Питрәч районы хастаханәсе коллективы да бер төргәк тукыма алып килә аларга. Хәзер кызлар балаклава гына түгел, яңгырдан саклаучы плащ, «толстовка» да тегә. Ул «толстовка»ларга балалар бакчасындагы сабыйлар ясаган открыткаларны да төрәләр. «Өйдән шушындый әйберләрне алгач, мобилизацияләнгән егетләрнең бераз булса да күңелләре күтәрелеп китәр», – ди кызлар. Питрәч районыннан киткән һәр егеткә балаклава өлгертергә ниятлиләр.

– Сез тилерәкме әллә, дип әйтүчеләр дә бар, – ди Гөлүсә. Күренеп тора: бу идея белән янып тора ул. Янына килеп сораган һәр апага, иренмичә, озаклап аңлата. – Бөтен нәрсә дә акчага сатылмый. Кешегә игътибар, кайгырту сыйфатларын акчага сатып алып булмый. Күңелдән килә торган хис ул. Мобилизация игълан ителгәч, күңел төшенкелегенә бирелдем. Бер атна елап йөрдем. Өч балабыз бар, ирем мобилизацияләнүчеләр категориясенә туры килә. «Повестка килә икән, китәм», – ди. Бүген-иртәгә повестка килер дип көтеп яшим. Менә шушы эш белән мәшгуль була башлагач, күңелемә тынычлык таптым, димме соң... Иремнең алыну ихтималына да башкача карый башладым. Гомере бетмәсә, кайтыр, Алла бирсә, дип уйлыйм. Киткән егетләргә дә менә шулай күңелем һәм кулларым белән булышам.

Видео: Фәгыйлә ШАКИРОВА »



ТӘРӘЗӘ



Гөлнур
ХӘСӘНШИНА





Фото: Анна Арахамия

Кешегә ярап булмый диләр. Була! «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күп функцияле үзәк» учреждениесе директоры, Татарстанның атказанган юристы, икътисад фәннәре кандидаты Ленара Акмалетдин кызы МОЗАФФАРОВА моның бөтен серләрен белә. Иң катлаулы очракларда залга – халык янына ул үзе чыга. Һәм барысын да көйли! Һәркем күңеленә тәрәзә ачу җиңел түгелдер, әлбәттә. Әмма бу аның үзе сайлаган юлы... «Тәрәзә» сүзе ул җитәкләгән оешмада бик еш яңгырый. «Бер тәрәзә» диләр алар, гадәттә. Әмма – нинди тәрәзә! Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов әйткәнчә, «аның аша республика халкының хакимияткә мөнәсәбәте чагыла» икән – ул бит гади була алмый. Әңгәмәдәшем белән әнә шулар хакында сөйләшәбез. Аның үзенең күңел тәрәзәләренә дә күз салырбыз.

«Бу вазыйфаны мин... үзем сорадым»

Документ алу өчен чиратта торуның нәрсә икәнен беләм мин. Торганым булды. Мин аны сатып алдым! Әнине авылдан алып килергә, андагы йортны сатып, шәһәрдә фатир алырга уйладык. Татарстан буенча Дәүләт теркәү палатасы Ершов урамында иде ул чакта. Белгечләргә эләгү өчен ачы таңнан чиратка басарга кирәк. 3 меңгә миңа үз чиратын сатучы табылды...

Татарстан буенча «Кадастр палата»сы 2001 елны оешты. Мин анда беренче көннән үк эшләдем дисәм дә була. 2005 елда аның директоры идем инде. Документлар кабул итүне оештыру буенча тәҗрибәм бик зур. «Күп функцияле үзәк» шушы эшләрнең дәвамы кебек булды.

Татарстанда «Күп функцияле үзәк»нең – КФҮнең оешу тарихы шактый кызык. Кадастр палатасы Федераль үзәккә карый – эш буенча Мәскәүгә еш барып йөри идем. Федераль органнарның кабул итү пунктлары тиздән булмаячак, субъектларда КФҮләр оешачак дигән хәбәрләр инде ишетелә башлады. 2012 елда, чыннан да, Президентның шул хакта Указы чыкты. Әмма бездә бу вакытта «Росреестр»да да, «Кадастр палата»сында да чиратлар юк иде инде: язылып, шул көнне үк белгечкә эләгеп була. Мин ул вакыт талоннарга фамилия язуны кисттем – сатып, акча эшләүне туктаттым. Тагын нидер үзгәртергә кирәкми дә кебек иде...

«Кадастр палатасы»ның районнардагы филиалларында мең ярым хезмәткәр эшли иде. Иң катлаулы документларны кабул итүне дә биш бармагы кебек белүче белгечләр! «Росреестр» документлары элек тә, хәзер дә иң катлаулысы дип санала: милеккә хокукны теркәүнең 300 ләп төре бар! Коллегалар килеп: «Районда КФҮ төзиләр, безне яңа оешмага алабыз дип торучы күренми», – диләр. Берсе шулай зарланды, икенчесе... 2015 ел җитте. Рөстәм Нургалиевич катнашында чираттагы коллегияне уздырдык. Ул эшебезгә уңай бәя бирде, КФҮләр турында да искә алды. Шунда уйлыйм: бу яңалык тормышыбызга барыбер керәчәк – әлеге эшкә үземә алынырга кирәк. Президентка тәкъдимнәрем белән кердем... КФҮләр оештыру буенча республика артта сөйрәлә – моны да төзәтергә кирәк иде. Ә мин, «Кадастр палатасы» директоры буларак, дәүләт хезмәткәре дип саналмыйм, шуңа күрә тагын бер вазыйфа били ала идем. Без ул чакта элмә такталарын гына алыштырдык. 4 февральдә республикада КФҮләр төзү турында Президентның карары чыкты – кул астымда эшләүчеләрнең сигез йөзе ул көнне КФҮ хезмәткәренә әйләнде. Сүз уңаеннан, ул елны дәүләт пошлинасының 50 проценты Татарстанга калу турында карар кабул ителде: беренче елда ук республика бюджетына 300 миллион табыш керттек. Президентыбыз безнең үзәккә һәрвакыт югары бәя бирә – Рөстәм Нургалиевичның аңлавын, ярдәмен тоеп эшлибез.

Ә Россиядә бу вакыт «Кадастр палата»сында кыскартулар башланды. Менә дигән белгечләр китте. Ә КФҮләргә берниндн тәҗрибәсе булмаган кешеләр килде. Чираттагы коллегияләрнең берсендә Россия Федерациясенең икътисад министры урынбасары Виктория Абрамченко: «Сез ул чакта шулкадәр дөрес карар кабул иткәнсез. Кызганыч, бу тәҗрибәне кабатларга соңга калдык – никадәр белгечне югалттык», – дип, миңа рәхмәт белдерде.

«Күп функцияле үзәк»ләрнең иң зур өстенлеге – хезмәтнең тиз күрсәтелүе, чиратлар булмавы.

«Бер тәрәзә» принцибы

«Күп функцияле үзәк»нең нинди оешма икәнен башта бик күпләр аңламады. Хәер, андыйлар хәзер дә бар... 61 төрле хезмәт күрсәтүдән башлаган идек, бүген инде алар 287 гә җитте. КФҮ – кабул итү пункты гына ул, әмма профессиональ пункт. Әйтик, паспортыгызны югалттыгыз ди. Аның белән бәйле тагын күпме документны үзгәртергә кирәк булачак сезгә: ә ул оешмалар шәһәрнең төрлесе төрле җирендә урнашкан, төрле вакытта кабул итә... Ә сез киләсез дә, боларның барысына берьюлы заказ бирәсез. Үзәк эше нигезенә салынган «бер тәрәзә принцибы» шушы ул. Юк, ул документларны үзебез әзерләмибез. Безнең төп бурыч: документларны хатасыз кабул итү һәм иң мөһиме – әзер документны органнардан вакытында кире алу. Гел ике арада – чиновник белән гариза бирүче арасында торабыз. Документны сораучыга вакытында алып бирү – безнең мәнфәгатьләрдә, югыйсә өстебезгә негатив ява башлаячак...

Кабул итүнең иң авыр эш икәнен һәм моны хәзер КФҮнең үз өстенә алуын белгән органнар бу яңалыкка сөенде, әлбәттә. Халык кына, әйткәнемчә, безнең арадашчы икәнне хәзергәчә аңлап бетерми: документлар бирәр сәбәп белән эшләүдән туктатылганда яки кире кайтарылганда бөтен гаепне үзәктән күрә.

Россия Президенты Владимир Путин КФҮләр төзүне ил тарихындагы иң уңышлы социаль проект дип атады. «Цифрлаштыру заманында нигә кирәк бу үзәкләр? Өйдән чыкмыйча да гариза биреп була бит», – дияр кемдер. Әмма бөтен кеше дә компьютерда утырмый, һәркемдә гаджетлар да юк шул әле.

Россия Федерациясе хөкүмәте рәисе Михаил Мишустин максат куйды: 2024 елга барлык дәүләт, республика, муниципаль органнар үзләренең кабул итү пунктларын ябарга – бу мәшәкатьле эшне безгә тапшырырга тиеш.

«Эштә яну»

Безгә иң күбе күчемсез милек объектларын исәпкә алу буенча мөрәҗәгать итәләр. Аннан – паспорт алыштыру, машина йөртү таныклыгы алу, салым бурычлары буенча мәгълүмат бирү, төзелеш объектларын төзү һәм реконструкциягә рөхсәт алу... Санап чыгу да мөмкин түгел! Өч ел элек аучыларга ау билеты бирә башладык. Уенынчынын кушып: «Сезгә бензин дә алып киләсе түгелмени?» – дип яздылар алар сайтка. Чиновникка килми бит алар... Шул ук вакытта чиновникны ашыктыра да алмыйбыз. Кайчак: «Тизләтә алмассызмы?» – дип сорый-

Безнең офиста Дәүләт хезмәтләре порталында «Шәхси кабинет»ыңны ачарга өйрәнергә була.



лар: юк, регламентта ун көн дип язылган икән, димәк, ун көннән соң гына аласыз документны.

Әйе, шундый очраклар да була: белгеч документларны кабул иткәндә ялгыша. Ә кешенең төрлесе бар: юк кына сәбәптән тә кызларга кычкыра, теләсә нәрсә әйтә, түбәнсетә башлый... Кәгазьләрне, паспортын күтәреп ата... Эштән китәргә гариза язган һәркем белән үзем сөйләшәм, сәбәбен сорыйм. Бүлектәге кызлар: «Бер көнгә дүрт конфликтка түзә алам, шуннан артса, көчем калмый», – диләр. Бездә хәзер «психологик бушаныш кабинеты» эшли. Гомумән, яңа килгән кеше психолог белән аралашмыйча, аны эшкә кабул итмим. Моңарчы яңа килүчеләрнең 70–80 проценты өч ай эшләүгә китә иде. Ә без аларга эш формасы тектерәбез, бушлай эшкә өйрәтәбез... Хәзер китәргә гариза язучылар 1,6 проценттан артмый. Әйе, халыкны кабул итүдә һәркем эшли алмый, монда эчке бер ныклык кирәк. Агрессиягә каршы торуны бөтен кеше дә булдыра алмый икән. «Нигә сезнең хезмәткәрегез елмаймый?» яки «Нигә ул гел елмая?» – дип тавыш чыгаручылар да бар бит... Без хәзер хезмәткәрләребез арасыннан конфликтны чишә белүчеләрне эзләп таптык. Бер елга кадәр эшләүчеләргә бәхәсне хәл итәргә тырышырга да кушмыйбыз: гариза бирүче тавыш күтәрә башлый икән, ул шунда ук төймәгә басарга тиеш – аңа ярдәмгә киләчәкләр. Һәр яңа хезмәткәргә остаз беркетәбез – бу да дөрес карар булды... Районнардагы офисларда мондый проблемалар юк, әлбәттә. Анда халык бербeрсен белә – мөнәсәбәтләр бөтенләй башкача корыла.

Пандемия чоры

Бу хакта аерым сөйләргә кирәк. Кемдер инде, бәлки, онытырга да өлгергәндер, ә без әле озак хәтерләрбез: смартфоны булмаганнар Covid-19 вакцинациясе турында QR-кодлы сертификатны алу өчен безгә чиратка тезелде ул көннәрдә. Халык белән эшләүдә тәҗрибәсе булмаган башка оешма бу эшне ерып чыга алмас иде... Кемнекедер килеп җитмәгән – нәтиҗәдә, без гаепле. «Мозаффарова, куар-код уйлап чыгардың да, хәзер безне шуның артыннан йөрергә мәҗбүр итәсең», – дип язучылар да булды... Пандемиягә кадәр республикадагы 61 офиста көнгә 14 мең кешене кабул итсәк, QR-код таратканда рекорд куйдык – бер көнне 28 мең кешегә хезмәт күрсәттек. Үземнекеләргә шаккаттым: кирәк диделәр дә эшләделәр... Яңа ел бәйрәмнәрендә дә, май бәйрәмнәрендә дә ял итмәдек – балалар өчен түләүләр башланды. Пандемия игълан ителгәч, бөтен оешмаларны ике атнага өйләренә җибәрделәр. Ул чакта без дә киттек. Аннан аңладым: документлар вакыт белән бәйле, күбесе инде «яна». Халыкны алдан язылу буенча кабул итә башладык. Ике атнадан эшкә чыкканда өстәлемдә 600 жалоба җыелган иде. Берәү: «Хөрмәтле Владимир Владимирович! Барысын да аңлыйбыз – сез безне кайгыртасыз. Әмма МФЦлар нигә эшләми соң?» – дип язган. Әйтерсең, безнекеләргә чир янамый!

Саклангянны – саклармын

Узган елның 7 декабрендә Мәскәүдәге КФҮләрнең берсендә коточкыч зур фаҗига булды. Бер ир-ат үзәк хезмәткәрләренә ут ачты: кешеләр һәлак булды. Казан мәктәбендә булган атыштан соң да аңладым – бу бездә дә кабатланырга бик мөмкин. Теркәү палатасында белгечләр һәрвакыт пыяла артында утырды. Районнарда хәзер дә шулай. Сүз уңаеннан: ковид вакытында нәкъ менә пыяла артында утыручылар авырмады... Без әлеге мәсьәләдә Мәскәүдәге министрлык белән гел бәхәсләшә идек. Бу хәл булгач: «Эшебезне түбәнрәк бәяләсәгез дә риза, әмма һәркем алдына саклагыч пыяла куябыз», – дидем. Кызлар моның өчен миңа бик рәхмәтле: «Гариза бирүче ярсып киткәндә сугар, биткә нәрсә булса да бәрер дип гел курка идек», – диләр. Сак хезмәтеннән тыш, һәр филиалга «шомлы төймә» куйдыртуга ирештем. «Росгвардия»не чакырып укулар үткәрдек. Гап-гади нәрсәләрне дә белмибез булып чыкты. Иң мөһим кагыйдәне сез дә истә калдырыгыз: андый очракта башкаларны коткару белән шөгыльләнмәгез, үзегезне саклагыз. Беркайчан да аягүрә басмагыз, шунда ук идәнгә утырыгыз. Һөҗүм итүченең күзенә карамагыз.

Ә «шомлы төймә»гә басарга туры килгәнлеге бар. Дәрвишләр бистәсендә бер ир-ат офистагы кызларны әледән-әле куркытты. Полиция чакырталар – качып өлгерә. 9 Май көнне «Үлемсез полк»та әлеге офисның начальнигын табып, аңа һөҗүм итте... Гариза арты гариза язып, кулга алдыруга ирештек – авыру кеше булып чыкты.

Күләргә дә, еларга да белмәгән хәлләр бездә гел булып тора. Пандемия вакытында бер урындык аша утыру тәртибе кертелде. Бер көнне 60 яшьләрдәге бер хатын,

тыныч кына чиратта утырган җирдән сикереп торып, урындык-диваннарга ябыштырган ленталарны кубара башлаган. Полиция чакырттык. Ул арада аның килешүгә кул куярга чираты җитте. «Бернинди документ та кабул итмибез. Бу хәлдә ул фатир сата алмый, иртәгә тынычланыр да үзенең ялгышканын аңлар», – дим. Безгә салган 50 мең зыянны да түләде ул. Мин бит һөнәрем буенча юрист – эшемдә бу бик булыша.

Эшкә өйрәтүче мәктәп

Кешеләрне яратмасаң, «Минем документларым» («Мои документы») офисларында эшләп булмый. Ул очракта конфликтлар бермә-бер артыр иде...

КФҮ мәктәбен узган белгеч төрле өлкәләрдә эшләрлек белем туплый, бөтен документны да тотырырга өйрәнә. «Без – күппрофильле белем бирүче оешма, моннан киткәч, сез – эшне түгел, ә эш сезне эзләячәк», – дим яшьләргә. Аларга, чыннан да, теләсә кайсы югары уку йортыннан да күбрәк белем бирәбез. Күптән түгел эшкә урнашкан хезмәткәр хата ясый икән, шунда ук кабат укырга утыра. Бездә һәр айның бер көнендә филиалларның берсе белемен арттыра: законнар гел үзгәреп тора – алар белән танышып барырга тиешбез.

Кем белә: бәлки киләчәктә теләсә кайсы документны электрон рәвештә генә алып булыр, ә без халыкка порталга гаризаны ничек бирергә икәнен өйрәтүче генә булып калырбыз. Әйе, бик мөмкин! Әле кайчан гына Мәскәүдә фатир сатып алып, сатып-алу эшләрен Казанда гына эшләп булуын күз алдына да китерә алмый идек. Бүген бу – гадәти күренеш. Тормыш бик тиз үзгәрә.

Өченче буын җитәкче

Әнием Тәтеш районының Олы Тархан авылыннан. Минем дә балачагым, гомеремнең бер өлеше шунда узды... Бабам районның «Сельхозтехника» оешмасын җитәкләгән. Әнием авылда пекарня директоры иде, аннан Яшел Үзәндә ашханәләр трестын, рестораннар җитәкләде – һәрвакыт сәүдә өлкәсендә эшләде. Иртәнге сәгать дүрттә тора иде ул. Йокы аралаш көн саен бер сүз ишетәм: ир-



■ Бездә һәрвакыт «Иң яхшы хезмәткәр» исеменә бәйге уза. Башта үзебездә, аннары – Россия күләмендә. Яшел Үзәндә эшләүче хезмәткәребез Айгөл Хаҗиәхмәтова, иң күп балл җыеп, быел менә конкурстан беренче урынны алып кайтты.

түк колхоз рәисенә шалтырата – солярка алып кайту өчен «бензовоз» сорый... Әни өчен ипи – иң зур сый. Алар пешергән икмәк сыйфаты буенча Казанда гел беренче урыннар ала иде. Тарханда кечкенә генә йортта яшәдек без, әмма әни атна саен анда йорт җиһазларының урынын алыштыра иде. Тирә-юнендә матурлык тудыра белә ул! Складка он, чүпрә, май кабул итүне миңа 2–3 нче классларда ук ышанып тапшырды. Шундый итеп саныйм – ник бер кисәк чүпрә югалып карасын! Аннан мин мотоцикл алырга теләдем. 5–6 нчы класста укыганда бу. «Эшлә, үз акчаңа алырсың», – диде әни. «Беркайчан да ул акчаны җыя алмассың дип уйладым», – диде ул соңыннан. Ә мин җыйдым! 460 сум! Җәй буе куас саттым, туган көнгә дә бары тик акча гына бүләк итүләрен сорадым. «Минск» мотоциклыннан II курста укыганда гына төштем: «Кыз балага килешми», – дип туктаттылар. Сыер эзләргә җайлы иде мотоцикл белән... «Эшли башларсың да, ни теләсәң – шуны алырсың», – дип үстерде мине әни. Үпкәли идем, билгеле. Хәзер аңлыйм – ул бик дөрес тәрбияләгән. Әнигә 72 яшь. Аңардагы энергиянең 10 проценты да юк миндә! Һәрнәрсәгә сөенә белә. Мине өйдә халаттан күрсә, шунда ук тавыш күтәрә: хатын-кыз һәрвакыт матур күренергә тиеш дип саный ул. Гаиләдә – бигрәк тә.

Мин – балыкчы!

Беренче калкавычымны кайдан алганымны да белмим. Бабай да балык тотмый иде, әти дә... Әнкәйгә судак булсын, ул маймычларымны пешереп тә тормый, әмма мин барыбер яр буеннан кайтып кермим... Ирем Илдар Сарман районының Җәлил бистәсендә үскән – анда зур сулар юк. Балыкны ул, гомумән, миңа өйләнгәч кенә ашый башлады. Хәзер исә без аның белән профессиональ балыкчылар: балыкка дип Әстерханга кадәр дә чыгып китә алабыз. Мин тоткан иң зур балыкмы? Ике кило ярым иде! Тик бер гадәтем бар: зуррак балык эләккән кебек тоелса, тартып чыгарырга гел Илдарны чакырам. Кармактан ычкынса, кәефем төшмәсен дип, ахрысы – ул очракта мин гаепле булмыйм бит.

Без әле аның белән тагын гөмбәчеләр дә. Бакчачылар да! Мин үзем энергияне җирдән алам. Бакчабызда бер чүп үләне үсми. Ел саен 300–400 банка салат ябам. Илдар белән без аны, гадәттә, урамда икәү әзерлибез – учакта пешерәбез. Тәмлелеге! Кунак сыйларга бик яратам – барысын да үзем әзерлим. Камырга гына тотынганым юк. Барыбер камырым Тархан әнкәйнеке кебек юка килеп чыкмастыр... Ә пылауны бездә Илдар гына пешерә. Миңа ул кишерен дә туратмый. Хәтта казанын да юдыртмый: «Аны юуның үз серләре бар», – ди. Юк, мин өйдә җитәкче түгел – бөтенләй башка кешемен. Илдарда юмор хисе ташып тора – ул мине бик тиз үз дулкынына көйли... Улыбыз Илхан өчен әтисе – иң якын дус. Аның миңа: «Әни, син биргән ике киңәшне беркайчан онытмыйм. «Булдыра алмыйсың икән – вәгъдә бирмә, биргәнсең икән – үтә», «Хыялларыңны кычкырып сөйләмә», дидең син», – дигәне булды. Үземнең төп тормыш принципларымны аңа җиткерә алуыма сөенәм!

ТӘРБИЯДӘ ИДЕАЛЬЛЕККӘ ОМТЫЛЫРГА КИРӘКМИ ИКӘН



Таңсылу, син әниең белән шундый охшаш! Холыкларыгыз да охшашмы?

– Минемчә, холыкларыбыз да охшаш. Вакыты-вакыты белән бик кызу, сабырсыз булырга мөмкин без. Шулай да әнигә караганда, мин сабыррактыр. Әни эмоциональ, тиз ярсып китүчән. Әти белән ул яктан тынычрак миңа. Аның янына килəм дә, болай эшлим әле, дим. Ул бер сәгать уйлап утырырга, аннан соң бер сүз дә әйтмәскә мөмкин... Ә әни белән беркайчан да алай булмаячак. *(Көлә.)* Әмма шуны әйтә алам: әни һәрвакыт минем яклы.

Әниеңнән серләрең бармы?

– Бик тыныч тормыш алып барам бит мин. Начар гадәтләрем юк – ничек бар шундый. Шуңа күрә яшерер әйберләрем юк. Төнлә беркая да чыгып китмим, беркем белән дә очрашмыйм, яхшы укыйм, кайчак мин үземне бик күңелсез кешедер дип уйлыйм, әмма бу алай түгел. Яшьтәшләрем белән чагыштырганда, артык дөрес кеше инде мин.

Борчыймы әллә бу халәтең?

– Юк, бу минем өчен идеаль халәт. Үземә бик ошый. Безнең яшьтә каядыр барып бәйрәм итеп йөрергә яраталар, ә миңа өйдә рәхәт! Китап укыйм, сериаллар карыйм. Бу күпкә кызыграк.

Таңсылу, синең ике сеңлең – Зифа белән Зәйнәп бар. Алар тугач көнләшү булмадымы?

– Зифа миңа 4 яшь булганда туды. Мин берүзем генә булуымны бөтенләй хәтерләмим. Балачагым Зифа белән үтте. Башта ук үземне олы апа итеп кабул иттем. Үземдә җаваплылыкны да тоям. Әти белән әнинең миңа игътибары аз дип үпкәләп йөргәнем дә булмады. Бу җәһәттән комплексларым юк. Мин – мөстәкыйль кеше. Мәктәпне тәмамлагач, башка шәһәргә укырга китәргә мөмкинмен. Китсәм, авыр булачагын да беләм, чөнки мин гел гаиләм янында. Шулай да иртәме-соңмы алар яныннан чыгып китәчәгемне аңлыйм. Рухи яктан үземне моңа әзерлим дә бугай.

Беренче балага гадәттә: «Син олы кыз, эне-сеңелләреңне кара», – диләр. Сиңа да шулай әйтәләрдер. Бу җаваплылык сине кайчак алҗытамы?

– Кайчак була. Зәйнәп әле кечкенә чакта һаман аны карау ялкыта иде, ә хәзер үзем теләп карыйм. Ул бит үсә. Аның кызыксынулары да үзгәрә. Ул хәзер биергә ярата, мин дә биергә яратам. Дөрес, соңгы вакытта укуым аркасында аның белән еш уйный алмыйм.

Син инде зур сәхнәдә җырлыйсың, социаль челтәрләрдә инглиз телендә җырлавың шәхсән миңа аеруча ошый...

– Рәхмәт. Үземне белгәннән бирле җырлыйм һәм ул миңа бик ошый. Вокал белән бары 10 яшьтән генә шөгыльләнә башлаганыма үкенәм кайчак. Кечкенә чакта кем буласың килә, дип еш сорыйлар иде. Җырчы буласым килә иде, әмма бу хакта әйтми идем. Киләчәктә аранжировкалар ясау белән дә шөгыльләнергә телим.

Таңсылу, әни белән конфликтлар булмый калмый бит инде ул. Кем беренче дуслаша?

– Ачуланышканнан соң әни миңа бүләк бирә, мин ниндидер җылы сүзләр әйтәм, дип сөйләүчеләр бар яшьтәшләрем арасында. Бездә бервакытта да алай булганы юк. Сүзгә киләбез икән, шунда ук онытабыз. Һәм бу теманы башка күтәрмибез. Әмма ниндидер бер ситуацияне әни дөрес аңламый йә ул хаклы түгел икән, мин бит хаклы, гаебем кайда соң, дип, озаклап уйлап утырырга мөмкинмен. Әмма әни бит инде ул, нигә инде үпкәләргә дип тынычланам да онытам. Гомумән, үпкәчел кеше түгелмен. Үпкәләп йөрүнең мәгънәсен дә күрмим.

Әниең узган ел җитди авыру белән авырган. Бу хәбәрне ничек кабул иттең?

– Бу хакта үзе әйткәнче үк сизендем. Аның турында уйламаска тырыштым, әмма андый хәл булу мөмкинлеген аңлый идем.

Курыктыңмы?

– Курыктым дип әйтеп була микән... Мин әнинең: «Хәзер инде бар да яхшы» дигән сүзләренә ышандым. Яшермим, беренче көннәрдә еладым. Әнине бик жәлләдем. Хәзер инде әнине сакларга кирәк дигән уй белән яшим. Ул әйтмәсә дә, өйдәге эшләрне эшләп куярга тырышам. Һәркемнең авырып китү ихтималын, шуңа күрә якын кешеләрнең кадерен белергә кирәклеген аңладым.

Әниең белән кичергән иң бәхетле мизгелең?

– Уйларга кирәк... Икәү генә булган бәхетле мизгел... Сәхнәдә икебез генә җырлаганда. Ул – синең генә әниең, башка балалары юк кебек. Тормышта без гел Зифа, Зәйнәп белән бергә. Әни белән икәү генә каядыр баруга да каршы түгел мин, әмма гаиләсез үзебезне күз алдыма да китерә алмыйм.

Үсмерлек чоры. Ата-ана өчен иң зур сынау вакытыдыр бу, мөгаен. Сүзеңне тыңлап, һәрвакыт янында сырпаланган бала көннәрдән бер көнне бөтенләй үзгәрә дә куя. Аның инде үз дөньясы... Бала белән бәйләнешне ничек саклап калырга? Бәлки, безнең геройларыбыз тәҗрибәсе дә сорауларыгызга җавап табарга ярдәм итәр. Рубрикабызның кунаклары – җырчы Ләйсән ГЫЙМАЕВА һәм аның кызы ТАҢСЫЛУ.

Ләйсән, син нинди үсмер идең?

– Бик оялчан, үз сүземне әйтергә дә курыккан бер үсмер идем. Ул тәрбиядән килде микән, безне эш белән, кырысрак тәрбияләделәр инде. Әллә үз-үзеңне кабул итә алмау булган микән... Үсмер чагымны бер дә сагынып искә алганым юк. Таңсылуны гел үзем белән чагыштырам. Ул башка. Аның һәрнәрсәгә үз фикере бар. Мине дә, әтисен дә өйрәтергә, безнең белән килешмәскә дә мөмкин. «Кызым, хәзер мөмкинлекләр шундый зур. Синең алда бөтен юллар да ачык, кулланып кал. Ничек булдыра аласың, шулай тырыш», – дип әйтәбез инде без аңа.

Таңсылуга: «Безнең кебек җырчы бул» йә «Берүк сәхнә турында уйлый да күрмә» дисезме?

– Бар да, барма да димибез. Өч кызыбыз арасыннан Таңсылу – тугач ук җырлый башлаган бала. Шулай да музыка мәктәбенә өченче сыйныфта гына үзе теләп китте. Аңынчы басым ясамадык. Төрле түгәрәкләргә йөреп карады да музыканы сайлады. Ул җырлый, телләр өйрәнүгә дә сәләте бар. Ике уку йортына берьюлы керсәм, алып бара алырмын микән, дип тә әйтештерә башлады. Балага ниндидер басым ясарга куркыныч та бит әле ул. Әти-әнисе теләгән һөнәргә укып, үзләрен табалмый йөрүчеләр дә бар. Кемдер югалып кала, көчлерәкләр урау юллар белән булса да үзе теләгәненә ирешә. Күңелең ничек куша, шулай эшлә, дибез Таңсылуга.

Ләйсән, әни кеше буларак, упкәләшүләрне ничек җайлыйсың? Әллә әтиегез җайлыймы?

– Бездә, беләсеңме, ничек, әгәр дә Таңсылу минем белән конфликтка керә икән, әтисе читкәрәк китә, әтисе белән аңлашылмаучылык туа калса, мин тыңлап кына торам. Без аны дөрес алымдыр дип уйлыйбыз. Әгәр дә икең бергә кушылып, балага тавыш күтәрсәң, өйрәтә башласаң, бик авыр булачак аңа. Кызларны ишетергә, тыңларга тырышам. Ишекне шапылдатып ябып бүлмәсенә кереп киткән вакытлары да булды инде. Аңа да тыныч карыйм.

Килешәсеңдер, беренче бала – тәрбиядә экспериментлар корбаны да бит әле ул...

– Әйе, килешәм. Зәйнәп белән Таңсылуга булган мөнәсәбәтләр, чынлап та, җир белән күк арасы. Бу хакта сөйләшкән дә бар. Таңсылу аңлый инде. Шулай булырга тиеш булгандыр, ди.

Ләйсән, син сәхнәдән идеаль булып күренәсең. Гел камиллеккә омтыласың кебек. Таңсылуны да идеаль итеп үстерергә теләгәнсеңдер әле.

– (*Көлә.*) Мин алай ук идеаль түгел үзе, әмма Таңсылуны үстергәндә идеальлеккә омтылу булды. Психология фәне белән таныша башлагач, алай булырга тиеш түгеллеген аңлап алдым. Әмма тәрбия тәэсир итми калмаган. Таңсылуның холкында шундый сыйфат бар: кайбер чакта үзен минем урынга куеп, сеңелләреннән минемчә таләп итә башлый. «Мин булма, зинһар өчен», – диям ул вакытларда. «Минем өчен борчылма», – дип әйтәм.

Борчылу дигәннән... Күптән түгел социаль челтәрләрдә яман шеш авыруы белән көрәшүең турында яздың. Авыруың хакында иргә, туганнарга әйтү, балага әйтү белән чагыштырганда, җиңелрәктер әле. Син бу хакта кызларыңа ничек әйттең?

– Операция ясагач кына әйттем аларга. Борчыйсым килмәде. Ул бит Яңа ел алдыннан булды. Яңа елга чистарынып керәсем килде. Бетте, үтте диган уй белән башлыйсым килде елны. Ни дисәң дә, бәйрәм, могҗиза көтә балалар ул чорда, кәефләре дә күтәренке була. «Кечкенә генә бер операция ясатырга кирәк. Әбиләр, апалар киләчәк, сезгә күңелле булачак», – дип әйттем кызларга. Хастаханәдән чыгып, берәр атналар узгач кына өстәл артында нинди авыру белән очрашканым турында хәбәр иттем. «Барысы да артта калды инде», – дидем. «Куркып торган идем, шундый җайлы гына әйттең», – диде Булат.

Шушы хәлдән соң Таңсылуның үзеңә карата мөнәсәбәтендә үзгәрешләр сиздеңме?

– Нык үзгәрде дип әйтә алмыйм. Әмма башка кызларга караганда, игътибарлырак: һаман «Әнием, хәлең ничек?», «Нишләп кәефең юк?» дип сораштырып кына тора. Беренче бала әти-әнисен җәлләүчән була. Ул болай да кайгыртучан бала иде, хәзер тагын да көчәйде. Сеңелләренә караганда аның белән тагын да якынайдык дип әйтимме соң инде...

Таңсылу быел унберенче сыйныфны тәмамлый. Башка шәһәргә укырга китәм дисә, син аны җибәрергә әзерме?

– Уенда юк түгел. Хәзерге вазгыять кенә аны бераз үзгәртте кебек. Әле уйлана... Баланы үз янында бәйләп тотарга ярамый диләр бит инде. Йөрсен, күрсен, мөстәкыйльлеккә өйрәнсен. Безнең фикер шундыйрак. Аңа булдыра алганча ярдәм итәргә тырышачакбыз.

Таңсылуның дуслары белән аралашуны өстенрәк күргән чорыдыр, мөгаен. Егетләр дә барлыкка килгәндер. Тормышының бу этабын ничек кабул иттең?

– Йөрми ул безнең беркая да. Иптәш кызлары белән очрашып, каһвә эчеп кайтырга мөмкин. Дус малайлары да юк бугай. «Мәктәптә апаңның дус малайлары бармы?» – дип, Зифадан да сораштырам. «Юк», – ди. Миңа калса, аның максатлары башка әле. Безнең Таңсылу, башта югары уку йортын тәмамлап эшлим, ди. Хәзерге яшьләр иң элек үз-үзен финанс ягыннан тәэмин итү турында уйлый бугай.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА
Фото: Анна Арахамия



PRESSA

ОЧКЫЧЛАРГА КАНАТ КУЙГАНДА



Алсу ШАКИРОВА

– Бакчабыз яшәгән җиребездән – Авиатөзелеш районыннан ерак түгел. Очкыч тавышы ишетелүгә бакчага йөгерешеп чыгабыз. Заводта җыелган самолетның беренче тапкыр һавага күтәрелү мизгеле безнең өчен дә бик дулкынландыргыч. Бер күрүдә үк таныйбыз без аларны. Әле буялмаган да – дюралюминийга хас сыек яшел төстә булсалар да, һәрберсен аерабыз. Гади очкыч дип кенә карамыйбыз без аңа. Ничә еллык тырышлыгыбыз кергән хезмәт җимешебез бит ул! Бу хисләрне заводта эшләүче кеше генә аңлар. Гүя күктә яңа гына стапельдән төшкән самолет түгел, меңләгән кешегә кадерле һәм якын булган җан иясе күккә күтәрелгән. Кеше куллары белән җыелган могҗиза бит ул!



Бу диварлар эчендә очкычлар гына түгел, гаиләләр төзелә, язмышлар хәл ителә...

Завод диюгә, рәт-рәт тезелеп киткән төрле станоклар, вак һәм зур детальләр, стапель корылмалар, җәелеп ятучы җитештерү цехлары, минуты белән исәпләнә торган эш көне, бертуктаусыз хәрәкәт күз алдына килә. Әмма шул салкын тимерне, станокларны, үзеннән дә зур җайланмаларны кеше буйсындыра бит! Завод ул – кешеләр, диләр. Кеше куллары теләсә кайсы тимер кисәген бөгә, сыгылмалы итә, алардан үзе теләгән деталь ясый. Тели икән – аларга канат куеп күккә күтәрә! Бу осталык, хезмәт алымнары, традицияләр, буыннан-буынга күчеп, еллар аша киләчәккә юл сала. Бу диварлар эчендә очкычлар гына түгел, гаиләләр төзелә, язмышлар хәл ителә... Быел үзенең 95 еллык юбилеен билгеләп узган завод гомере әнә шундый алтын куллы кешеләре белән исәпләнәдер ул.

С. П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводына 289 ел гомерләрен багышлаган Хөсәеновлар гаиләсе дә – очкычларга канат куючылар. Республикада күптән түгел узган Машина төзүчеләр көне уңаеннан оештырылган бәйгедә «Хезмәт династиясе» номинациясендә җиңүче буларак сәхнәгә менгән гаиләнең завод белән бәйле беренче хатирәләренә чумабыз.

– Нәселнең хезмәт стажы башында Роза апабыз тора. Заводка иң беренче булып ул урнашкан. Ләкин аңа кадәр безнең әти дә эшләгән әле монда. Сугыш башлангач, Лаеш районы Атабай авылыннан җибәргәннәр аны. Авыл агаена агач белән эш итү чит-ят әйбер түгел, балта остасы булуы бик ярап куйган. Фанерадан самолетлар җыюы турында сөйли иде әти. Очкычның яңа модельләренең макетын шулай ясый торган булганнар элек, шунда катнашкандыр дип фаразлыйбыз. Ләкин аның документларын архивтан таба алмадык... Аларны да кушсак, тагын да зуррак сан чыгар иде, – дип аңлата гаилә башлыгы Һарун абый.

Ул үзе заводка мәктәп бетергән яп-яшь егет булып килеп керә. Гаиләдә җиде бала үсә, җидесенең дә хезмәт юллары завод белән бәйләнгән. Вакыты да шундый булган инде, әле балалыктан да чыгып җитмәгән егет апалары Роза, Равия, абыйсы Әхәт эшләгән Казан авиация заводына барып урнаша шулай. Башта калайчының укучысы буларак өйрәнеп йөри, ата-бабадан сеңдереп үскән осталыгы ярдәм итә егеткә. Аннары армиягә барыр вакыты җитә. Хәрби хезмәттән крановщик белгечлеге алып кайта да эшен яңадан заводта төзелеш цехында дәвам итә Һарун абый.

– Өр-яңа 69 нчы цех төзеләсен әйтте дус егетләр. Өстәвенә, анда эшләүчеләргә фатир алу мөмкинлеге дә булачак! Мондый мөмкинлекне ычкындыру – ахмаклык. Яңа цехка барып урнаштым. Әле ул цехның корпусы гына төзелгән иде. Барлык җайланмаларны урнаштыру, торбалар сузу безгә – яңа коллективка йөкләнде. Барыбыз да диярлек яшьләр, цехны аякка бастыруның бер кыенлыгы да булмады. Бик күңелле итеп эшләдек, җитәкчелек тә аңлый торган, кешелекле иде. Алар үсендерә белде, без тырышып эшләдек. Һәрвакыт алдынгы булдым мин. Бу эшләр тәмамлангач, цехка аппаратчы кызлар килде... – дип искә ала яшь чакларын Һарун абый.

Бу урында Чуашстанда туып-үскән Фәридә ханым турында сөйли башларга вакыт. Ул да мәктәпне тәмамлагач, Мәскәүгә апасы янына заводка барып урнаша. Анда биш елга якын эшләгәннән соң, Казанга күченергә хәл итә. Туганнары бик күп була монда. Ә менә авиация заводына килеп керүе очраклы булганмы, язмышмы – анысы мөһим түгел. Яшь коллективы белән аерылып торган 69 нчы цехка аппаратчы булып эшкә килүче кызлар арасында Фәридә да була.
Өч катлы йорт биеклегендәге чистарту корылмалары җитештерүдә кулланылган барлык суларны цехлардан кудыра да торба буйлап аларны кире шул цехларга җибәрә. Зур краннарны ачып-ябып, суларны суыртып агызу өчен нәкъ менә шул яп-яшь кызлар – аппаратчылар җаваплы була. Заводтан бер генә тамчы су да чистартылмыйча чыгарга тиеш түгел! Хәзер инде заводның очыш-сынау станциясендә урнашкан заманча чистарту корылмалары Фәридә апа эшләгәннәре белән чагыштыра торган түгел. Җыйнак кына заманча корылмалар чистарта җитештерү суларын.

– Эшкә урнашуга тулай торакта урын бирәләр иде ул вакытта. Шуңа яшьләр заводка килгәндер инде. Юнгородок дип аталучы бистәдә никадәр яшь эшче, яшь гаилә яшәгәндер! Иртә белән проходнойдан Каравай бистәсенә кадәр чират сузыла иде. Бик күңелле эшләдек. Бәйрәмнәрне, туган көннәрне бергә уздырабыз. Ул чакта сменалап та эшли идек әле. Бер гаилә кебек идек без. Завод эчендә дә, заводтан чыксаң да шул бер мохит, бөтен кеше бертөрле, бер шәһәр кебек иде. Әнә шулай囲 эштә таныштык инде Һарун белән, – дип дәвам итә Фәридә апа.

– Әйе, күз төште Фәридәгә. Ошаттым инде. Без, егетләр – бер компания, кызлар да оешып йөриләр иде. Эштән соң тулай торакка да шулай бергәләп кайтабыз. Алар – кызларныкына, без – егетләрнекенә. Кичләрен урамда йөрергә чыгабыз. Ял көннәрендә Социаль шәһәрчек паркында «пятачок»та очрашып, биибез, җырлыйбыз, походларга барабыз. Озак та очрашып йөрмәдек, бер елдан өйләнештек.

Заводтан фатир алганчы бергә яшәп торыр урын да тиз табыла. Бер әбигә йортка кереп, дус-тату яши башлыйлар. Йорт-хуҗалыкта ир кулы тимәгән җирләрне торгыза, рәткә китерә, капкасын төзәтә, суын кертә Һарун абый. Кызлары Ләйсән дә шул йортта туа әле. Үз әбиләре кебек якын кешегә әйләнгән йорт хуҗасына Ләйсән «әбекәй» дип дәшә башлый хәтта. Фатир да озак көттерми. Цехта тырышлыгы белән аерылып торган Хөсәеновлар гаиләсе беренчеләрдән булып үз почмакларына ия була.

Фото: Анна Арахамия



■ 2019 елда «Безнең заман» фестивалендә Гран-при алу мизгелләре (*Данис белән Илиана аскы рәттә сулдан беренчеләр*).

Фото: «Созвездие-Йолдызлык» фестиваль хәрәкәте архивыннан.

Төзелеш тизрәк барсын өчен, фатир бирелгән эшчеләр үзләре дә төзелештә катнашырга тиеш була. Харун абый да шунда ашкына. Тиздән улы да туасы бар – ашыктырасы килә бит! Өлгерәләр. Уллары Данис яңа фатирда туа инде. Ләкин болгавыр еллар башланып, хезмәт хакы белән авырлыклар башлангач, Һарун абый башка эшкә китәргә мәҗбүр була. Берничә елдан кабат кайтачак әле ул...

Фәридә апа инде үз гаиләсе кебек якынаерга өлгергән коллективыннан аерылырга уйламый да. 35 ел буе эшенә тугры калып, лаеклы ялга чыга. Авиация заводында эшләп, Авиатөзелеш районында яшәп, авиатөзүче туганнарың белән аралашып, пенсиядә булып та заводтан аерылу мөмкин эш түгел. Бергә эшләгән дуслары белән телефон аша сөйләшеп, цех яңалыкларын белешеп кенә тора. Кемне кая күчергәннәр, кайда яңа установкалар куйганнар, кайсы җиргә ремонт ясаганнар – барысы белән дә кызыксына Фәридә апа. Бәйрәм табынына утырсалар да, кунакка йөрешсәләр дә, сүзләр һәрвакыт завод хәлләренә кайтып кала. Хезмәт юллары туктап тормый да бит әле. Хөсәеновлар династиясен уллары Данис, киленнәре Илиана дәвам итә.

– Авиация заводының очышсынау станциясеннән очкыч һавага күтәрелгәнче үк двигатель тавышыннан кайсы самолет икәнен аерам. Алай гына да түгел, аның борт номерын, ничәнче машина булуын да беләм. Әйе, очкыч булса да, бездә аларның һәрберсен фәләненче машина дип йөриләр. Машинаның төп эш атамасы ул. Һавага күтәрелгән очкычның мин эшләгән өлеше күзгә күренмәсә дә, үзегендә, – ди Хөсәеновлар династиясенең яшь буын вәкиле инженер-конструктор Данис Хөсәенов.

П. В. Дементьев исемендәге Казан авиацион-техник колледжын тәмамлаган егет эш урыны эзләп, туры заводка юл тота. Унике ел дәвамында төрле вазыйфа башкарырга туры килә Даниска. Ту-22М3 бомбардировщикларын җыю һәм мордернизацияләү цехында эшләп, зур тәҗрибә туплый ул. Хәрби очкычның кайсы җирендә нинди заклепка урнашканын, аларның арасы ничә сантиметр булырга тиешлегенә кадәр өйрәнергә туры килә хәтта. Бүген Данис конструкторлык бюросында инженер-конструктор вазыйфасын башкара.

Илиана да, кайнанасы кебек, заводка очраклы гына килеп урнашкан диярга дә булыр иде. Кулына КХТИ дипломы алгач, үзе турында белешмәне шәһәрнең берничә заводына биреп карый. Авиатөзелеш заводыннан «туры килмисез, безгә КАИ дипломы кирәк», дип озаталар кызны. Ләкин берничә көннән шалтыратып, чакырып та алалар. Шулай итеп, Азнакай кызы инженер-технолог Илиана үзенең беренче эш көнен цехта башлап җибәрә. Данис белән ике цех арасында коридорда еш очраша торган булалар. Бөдрә чәчле сөйкемле кызны күңеленә салып куя егет. Ләкин икесенең берсе дә күзгә-күз очрашып йөрүдән ары китәргә җөрьәт итми. Анысын вакыт хәл итә. Ике елдан соң!

– Отпусктан чыккан идем генә әле. Заводта эшләүче иҗади яшьләрне «Безнең заман» республика фестивалендә катнашырга җыялар, җыелышка син барасың, дип әйттеләр. Мәктәптә укыганда бию белән шөгыльләнгәнемне беләләр иде инде хезмәттәшләрем. Баргач, Илиананың да килгәнен күрдем, – дип искә ала Данис.

– Ә мин кечкенәдән музыка мәктәбендә укыдым, хорга йөрдем. Шулай ук үземне сынап карыйсым килде. Республиканың төрле оешмаларында, заводларда эшләүче яшьләр арасында беренче тапкыр узачак масштаблы конкурс мине бик кызыксындырды. Җыелышта команда туплап, җиң сызганып конкурска әзерли башладылар безне. Данис белән икебез дә командага кердек, – дип дәвам итә Илиана.

Шул көннән башлап ике сменада эшләүгә күчә алар. Чөнки эш көне тәмамланганнан соң иҗади хезмәтләре башлана гына бит әле! Профессиональ хореографлар, вокал буенча белгечләр әзерли яшьләрне конкурска. Ни кызык, Данис белән Илианага бер генә тапкыр да бергә биергә туры килми. Бер-берсенең барлыгын тоеп, иңгә-иң куеп диярлек әзерләнәләр, репетиция ясыйлар. Әле дә дуслыктан ары китми мөнәсәбәтләре.

– Безне конкурска әзерләүче остазларыбыз барысын да үз кулларына алырга була, күрәсең. План корып, Илиананы миңа «димли» башладылар. Без икебез дә заводның «Яшьләр советы» әгъзалары. Фестивальгә әзерләнүдән тыш, төрле чаралар уздырабыз, бәйрәмнәрдә чыгыш ясыйбыз, туристик слетларга, елга буйлап сплавка чыгабыз. Туры китерәләр бит шулай – кая барырга кирәк булса да, икебезне бергә җибәрәләр! Соңга калсак, мин Илиананы озатып куям. Ничектер сизелми дә диярлек кавышып та куйдык шулай, – дип елмая Данис.

Авиатөзелеш заводында тупланган «Авиатор» коллективы «Безнең заман» эшләүче яшьләр республика фестивалендә ел саен катнаша.

Бер җиңү икенчесен алыштыра. Фестивальнең иң мәртәбәле бүләген – Гран-прины 2019 елда ала коллектив. Ул вакытта Хөсәеновлар инде ир-хатын статусында чыгыш ясап ирешә бу җиңүгә.

– Фестиваль юлын узганда коллективта дүрт гаилә туды! Без инде берберебез белән туганлашып та беттек бугай. Туйларга йөрибез, иҗади чыгышлар ясап яшь гаиләне котлыйбыз. Күңелле, якты, вакыйгаларга бай чор иде ул! Бу кичерешләрне, хисләрне эшебез бүләк итте бит. Ә кемдер завод кына, ди. Безнең гаиләдә «Завод бит ул!» дияргә күнегелгән. Ышанычлы, нык, киләчәге бар... Аны безнең тормыштан аерып та булмый инде хәзер. Мин хәтта китеп тә карадым заводтан. Ләкин бер ел да узмады, кабат әйләнеп кайттым. Заводтагы стабильлек, регламент белән эшләү тәртибеннән соң шәхси оешмалардагы эш тәртибенә ияләшү җиңел түгел икән. Ә монда барысы да җайга салынган, системага куелган. Гаилә дусларыбызның да күпчелеге бергә эшләгән, бергә чыгыш ясап йөргән завод яшьләре, – ди Данис.

– Туган көнгә җыелышсак та, котлауларга унбиш минут вакытны гына багышлыйбыз да яңадан завод тормышына әйләнеп кайтабыз. Кемдә нинди яңалык, нинди заказлар кабул ителгән, кайсы цехта нинди вакыйга булган, кая яңа җитәкче куйганнар – сөйләшмәгән бер генә тема да калмый. Тагын заводка күчтек бит инде дип, көлешеп алабыз, – дип хуплый иренең сүзләрен Илиана.

Данис белән Илиананың кызлары Инарага дүрт кенә ай әле. «Теләге булса, династия эшен ул да дәвам итәр, каршы килмибез, көчебездән килгәнчә ярдәм итәчәкбез, – ди яшь әти-әни. – Заводта балалар өчен уздырылган бер генә конкурсны да калдырмаячакбыз, анысы һичшиксез. Менә балаларны яклау көне уңаеннан уздырган рәсем бәйгесеннән үк башларбыз!»

Сабый әле үзен алда ниләр көтәсен белми. Ләкин бөтен тормышлары завод тирәсендә кайнаган әти-әнисен, әби-бабасын күреп, ул да үз хезмәт юлын сайлаганда икеләнеп тормас кебек. Бу гаиләдә канат куя беләләр...





Илшат ГАНИЕВ, С. П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы – ПАО «Туполев» филиалының профком рәисе

Казан авиация заводы һәрвакыт үзенең тырыш хезмәт династияләре белән аерылып торды. Заводта эшләүнең үз романтикасы бар кебек. Бер килеп кергәч, яңа гаиләңне тапкан кебек буласың. Күп очракта шулай була да – яшьләр үз тиңен табып, кавышалар, гаилә коралар. Андыйлар өчен завод яңа бер төсмер, тирәнрәк мәгънә ала. Проходнойдан чыгып, өйгә кайтып китү белән генә чикләнми аларның мөнәсәбәте, гаиләнең үзәгенә үтеп керә, буыннан-буынга күчә, гасырларга сузыла.

Заводта эшләүче династияләр, чыннан да, безнең горурлыгыбыз. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы уздыра торган «Хезмәт династиясе» бәйгесендә ел саен җиңүгә ирешә бездә эшләүче гаиләләр. Быел җиңгән Хөсәеновлар династиясе дә – шундый абруйлы, хөрмәтле гаиләләрнең берсе. Аларныкы кебек гаиләләр – заводның алтын баганалары. Җитештерүнең төп күләме дә, заводның киләчәге дә шундый тугры гаиләләр җилкәсендә. Хөсәеновларның һәр яңа буыны алдагыларына караганда да талантлырак: башкача фикерлиләр, яңа үрләр яулыйлар, эшне дә, иҗатны да бергә алып баралар. Данис белән Илиана төрле дәрәҗәле конкурсларда завод данын яклап чыгыш ясыйлар, исемебезне таныталар. Илиананың заводка эшкә урнашырга килгәнен әле дә хәтерлим. Әтисе белән соң гына килеп керделәр алар минем кабинетка. Инженер-технолог булып урнашкан иде, хәзер технологияләр җитәкчесе вазыйфасына кадәр үсте. Бик матур җырлый да әле ул!

Яшь гаиләнең хезмәт юлы башлана гына әле, бөтен мөмкинлекләр ачык алар алдында. Хөсәеновлар династиясенең күркәм традицияләре аларның балаларында, оныкларында дәвам итсен иде!





Килен һәм кайнана… Ике арадагы мөнәсәбәтләрнең матурлыгы, ныклыгы, якынлыгы күбрәк кемнең зирәклегенә, акылына, тырышлыгына бәйләнгән? Иреңнең әнисе үзеңнекеннән тары ярмасы кадәр генә ким булырга тиеш, диелгән динебездә. Ә менә сез моңа ничек ирештегез? Нинди сынаулар, нинди юллар аша уздыгыз? Сөйләгез әле! Башкаларга – бигрәк тә яшьләргә гыйбрәт, сабак, үрнәк итеп сөйләгез.

«Сөембикә» журналы белән берлектә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен үстерү мәсьәләләре комиссиясе игълан иткән «Килен һәм кайнана» дигән хатлар конкурсы тәмам. Бәйгегә килгән хатларның калганнары белән журналыбызның сайтында таныша аласыз.

КОДАГЫЙЛАР ДА БЕР ӨЙДӘ



Татар халык авыз иҗатында килен-кайнана мөнәсәбәтенә бәйле әйтем-мәкальләр шактый. Шулай да күңелемә «Килен – кайнана туфрагыннан» дигәне якын. Ни генә димәсеннәр, ир-ат гомерлек ярын әнисенә охшатып сайлый дип уйлыйм. Әле үзем кайнана булырга җитешмәсәм дә, ике әнием – Суфия һәм Разия хакында бу язмам.

Еллар, еллар... Кай арада узалар да тарих битләренә күчә соң алар?.. Үзләре белән маңгайга сырлар, чәчләргә чал гына түгел, тормыш тәҗрибәсе дә алып киләләр. Менә хәзер дә әниемнең «Үзең әни булгач аңларсың әле», дигән сүзе колагымда яңгырап тора.

Узган гасырның 80 нче елларында мин, Арча педагогика училищесын тәмамлап, юллама буенча Алексеевский районы Зур Тигәнәле авылына кайттым. Мәктәптә балалар күп чак, коллектив дус, тату. Бер йодрык булып тупланып, бик күңелле яшәдек без ул елларда: өлкән хезмәттәшләребез тәҗрибәләрен оста итеп уртаклаша, яшь укытучыларга чын остаз була белделәр. Шул ук вакытта эш белән генә дә чикләнмәдек: буш вакытларны да күңелле уздырдык, кичләрен дә матур итеп ял итә белдек. Клуб-китапханәләрнең дә әле гөрләп эшли торган чагы бит. Шундый чараларда гомерлеккә булачак дуслар тупланган, ә оста куллы, яшел күзле Равилемнең исә ниятләре зуррак булып чыкты. Юллама вакыты тәмамланып, инде үз туган ягыма кайтып китсәм дә, мине эзләп, тәкъдим ясарга килеп җитте.

Әле дус булып йөргән чакларда ук: «Булачак кайнанаңның бик усал икәнен беләсеңме соң?» – дигән сүзләр килеп ирешкәли иде. Шулай да ике йөрәккә кавышырга язган булса, кеше сүзенә генә игътибар ителми. 1985 елның августында гөрләтеп туй ясадык. Тигәнәле җиренә инде яңа статуста аяк баскан чакта әкрен генә яңгыр сибәли иде. Шуңа үзем дә, авыл халкы да моны хәерлегә юрадык кебек. Яңа гаиләгә керү кызлар өчен шактый читен була диләр, тик мин Разия әнигә бик тиз ияләштем. Кеше сүзе кеше үтерә, диләр, ярый әле колак салмаганмын. Әни бервакытта да усал сүз әйтмәде, хәтта кырын итеп караганын да хәтерләмим. Бик яшьли үз әнисен югалтып, үги ана белән яшәгән ул, кырык яше тулыр-тулмас өч бала белән тол калып, аларга җил-яңгыр тидермичә үстерү өчен нинди авырлыклар кичерүен үзе генә белгәндер. Фермада авыр физик хезмәт куеп кайткан хатын сыер-сарыгын да, тавык-казын да асраган. Ә аларга азык юнәтү, ай-һай, авыр булган бит ул елларда. «Бервакыт, кешеләр йоклап беткәч, күрше Зәйнәп апа (анысы да тол хатын, өй тулы бала тәрбияли) белән аз булса да салам алып кайтырга дип, кырга киттек. Инде кайтырга таба борылганда, бер дә көтмәгәндә буран чыкты бит. Адаштык. Белгән догаларыбызны укып, күпме әйләнеп йөргәнбездер, Ходай Тәгалә ярдәме белән кайтып җиттек авылга. Балалар хакына исән калганбыздыр инде», – дип, елый-елый искә ала иде ул авыр елларны.

Бакчасын да утырткан, кул эшләрен дә эшләгән. Гомеренең иң матур чагына – яшьлегенә туры килгән сугыш елларында окоп казырга, урман кисәргә йөрүләрен сөйләгәндә дә әниебезнең күзләренә яшь килә иде. Туйганчы ашарга ризык, кияргә юньле кием булмаса да, тыл хезмәтчәннәре дә җиңү өчен үзләреннән шактый өлеш керткән. Олыгайган көнендә шул чакта туңдырган аяк бармакларының сызлаулары үзәгенә үтсә дә, әни бервакытта да зарланмады, бары тик дуска түгел, дошманга да без күргәнне күрергә язмасын дип тели иде.

Гап-гади авыл кешесе булды әни, авылдан чыгып әллә кайларга да бармады, әллә нинди байлыкларга да кызыкмады. Миңа да килен кеше – ким кеше дип карамады. Һәр эшне бергәләп, киңәш-табыш итеп башладык. Олыгайганчы кулыннан орчыгы, бишинәсе төшмәде: балаларны да, үзебезне дә оекбаш-бияләйдән өзмәде. Каз бәлешенең, кабак бөккәненең тәме хәзер дә авызда тора. Тормыш булгач, декрет ялыннан соң эшкә дә бик иртә чыктым. Ул чакта да кыз-улыбызны карау-тәрбияләүдә әни зур терәк булды. Оныкларын бик ярата иде ул. Балалар үсеп, Казанга укырга киткәч тә шатланып каршы ала, китәр вакытлары җиткәч, изге теләк теләп озатып кала иде. Балалар да дәү әниләренә игътибарлы булдылар.

Туган нигеземнән 15 яшем тулыр-тулмас чыгып киткәнгә күрәдерме, ризыгым туган авылымнан шактый еракта булгангамы, гомеремнең күбрәк өлеше Тигәнәледә уза минем. Ирем Равилгә дә, әнигә дә бик рәхмәтлемен. Туган авылым Кычытканлыга (Нурлат районы) әти-әниемнең хәлен белергә барасым килгән саен, каршы төшмәделәр, әле үз машинабыз булмаган чакта да җаен таптылар, йорт-җиргә дә күз-колак булдылар. Әни-әтием безгә утырмага килгән чакта да кода-кодагыйларның сөйләшер сүзләре бетмәс иде. Шуңа күрә килен генә охшамыйдыр ул кайнанага, яшьләр тормышында кодагыйларның да бер уйда булуы мөһим дип уйлыйм.

Хәтерем юк, күзем күрми, картайдым дисә дә, гомеренең соңгы көннәренә кадәр күзлексез газета укыды, фәлән елның фәлән көнендәге вакыйгаларны бәйнә-бәйнә сөйләп бирер иде әни. Хәл белергә кергән һәр кешене изге теләк теләп озатыр иде. Сәламәтлеге мөмкинлек биргәнчә биш вакыт намазын укыды, уразасын тотты ул. 92 яшь тулырга санаулы көннәр калгач, матур гына мәңгелеккә күчте. Догаларыбыз барып җитәдер, урыны оҗмахтадыр дип өметләнәбез.

Кулга каләм алгач, дәвам итим әле. Әнием Суфиянең дә балачагы кайнанам – Разия әни тормышына бик охшаган. Сугыштан соңгы авыр елларда авырлы әнисе бәбили алмыйча вафат була. (Бала табар вакыты җиткән әбине Кычытканлыдан ат белән башта Мамыкка, аннары Биләргә, анда да ярдәм итә алмагач, Чистайга алып китәләр. Әмма Мөслим авылына җитәрәк әбиебез, өч баласын ятим калдырып, соңгы сулышын ала. Ике җан – ана һәм аның карынындагы бала мәңгелеккә күчә.) Балаларга – әни, үзенә иптәш булыр диптер инде, бераз вакыттан соң бабай балдызына өйләнә. Өч бала янына бер-бер артлы тагын өч бала дөньяга килә. Шулай итеп, өлкән бала буларак, әнигә дә яшьтән үк тормыш арбасына җигелергә туры килә. Мәктәпне уңышлы гына тәмамлагач, Казанга укырга китә ул. Кешене ризыгы йөртә шул – авырып китеп, кире кайтырга мәҗбүр була. Озакламый авылдаш егете – әтием Әсхәт белән кавыша, һәм 40 елга якын кайнана белән яши. Аңлашып яшәделәр алар зур әни Сафия белән. Әти бердәнбер бала иде. Шулай да ул да иркә кочакта үсми. Сугыш аркасында ятим калып, ул да бик яшьли тормыш куа башлый.

«Балалар хакына исән калганбыздыр инде», – дип, елый-елый искә ала иде Разия әни ул елларны.

Шуңа күрә әти-әнием бер-берсе белән аңлашып, авырлыкларын да бергә күтәргәннәр, шатлыкларын да уртак иткәннәр. Биш баланы аякка бастыру җиңел булмагандыр ул елларда да. Әмма авыл халкы алдында аларның йөзләре ак булды: тормыш булгач, бәлки, төрле чаклар булгандыр, шулай да табак-савыт шалтыраган тавыш урамга чыкмады, булганына шөкранә итеп яшәделәр.

Нинди җирдә эшләсәләр дә, икесе дә намус белән хезмәт иттеләр. Гектарлаган шикәр чөгендерен эшкәртү, кирпеч заводында кирпеч сугу гына түгел, букчасын иңенә салып авыл буйлап почта таратып йөрү дә җиңелләрдән булмагандыр әнигә. Ул вакытта бит әле авылда да кеше күп, барысы да газета-журнал да укый, бәйрәм тирәсендә котлау открыткалары йөзләп кенә килми иде... Ә өйдә берсеннән-берсе кечкенә биш бала. Шулай да, әче таңнан торып эшкә китсәләр дә, балалар өчен күңелләре тыныч булды аларның – өйдә зур әниебез булгач, ишеккә йозак эленмәде. Күрү сәләтен югалткан булса да, зур әниебез үзе дә тик тормады, безне дә эшкә өйрәтте. Әти-әни эштән кайткан җиргә кайнар аш әзер, йорт-җир каралган булыр иде. Шул рәвешле, килен – кайнана, кайнана килен рәхәтен күргән дип көлешәбез хәзер дә.

«Киңәшле эш таркалмас», диләр бит. Нинди генә эшкә тотынсалар да, әти-әни зур әни белән киңәшләшеп эшләделәр, шулай булырга тиеш дип безгә дә сеңдерделәр. Үз гомерләрендә әтием белән әнием ике өй салып чыкты. Зур әниебез эшләгәннең бәрәкәте булсын дип дога кылгангадыр, шөкер, рәхәтен дә үзләре күрергә өлгерде. Башта зур әниебезнең урыны өйнең түрендә булса, соңрак әти-әни үзләре шунда күчте.

Зур әнине олылап соңгы юлга озаткач, берничә елдан соң әниебез үзе кайнана булды. Әни белән балачакта бергә уйнап үскән, шактый еллар бергә эшләгән Мәдинә апаның кызы Гөлүсә энебез Азатны гомерлек яр итте. Егерме елдан артык яшәү дәверендә алар турында бер генә дә начар сүз әйтеп булмады, Аллага шөкер. Әнинең пешергәнен дә, Гөлүсәнең әзерләгәнен дә мактый-мактый чәй эчүләре генә дә ни тора бит. Түгәрәк өстәл артында көндәлек эшләргә йомгак ясала, иртәгесе көнгә нәрсә эшлисе сөйләнә. Бәхет өчен күп кирәкме?! Шуның өстенә дүрт яктан дүрт кыз гаиләләребез белән төп йортка җыелабыз бит әле. Бер мәртәбә генә караңгы чырай күрсәтсәләр, икенче тапкыр бара алмас идең туган йортка да. Ходайның рәхмәте яусын энебез белән киленебезгә (хәер, Гөлүсәне бишенче кыз туганыбыз итеп күрәбез): ачык йөз белән каршы алалар, тагын килегез дип озатып калалар.

Җәлил хәзрәтнең сүзләре хәтердә яңара: «Яшь киленгә авыз ачып сүз әйтәсе булмагыз, чөнки ул төп йортта кала. Каядыр кунакка барсам, мин күчтәнәчне үз кызыма түгел, ә яшь киленгә алып кайтам. Чөнки олыгайган көндә ул безгә чәй ясап эчертә», – дип әйтә ул. Ир-ат, мең сәбәп табып, өйдә тормаска мөмкин, ә килен кала. Ирнең олыгайган әти-әнисенә кадер-хөрмәт күрсәтү, чәй куеп эчертү – бар эш киленгә төшә. Шуңа күрә килен белән дус булырга кирәк. Безнең әти-әни дә беренче көннән якын итте, бишенче кызлары урынына күрде Гөлүсәне. Бер генә мисал китерим: без өйгә берәр нәрсә алырга уйласак та, Гөлүсәгә дә кирәк, аңа да алыгыз, дияр иде. Үз итүен шушы гади мисалдан да аңлап була дип уйлыйм. Гөлүсәбез дә: «Әтиемне хәтерләмим дә диярлек. Шуңа күрә кияүгә чыгуым тулы гаиләле булып, бәхетле яшәргә мөмкинлек бирде», – дип, рәхмәт сүзләре белән искә ала олыларны.

Бер-бер артлы дөньяга аваз салган Гөлкәй белән Айсылу да төп йортка ямь өстәде. Туган оябыздан очып киткәнгә инде ярты гасырлап вакыт узса да, җай чыккан саен шунда ашыгабыз. Хәер, без генә дә түгел. Нәсел җепләре Кычытканлы белән бәйле туганнарыбыз да шунда җирләнгән әти-әниләренә зыярәт кылырга, рухи көч тупларга кайтып тора.

Тормыш шундый инде: әти дә, әни дә бер-бер артлы мәңгелеккә күчте. Әмма алар балалар игелеген күреп, тыныч күңел белән бәхиллекләрен биреп киттеләр. Әти-әни нигезе бүген дә гөрләп тора: Азат белән Гөлүсә гаилә традицияләрен дәвам итеп яшиләр. Олыгайган көннәрендә дә сәламәт, бәхетле булсыннар иде алар.

Өлкәннәрнең куанычы – дәвамчылары булуда. Инде үзебез дә дәү әни, дәү әти булып җитештек, үзебез оныклар рәхәте күрәбез. Шулай да үзебез бала чакта алган гыйбрәтләр һаман күңелдә. Әниемнең бүгенге яшьләргә дә, кайнана булырга җыенган аналарга да кирәге чыгарлык бер сүзен җиткерәсем килә. Дүрт хәрефле гади генә «ярар» дигән сүз ул. Нинди генә тормыш авырлыклары булса да, «ярар, монысы да узар», дия иде әнием. Кайгы да, шатлык та адәм баласына гомерлеккә бирелми шул. Чыннан да, мәшәкатьле чаклар да булмый тормады, бәхеттән елаган-елмайган вакытлар да шактый булды, әниемнең артык шатланмый яисә хафаланмый торганына (әченнән янса да, безгә күрсәтмәгәндер инде, бәлки, сабырлыгы алтын белән бер иде), зирәклегенә хәзер дә гаҗәпләнәм әле. Шуңа күрә үз гаиләмдә дә шул сүз шактый еш яңгырый. Ярар, узар...

Хәзер дә әниләр турында сүз чыкса, инде өченче буын киленнәр дә: «Бу гаиләгә килен булып төшсәм иде, бигрәк сабыр дәү әниле булыр идем дип уйлый идем», – дип искә алалар. Бу да бит үзенә күрә бер күрсәткеч.

Уза икән шул, гомерләр дә үтеп китә икән. Инде әти-әниләребезне мәңгелек йортларына озатканыбызга да берничә ел узды. Сагынып сөйләр мизгелләр, сабак булырлык гыйбрәтләр тормыш тәҗрибәсенә әверелеп бара. Ә иң мөһиме – әниләр, кайнаналар биргән тәрбия традицияләре буыннар аша дәвам итә.

Фәния НАСЫЙХОВА.
Алексеевский районы, Зур Тигәнәле авылы.

Фотода кайнанам Разия, әтием Әсхәт, әнием Суфия.

БЕРГӘ БУЛЫЙК!

Киләсе елга «Сөембикә» журналына 110 ел тула!
Бу безнең өчен дә, сезнең – аның тугрылыклы укучылары өчен дә зур бәйрәм. Ә бәйрәм бүләксез булмый!

2023 ел (6 ай, 12 ай) өчен «Сөембикә» журналына язылып, квитанция күчермәсен редакциягә юллаучылар арасында түбәндәге бүләкләр уйнатыла:

ЙӨЗ УН!

/ **мультиварка** (2 данә)
/ **электрогриль** (2 данә)
/ **электр иттарткычы** (2 данә)
/ **планетар миксер** (2 данә)



Ә 2023 ел өчен бер елга журналга язылып, квитанция күчермәсен иң беренчеләрдән булып редакциягә юллаган 110 абунәчебезнең һәркайсы махсус бүләк алачак. **«Матурлык сандыгы»**!

Квитанцияләр 2023 елның 20 гыйнварына кадәр кабул ителә.
Бүләк уйнату 23 гыйнвар көнне узачак.

Квитанция күчермәләрен редакциягә җибәрүнең берничә юлы бар:
почта аша: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт
редакциянең электрон почтасына: ssuum@yandex.ru
ватсап номерына: 8(937) 288-18-01

«Сөембикә» журналы – Әниләр көненә иң затлы һәм иң мәгънәле бүләк!

АО «ТАТМЕДИА» реклама 16+

ҮКЕНЕЧЛЕ ЯЗМЫШ





Тәэминә БИКТИМИРОВА,
тарих фәннәре кандидаты

Тарихка гражданнар (ватандашлар) сугышы дип кереп калган сугышның татар халкына кагылышлы өйрәнелеп җитмәгән вакыйгалары, ачылмаган сәхифәләре бүгенге көнгә кадәр бар әле. Бу сүзне бигрәк тә армиядә медицина-санитария хезмәте күрсәтүчеләрне күздә тотып әйтәм. Чөнки армиядә табиблар, шәфкать туташлары, санитарлар булмаса, алар тырышлыгы белән йөз меңнәрчә яралылар яңадан армиягә кайта алмас иде. Ни булганын күз алдына китерү дә кыен... Мисал өчен, I Бөтендөнья сугышында яраланган офицерлар саны барысы 27 меңнән артык, ә солдатлар 2 миллион ярым тирәсе дип исәпләнгән (контузия алучылардан башка). Шулардан офицерларның – 14 меңе, солдатларның 1 миллион 800 е, яралары төзәлеп, кире сафка баса алган. Моннан тыш, фронтларда төрле-төрле йогышлы авырулар, эпидемияләр килеп чыгуын да әйтсәк, медицина хезмәте күрсәтүчеләрнең фидакарьлекләрен бәһаләп бетерүе тагын да кыенлаша. Гражданнар сугышы елларында Кызыл Армиядә генә 1 миллион 300 мең кеше тиф белән авырган.

Бу сугышларга, бигрәк тә мондый җан өшеткеч хәлләргә, хәзерге тарихчыларның бәяләре төрлечә. Аларга тукталып тормастан, татар хатын-кызларының илгә афәт килгәндә ирләр белән бер сафка басулары хакында сөйләүгә күчәм.

«Беренче империалистик сугыш башлану белән Санкт-Петербургтагы хәйрия җәмгыяте тиз арада «яралылар өчен лазарет ачарга... һәм шәфкать туташлары итеп мөселман кызларын да чакырырга карар кылды» дип язган «Каспий» газетасы 1914 елның 9 август санында.

Мондый хәл Казанда да күзәтелә. 1914 елның 31 сентябрендә шәһәрнең 200 дән артык иң абруйлы кешеләре «Новый клуб» залында җыелып, яралылар өчен хастаханә ачу хакында сөйләшәләр. Мәҗлесне Галимҗан хәзрәт Галиев (Баруди) ача һәм рәислеккә Габдулла хәзрәт Апанаевны тәкъдим итә. Коръән уку белән башланып киткән мәҗлеснең ахыры да бик уңышлы тәмамлана. Тиз арада хастаханә ачу өчен җитәрлек акча да җыела, оештыру комитеты да төзелә. Безнең өчен тагын да мөһимрәге шул: оештыру комитетына татар хатын-кызларыннан ике табибә тәкъдим ителә. Болар – Мәһипәрвәз Дәүләткилдиева һәм Суфия Коләхмәтовалар. Алар икесе дә яралыларны дәвалауда искиткеч тырышлык күрсәтәләр.

Гражданнар сугышы башлангач, Казан хәрби медицина үзәгенә әверелә. Шәһәрдә сугышка кадәр үк төрле дәвалау учреждениеләре, шул исәптән, Россиядә иң абруйлылардан саналган хәрби госпиталь, атаклы галимнәре белән танылган университетның медицина факультеты булуы да сәбәп булгандыр. Тиз арада яңа хастаханәләр, дезинфекция отрядлары оештырыла. Шәһәрне чистарту өчен мәҗбүри хезмәт кертелә, санитарлар өчен махсус курслар оештырыла, армиягә, яраланучыларга ярдәм итә алган һәрбер кеше исәпкә алына.

Әмма гражданнар сугышының сыйныфлар сугышы икәнен дә истән чыгарып булмый. Табиблар,

1920 елда Кызыл Армиядә хезмәт итүче шәфкать туташларының саны 10 830 га җитә.

шәфкать туташлары һәм хәтта санитарлар да кызыл сугышчыларны тәрбияләүдән баш тарткан. Коммунистлар партиясе шәфкать туташлары һәм санитарлар курсларына язылуны сорап, халыкка мөрәҗәгать белән чыгарга мәҗбүр була. Еш кына бу курсларга укыйяза белгән кызларны, бигрәк тә мөгаллимәләрне мобилизация белән дә алып китәләр.

Мәҗбүри түгел, ә йөрәге кушканга һәр ике сугышта да (I Бөтендөнья, гражданнар сугышы) шәфкать туташы булып яралыларга ярдәм күрсәткән Тальковская Зинаида Александровна (Зөләйха Искәндәр кызы) хакында язарга теләгән идем бу язмада.

1890 елның 4 маенда Австрия чигендә урнашкан Келецк губернасы Меховск өязе Новобрежск бистәсендә туа ул. Әтисе – Вилен губернасы Ошмянск өязе Кырык Татар авылыннан чыккан литва татары, патша армиясе генералы Искәндәр Осман улы. Әнисе – Елизавета Степановна Сулькевич – татар ротмистры кызы, укытучы.

Искәндәр Осман улының гаиләсендә ике кыз – Дейли (Елена) белән Зөләйха (Зинаида) һәм ике ир бала туа. Уллары Михаль (Михаил) чик саклаучы берләшмәнең ротмистры, соңрак Азәрбайҗан армиясе офицеры була һәм 1924 елда Баку шәһәрендә үлә. Икенче уллары Искәндәр Тальковский – киләчәктә Кызыл Армия генералы дәрәҗәсенә күтәрелә, ә аннан репрессиягә эләгә һәм 1942 елның февралендә атып үтерелә.

Әйтеп үтик, татар халкының талантлы баласы Искәндәр Тальковский хакында тарихчы галим Дамир Шәрәфетдиновның «Карурман аша ла башлар адаша...» дигән тарихи-документаль очеркы чыкты. Рәхмәтебез рухына шатлык өстәсен.

Зинаида (сүземне Зөләйха исеме белән дәвам итәм) Ригада гимназия тәмамлагач, Санкт-Петербургтагы Югары медицина курсларына (соңрак Медицина институты итеп үзгәртелә) укырга керә. I Бөтендөнья сугышы башлангач, студенткаларның күбесе (алар арасында Зөләйха да бар) шәһәрдәге госпитальләрдә шәфкать туташлары булып хезмәт итә башлыйлар. Зөләйханың искиткеч таланты аңа эшләргә дә, укырга да мөмкинлек биргән.

Шушы чорда ул Казанның атаклы бае Мөхәммәтшакир Апанаевның улы Якубны очрата. Якуб бу вакытта Петроградтагы укчы дивизиядә – Зөләйханың әтисе янында хезмәт итә. Ни кызганыч, Якуб Апанаевның соңгы еллары хакында КГБ (ФСБ) архивындагы шәхси эшен карый алмадым. Ул – репрессия корбаны. Нахакка гаепләнеп үтерелгәннәрнең эшләре ни өчен хәзергә хәтле серле сандыкта ятканнарын берничек тә аңлый алмыйм...

Октябрь революциясе Тальковскийларның язмышын кискен үзгәртеп җибәрә. Алар бернинди икеләнүсез совет власте ягына чыгалар. Гаилә башлыгы Искәндәр Осман улы Тальковский Петроградтагы 1 нче укчы дивизиянең бригада командиры итеп билгеләнә, ә аның улы Петроград мөселман батальоны командиры, ә 1918 елның гыйнварыннан шушы полкның командиры булып китә.

1919 елда Зөләйха белән Якуб – икесе дә әлегә бик бәхетлеләр, яратышып, Казанга кайтып өйләнешәләр. Зөләйха – инде атаклы Апанаевлар килене – документларын Петроградтан ала һәм Казан университетының медицина факультетына кабул итүләрен сорап гариза бирә. Моңарчы тиешле булган барлык имтиханнарын үз вакытында уңышлы биреп барган

PRESSA

кызны берсүзсез бишенче курска кабул итәләр.

Тик студентка булып университет аудиторияләрендә рәхәт чигеп йөрергә туры килдеме икән Зөләйхага? Ник дигәндә, 1920 елда Татарстан Республикасы төзелгәч, ил өстенә төшкән бәла-казаларны санап бетерерлек кенә булмый. Иң коточкычы – ачлык, янгыннар, тиф эпидемиясе... Татарстанның ил тоткасы булырдай барлык ирләре Төркестанда совет власте урнаштырып йөри. Зөләйханың энесе Искәндәр дә, ире Якуб та – шулар арасында.

Университет аудиторияләре бушап калгандай була...

Студентларны әле «Фронт атналыгы», әле «Кызыл сугышчыларның гаиләләренә ярдәм», әле «Кызыл хач җәмгыятенә ярдәм атналыгы» дип, җәмәгать эшләренә тартып торалар. Ач балаларны коткару эшенә дә студентлар чакырыла. Ул балаларны урамнардан, тыкрыклардан, вокзал тирәләреннән җыеп аласы, беттән арындырасы, мунча кертәсе, киемнәр табып киендерәсе, ашханәләр ачылса, алар өчен савыт-саба җыясы һәм тагын бик күптөрле эшләргә катнашасы була.

Зөләйха кебек уңган-булган студенткаларга да госпитальләрдә ихтыяҗ зур. Кулыннан эш килгәннәрнең хәтта табибларны алмаштырган вакытлары да була. Зөләйха да нәкъ менә шул вакытларда операцияләр ясый башламадымы икән?! 1925 елда Казан университетын хирург булып тәмамлый бит ул. Бәхетенә, Якуб та фронттан кайта.

Тик кеше бәхете озакка барамыни ул?! 30 нчы еллар җитә. Совет власте башта динчеләргә, соңрак үзе өчен көрәшүчеләргә, зыялыларга каршы ут ача. Якуб та, 1937 елда кулга алынып, 1938 елның башында инде атып үтерелә. Апанаевларның барысының да мөлкәтләре тартып алына, күбесе төрмәләргә ябыла, җидесе атып үтерелә.

Зөләйха апага яшәр өчен дөньяда нинди юаныч кына калды икән ул чакта? Ул 5 нче шәһәр хастаханәсендә гинеколог булып эшли. Хирург буларак операцияләр ясый. Студентларның практикасына җитәкчелек итә. 1941 елда шулай гадәттәгечә операция ясарга керешә, тик операция бик катлаулы булып чыга. Өстәл янында алты сәгать буе берүзе басып тора ул. Операциясен уңышлы тәмамлап чыкканда аягындагы тромблары шартлый... Утырып ял итәргә дә өлгерә алмыйча, татарның тагын бер талантлы кызы күзләрен мәңгелеккә йома...

Операцияләре уңышлы булып бетмәсә, «халык дошманы» хатынына гаеп тагарга да күп сорамаслар иде. Бәхетенә, һәр эше уңышлы килеп чыккан – төрмәләрдә тилмерергә язмаган.

Аның җеназасына килгән халык белән Мәскәү урамындагы (элеккеге Киров урамы) бакча халык белән шыгрым тулган булган. Казан халкы яраткан табибәләре Зөләйха Искәндәр кызы белән елап саубуллашкан.

Аның кабере – Иске татар зиратында. Нурания белән Илүзә Апанаевалар Зөләйха апаныкын да, Якубның башка туганнары каберләрен дә гел карап торалар. Калган истәлекләрен кадерләп саклыйлар. Рәхмәт аларга.



■ Сулдан уңга (утырганнар): Зөләйха Тальковская, Якуб Апанаев, Мөхәммәтшакир Апанаев, Хәдичә Исхак кызы Апанаева, Өммегөлсем улы Мәхмүт белән. Сулдан уңга (басканнар): Маһиәнвәр ире Ибраһим Апанаев белән, Нурмөхәммәт Усманов (Апанаев заводында бухгалтер).

АТА-АНА ДОГАСЫ



Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН, «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы

Ата-ана догасын иң олы дога дип әйтәләр, бу чынлап та шулаймы?

– Бик күптөрле догалар бар һәм аларның кайберләре турында Рәсүлебез (с.г.в.): «Аллаһы Тәгалә аларны кабул итә», – дип әйтә. Кабул булу ихтималы зур булган догалар берничә төркемгә бүленә. Мәсәлән, аның кайберләре доганың кылынган вакыты белән бәйле: яңгыр яуганда, яшен яшьнәгәндә, төннең ахырында, азан белән камәт арасында... Икенче төр мондый догалар кешеләр белән бәйле: әйтик, изге, тәкъва кешенең догасы. Аннан мәзлүм, ягъни золым күргән, рәнҗетелгән бәндәнең күңеле әрнегәндә кылган догасы кире кагылмас дигән хәдис тә бар.

Бу исемлеккә ата-ана кылган догалар да керә. Чыннан да, шулай – ата-ана догасыннан да олы дога юк. Моның сәбәбе бик гади: аларның балаларына карата кылган гамәлләрендә рия була алмый. Ата белән ана баласы өчен нәрсә генә эшләсә дә (ярдәм итү, бүләк бирү), алар аны беркайчан да нидер өмет итеп эшләми, яхшылыгыма яхшылык белән җавап бирер дип көтми. Һәм алар бервакытта да балаларына начарлык теләми, күңелләре изгелектә, яхшылыкта гына.

Баласы өчен әти кеше кылган дога әнисенекенә караганда тизрәк барып ирешә, диләр...

– Без, әлбәттә, шулай итеп ир-атларның дәрәҗәсен күтәрергә тырышабыз. Әмма бер хәдистән күренгәнчә, Рәсүлебез (с.г.в.) янына бер сәхабә килә дә: «Бу дөньяда иң зур мәхәббәт белән кемне яратырга кирәк?» – дип сорый. Рәсүлебез (с.г.в.): «Әниеңне», – ди. «Ә аннан соң кемне?» – дип сорый сәхабә. «Аннан соң да әниеңне», – дип җавап бирә Рәсүлебез (с.г.в.). Сәхабә һаман соравын дәвам итә. Дүртенче тапкыр сорагач кына Рәсүлебез (с.г.в.) безне – әтиләрне искә алган. Хәтта үзе ир-ат, ата булса да. Шулай булгач, әниләрнең дәрәҗәсе бәхәссез.

Аллаһы Тәгалә бик хикмәтле, ул – бу дөньяны яралтучы, бөтен нәрсәне тәртипкә салучы. Әйтик, әнисе рәнҗесә, баласы җәннәткә керә алмый. Ә әни кешедән – хатын-кыздан ире риза булмаса, ул да җәннәттән мәхрүм калырга мөмкин. Менә барысы да бер-берсенә ничек бәйләнгән, көйләнгән. Ир – баш, хатын – муен, дибез. Муен баш урынына менмәсен өчен, хатын-кыз җәннәте – ире ризалыгында, ә баланыкы – әнинекендә.

Аталар турында сүз барганда, диндә күбрәк алар кылган изгелек турында әйтелә. Ата кеше гаиләгә алып кайткан ипи кисәге дә әҗер-савап дип санала. Ә догада барыбер күбрәк әниләргә өстенлек бирелә. Бу урында безнең көннәргә килеп ирешкән бер риваятьне искә төшереп китәсе килә.

Борын заманда бер сугышчы булган. Ул сугыш мәйданына һич куркусыз, саклану чараларсыз – хәзергечә итеп әйткәндә бронежилет кимичә чыга торган була. Әйтеп-әйтеп карасалар да, берәүне дә тыңламаган. Ә беркөнне күрәләр: шул сугышчы баштанаяк томаланган. Иптәшләре, аптырап: «Ни булды, нигә киендең?» – дип сорыйлар. «Кичә мин әниемне җирләдем... Хәзер саклаучым – минем өчен дога кылучым юк», – дип җавап бирә ул...

Җәннәт – әниләрнең аяк астында, дибез. Шуңа күрә аларның кылган догалары кабул була да. Әни кешенең үз балаларына, оныкларына теләгән һәрбер догасын – яхшысын да, начарын да Аллаһы Тәгалә кабул итә.

Димәк, безгә – әниләргә дога кылганда сүзләрне бик сайлап кына кылырга кирәк.

– Кайбер гаиләләрдә, бала ачуны чыгарса, аңа «шайтан» дип әйтү гадәте бар. Ә бит шайтан бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхетле була алмый... Кайвакыт әни кеше кызы иdәнне юарга онытканы өчен генә: «Кем сине кияүгә алсын?!» – дип тузына. Ә аннары кыз бала бик озак үзенә пар таба алмый... Халык юкка гына «сабыр төбе – сары алтын» дими. Әйе, әни кешегә бик тә сабыр булырга, телен тыярга кирәк. Тагын кабатлыйм: онытмагыз, ачуланган вакытта да Аллаһы Тәгалә доганы кабул итә, шуңа күрә начар сүзне – бәддоганы әйтүдән сакланыгыз.

Күпләр өшкертергә дип киләләр дә: «Хәзрәт, нишләптер нәселебездә менә шундый хәл...» – диләр. Ә аннан, сөйләшә башлагач, бер нәрсә ачыклана: әниләре аларны гел бер сүзләр белән ачулана торган булган. Инде менә алар үсеп буй җиткәннәр дә, ачу чыкканда балаларына үзләре шул ук сүзләрне кабатлыйлар икән. Нәтиҗә күз алдында: әниләренең дә бәхете булмаган, кызларының да, инде менә оныкларының да...

Телебезне тыйыйк, якыннарыбызга, балаларыбызга, белгән-белмәгәннәргә авыр сүз әйтмик. Элек әбиләр юкка гына бала-чаганы «рәхмәт төшкере», дип ачуланмаган. Безгә дә ул-кызларыбыз нәрсә өчендер кәефебезне төшергәндә: «Әй бәхетең булгыры!» – дип куйсак, хәерлерәк. Яхшы сүз әйтү, хәерле дога кылу – изгелек кылу белән бер, һәм ул синең үзеңә үк әйләнеп кайта. Ә ләгънәт турында пәйгамбәребез менә нәрсә дигән: «Әгәр без бәддога әйтсәк, ул шул кешегә барып җитә. Әмма хаксызга әйткән булсак, кире үзебезгә үк әйләнеп кайта».

Сәбәпсез әйтәсең икән, үз балаңа кылган бәддога да – гөнаһ. Ана кеше уйламыйча әйткән ләгънәтне баласына төшүдән һәм аны бәхетсез итүдән бик сакланырга тиеш.

Әниләр исән булганда безне һәрвакыт аларның догалары саклап йөртә. Бу авыр, катлаулы көннәрдә намаздан соң догаларны тагын да күбрәк укысыннар иде алар. Иң хәерле дога, әлбәттә, «Аятел-көрси».



Хәйдәр ГАЙНЕТДИНОВ

Вакытсыз арабыздан киткән шагыйрь, язучы, журналист Хәйдәр Гайнетдиновка бу көннәрдә 70 яшь тулган булыр иде... Кыска гына гомерендә дә ул кабатланмас иҗатын калдырып китте. «Ялкын» журналында җаваплы секретарь, «Сабантуй» газетасында әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, Татарстан телевидениесендә автор-алып баручы. Затлы-зыялы, эрудицияле Хәйдәр хикәя-очерклары, шигырьләре белән укучылар күңелен яуласа, каләмдәшләрен Илһам абыйсының аһәңнәрен (Илһам Шакировның Гыйльмисафа апасының улы булсын да!) җиткереп җырлавы белән дә әсир итте. Матур әдәби теле, оста сурәтләү чаралары, күтәренке оптимистик рухы әсәрләрен бизәсә, матур тембрлы тавышы, үзенә бер зәвыклы телевизион тапшырулары аны ерак-еракларда танытты. Тележурналистлардан беренче булып ул ислам дине, Казан мәчетләре тарихына багышланган фильмнар әзерләде, әдәбият-сәнгать дөньясын тирәннән яктыртты. Көзге шигырьләре аша шагыйрьне кабат исегезгә төшерегез әле...

САУМЫ, САРЫ КАНАТЛЫ ҖИЛ!

Көзге җил

Таныш миңа синең төсләр,
хисләрең миңа таныш.
Саумы, көзем!
Килдең дәме?
Саумы, сары камалыш.

Күл булып төшкән болытлар –
юлларың шундый якты.
Җилләрең дә канат ярган,
сары яфрак – канаты.

Хыял кебек иде язын,
зәңгәр иде ул җилләр.
Хәзер инде тупылларда
сызгырыр нинди көйләр?!

Әле каядыр кача ул,
әле бөтерелеп исә, –
сагыш йөри, гүя, кемгә
бәйләнергә белмичә...

Әйтерсең лә хыял кайткан
әверелеп сагышка.
Йөгереп барып ишек ачам
тәрәз каккан тавышка.

Кешеләрсез беркайчан да
яши алмыйдыр сагыш...
Бу сагышлар миңа инде
кечкенәдән үк таныш.

Минем дә бит еллар аша
сагышлар эзләп барыш.
Саумы, сары канатлы җил,
саумы, сары камалыш...

* * *

Калды кар түгелеп
болытлы ак төннән.
Чәчәкләр хуш исе
бөркелә ак җирдән.

Җылы җил йөгерә
өстеннән даланың.
Җаннарны җылыта
аклыгы карларның.

Тик миңа шәфкатьле
булдымы әллә көз:
күмелгән киткән эз,
ак карда – килгән эз!

Ак шигырь

Мин кайтырмын, Әнкәй,
салават күперенең
зәңгәр төсе булып
кайнар яшең юып алган
зәңгәр күзләреңә.

Ә хәзергә
без явабыз, Әнкәй,
ак кар булып чәчләреңә.

Шул аклыкны эретерлек
җылы каян алыйм?!.
Ул бары тик
синдә генә иде, Әнкәй...

* * *

Болыт көрте күмгән – күренми дә
күктә балкып яткан кояш юлы.
Табигатькә баккан тәрәзәдән
җәй рәсемен салкын яңгыр юды.

Уңды төсләр спас яңгырында,
җилләр уйный сары яфрак белән.
Көзләр белән бергә нинди уйлар
уза икән Әнкәй күңеленнән?..

Мин сагышың булып йөрим, Әнкәй,
күңелсездер сиңа ялгыз чакта.
Теге тупыл һаман шаулыйдыр ул,
ямансулык биреп тирә-якка.

Тегермән күк, җилне тарта да ул,
шау-шу коя яфрак арасыннан.
Тыңлыйсыңдыр, Әнкәй, тупыл гына
шомлы хәбәр сиңа сөйләр сыман.

Кайгырмачы, Әнкәй, син барында
кояш кына балкый безнең җанда.
Гел кайтырмын, Әнкәй, һәрвакытта
якты шигырь булып синең янга!


Наилә ЯХИНА

Мөлаем, көләч йөзле, матур тавышлы Наилә Яхинаны күпләр телевизион һәм радиотапшырулар редакторы буларак белә. Ә сез «Көнләшмә, тулган ай, янында Зөһрә бар», дип, Рамил Миндияр белән парлап җырлаган Наиләне хәтерлисезме? Әйе, ул җырчы да! (Хәния Фәрхинең күрше авылыннан, икесе дә Башкортстанның Тәтешле районы кызлары.) Талантлы композитор һәм үзенчәлекле шагыйрә дә. Шагыйрь Зөлфәт аның иҗатын: «Күңел тәрәзәләреннән дөньялыкның соклангыч җиле – шигъри дөнья ургылып керә...» – дип бәяли. Хәзерге вакытта Наилә Яхина «Тәртип» радиосында «Кабатланмас моңнар» тапшыруының авторы һәм алып баручысы. Язучылар берлеге әгъзасы. Җыр һәм шигырь җыентыклары авторы.

АВАЗЛАРЫМ – САРЫ КЫҢГЫРАУ

Сәер гөлем

Коелды да инде җәйге гөлләр,
Хуш исләрен сагыныр көн җитте.
Моңсу көзләр карап тора күзгә –
Ялгыз күңел сагышын җикте...

Бу җәйләрдә яшәрде өметем,
Бер сәер гөл аны яңартты.
Хуш исеннән уянып йөрәгем,
Әллә нишләп аны яратты.

Мин өзмәдем гөлне, тик сокландым,
Хафалы күңлем дә сагайды.
Соңардым шул, никтер баккан гөлем,
Алсу гөлем бик тиз саргайды.

Күңел эзли. Гөлләр юк. Көз инде.
Сары төскә сарылган алан.
Җиләкләрен җыеп куйган түрдә
Көлеп тора тик ачы балан...

Яңгырлы көзем

Һөҗүм итә көзләр... Яңгырлысы...
Чыланадыр көннең ярлысы...
Киң кырлары күксеп яшеренгән,
Ята елап юлның тарлысы.

Беркая да барасы юк кебек...
Кызык түгел... Җәйләр үтелгән –
Һәр сурәте, яз башыннан башлап,
Җәлләмичә җуеп сөртелгән.

Дәшмәс инде сары агачлары,
Соңгы төсен алар коялар.
Кемдер йөргән кыю эзләрне дә,
Яфрак түшәп, төреп куялар.

Эзләр дә юк, төсләре дә төссез...
Тукта, яңгыр! Нигә явасың?!
Никадәрле сафлансаң да болай,
Салкын кышка барып авасың...

Елак көзләр! Кышлар усалрак,
Юкка гына аяк чаласың!
Кышлардадыр, ак юрган астында
Бер җирдә юк җылы табарсың...

Һөҗүм итә көзләр... Яңгырлысы...
Күшегәдер миндәй ярлысы...

Сары аваздаш

Дөнья усал, усал дигән булам,
Мин генәме әллә бик юаш?
Минем өчен янган җем-җем йолдыз
Сүнгән микән әллә мин тугач?..

Туганмын мин таң яралган чакта,
Көзге иртәләргә моң булып...
Тирәкләргә бик сак сары төсләр
Яткан чакта шәлъяулык булып...

Мин туганмын көзләр белән бергә,
Салкын күкләр кочкан ул чакта.
Сайрар кошлар да, җырдан туктап,
Еракларга очкан ул чакта.

Мин туганмын котлап моңсу көзне,
Авазларым – сары кыңгырау...
Шуңадыр да язгы шау авазлар
Минем якка гел дә саңгырау.

Минем өчен көзләр тик аваздаш,
Туганнарым түгел карлыгач...
Сафланамын сабыр көзләремдә,
Катлы-катлы яңгырлар югач...

Көзләр белән бергә туганмын мин,
Көзләр – минем сары аваздаш...

Ялгыз кораб


Мин бик аңлап җитмим бу дөньяны,
Ачылмыйдыр миңа һәр ягы...
Якынайдым дисәм утравыма,
Ә ул икән – аның аръягы.

Алып ташлый агым кире кагып,
Җикмәстәй җилкәннәргә тагып...
Каршы төштең, дип, дуамал дулкын
Кыйный мине, бәлаләр ягып...

Дулкын уйный, тыныч көннәремдә
Сизмим кебек дөнья агышын,
Диңгез сыман уйларым да – ялгыз,
Ялгыз кораб кебек барышым.

Бу корабта «матрос»ы да үзем,
«Капитан» да, «боцман», «рулевой»...
Күренми тик оазислы яры,
Ачыклыгы никтер нулевой...





Бүген сезгә тәкъдим ителә торган хикәя иң кадерле кешеләребез – әниләр турында. Һәркемнең тормышында иң изге кеше ул – әни. Ялгышларыбызны гафу итүче, кичерә белүче иң олы йөрәкле кеше дә – әни.

Разит Сибатов та, әни кеше белән кызы арасындагы катлаулы мөнәсәбәтне тасвирлап, уйландыра, тормышта дөрес чишелешләр табарга булыша. Автор Казан педагогика институтын тәмамлап, башта мәктәптә укыткан, аннары чирек гасырдан артык Лаешта «Кама ягы» район газетасында бүлек мөдире, редактор урынбасары булып эшләгән. Тормышчан язмаларын, повесть, хикәяләрен укучылар һәрчак яратып кабул итә.

Разит СИБАТОВ

«КИЧЕР МИНЕ, ӘНИ!»

(Хикәя)

Август аенда бу кадәр эссе булыр дип кем уйлаган? Кызудан җир ярылып бетте. Машинада йөрүчеләрнең дә ачуын китерә мондый чиллә. Кояшта илле градуска җитәдер, күләгәдә кырыктан арткан көннәр бар. Нәкъ 1972 елның җәе кебек. Ул елны да бар тереклек иясен, бар үсемлекне шулай газаплаган иде рәхимсез кояш.

– Мондый эссе җәйне күргәнегез бармы? Кара бу кояшны! Ник бер болыт кисәге булсын! Их, хет коеп бер булса да яңгыр яуса иде! – Кәүсәрия таксистның моң-зарын тыңлап бара.

– Кемгә кайтасың?

Хатын җавап бирүне кирәксенмәде.

«Безнең як кешесе түгел бу. Каян килеп чыккан коштыр? – дип, юк өчен борчылды таксист. – Теләмисең икән, сөйләшмә...»

Ниһаять, килеп җиттеләр.

– Сиңа биреггәме, күгәрченкәем? – тагын бер тапкыр сорады машина хуҗасы.

– Әйе, – дип тынычландырды аны Кәүсәрия. Акчасын түләп, машинадан чыкты.

Машина, тирә-якны бензин исенә күмеп, китеп барды.

Менә Кәүсәрия җәйге челләдә балачактан таныш урам буйлап бара. Танымаслык булып үзгәргән! Ә менә бу – ул керәсе йорт, анда аны әнисе көтә. Унбиш ел көтә инде...

Кичке эңгер-меңгер. Кәүсәриянең күзе ирексездән ике якты тәрәзәгә төште. Аларның берсендә бөкрәйгән хатын-кыз шәүләсе күренде.

«Йә Хода! Ничек картайган!» Кызганудан Кәүсәриянең йөрәге чәнчеп алды. Үзенең гөнаһын тою, аны төзәтеп булмаячагын белү тынын кысты. Бу өйдә кайчандыр ул «әни» дип дәшкән хатын яши.

«Әнием... Кадерле әнием...»

Яшь хатынның тизрәк ишекне ачасы, атылып керәсе, бусагадан атлауга әнисенең аяк очларына егылып гафу үтенәсе килде... Кайчандыр 17 яшьлек Кәүсәрия алдында үзе тезләнгән кебек тезләнәсе...

«И минем газизләрем! Сезнең белән нәрсә эшләдем мин?! Юк, булдыра алмыйм. Аякларым атламый. Бераз гына утырып хәл алыйм да...» – дип, Кәүсәрия сөйрәлеп диярлек эскәмиягә барып утырды.

Узган еллар турындагы истәлекләр бер-бер артлы хәтер капчыгыннан чыгып, күз алдына килеп басты.

Әтисе бүләк иткән кызыллы-яшелле зур туп кебек, балачагы матур, бәхетле, киләчәккә якты өмет белән тулы иде. 5 яшьлек Кәүсәрия яңа тубын шат күңелле дусты кебек яратты. Бер көнне туп ялгыш машина көпчәге астына эләгеп сытылгач, кыз температурасы күтәрелүдән тәүлек буе тора алмады. Дөрес, әнисе балалар табибы булгач, аны аякка тиз бастырды.

Менә аңа 13 яшь тулды. Какча гәүдәле, авыр хәрәкәтле, чамадан тыш озын аяклы булганга «багана» дип кушамат тактылар.

– Әни, нигә минем күкрәгем үсми? Ник миннән барысы да көлә? – дип, Кәүсәрия әнисенең тез өстенә җайлап утырып, борчыган сорауларын тезә.

– И минем карлыгачым! Гәүдәң үз яшеңә туры килеп формалаша. Менә күрерсең, мин әйтте диярсең, берничә елдан классыгызда синнән дә матур кыз булмаячак! Әнисе, яратып, аның озын чәченнән сыйпый.

Менә аңа 17 яшь. Кәүсәрия чыннан да чын чибәргә әверелде: каен кебек зифа гәүдәле, төз аяклары, кабарып торган чәче ерактан игътибарны җәлеп итә. Хәзер ул медицина көллияте студенты.

Ә Рушан... Рушан өченче курста укый! Егет бик сәләтле – киләчәктә хирург булырга хыяллана... Бирегә, ягъни Кәүсәриеләр шәһәренә, читтән килеп укырга кергән. Бер әбидә яши.

Бер күрүдә гашыйк булу аларның икесенә дә кагыла. Рушан бу кызны көллияттә беренче тапкыр күрүгә башын югалтты. Дәрестән соң көн саен өенә кадәр озатып куйды. Кулыннан тотса, юл буе ычкындырмас булды. Кәүсәрия үзе дә егеткә тәмам гашыйк иде.

Сөю-сөелү маҗарасыз булмыйдыр инде. Бер кичне Кәүсәриянең әти-әнисе өйгә вакытыннан алда кайтып кереп, көтелмәгән хәлгә тап булалар: кызлары янында таныш түгел егет утыра.

– Әти, бу Рушан була. Без бер-беребезне яратабыз. Ул – минем ирем... Ирем булачак... 18 яшь тулгач, аңа кияүгә чыгам, – дип ярып сала Кәүсәрия.

Ә әтисе ачудан шартлар дәрәҗәгә җитеп кычкыра:

– Кызым янына якын киләсе булма! Күземнән югал! Хәзер үк чыгып кит!

– Әгәр ул китә икән, мин дә монда калмыйм, – дип, Кәүсәрия батыраеп каршы төшә.

– Чыгып кит! – дип кычкыра әтисе.

Тәмам каушап калган егет ишектән югалуга, Кәүсәрия дә аның артыннан чыгып йөгерә.

Ислам Ибраһимович манеждагы ат кебек бүлмә тирәли әйләнә дә әйләнә. Бу көтелмәгән яңалыкны күңеле, акылы һич аңлый, кабул итә алмый. Хет үтерсеннәр!

Юньле гаиләдә үскән кыз ничек бозык юлга басарга мөмкин? Кем гаепле?

Ата буларак, бүгеннән контрольгә алмаса, бөтенләй эш харап. Кызны югалттык дигән сүз.

– Барысына да син гаепле! Аның кубызына биедең үсә башлаганнан бирле. «Бармак белән дә чиртмә», имеш. Аңа өй җыештырырга ярамады, кер уарга ярамады. Аш пешерергә дә өйрәтмәдең бит! «Аһ, Кәүсәр суым минем! Оҗмах чишмәм минем!» имеш! Телләгеңә ирештеңме?

– Ни өчен ул кер уарга, ашарга әзерләргә тиеш? Мин нәрсәгә? Ну, егет ияртеп кайтсын ди. Була торган хәл, – дип, Наилә ханым иренә күтәрелеп карарга куркып, арты белән борылды.

– Юләр нәмәстә! – дип үкереп, ире каршы атылып чыкты да хатынының яңагына чәпәде.

Наилә кычкырмады да, еламады да, үз сүзендә калды:

– Аңа 17 яшь тулганын оныттыңмыни? Хәзер заманасы башка, – дип пышылдады ул.

– Тормыш таләпләре гел бертөрле! Сиңа өйләнергә шайтан кушкандыр инде. Кызны харап иттең, юньсез хатын! – дип, тегесе һаман үзенекен тукыды.

– Кызың барлыгы, ниһаять, исеңә төште!

Ислам Ибраһимович күзләрен хатынына төбәде.

– Әйе шул, минем кызым бар. Ә синең кызың юк. Рәйсә бала тапканда үлгәч, мин башымны югалттым. Киләчәктә ничек яшәүне күз алдыма китерә алмыйча, акылдан язу дәрәҗәсенә җиттем. Син бит үзең өйләнешергә тәкъдим ясадың. Хәтерләмисеңме әллә? Мин кызым хакына, аңа әни кирәк булган өчен ризалаштым. Хастаханәдә балаларны караганда минем кызыма аеруча игътибарлы булгангадыр, мөгаен. Син аңа үз балаңа караган кебек карадың. Ни әйткәнеңне хәтерлисеңме? «Кызың табиб ярдәменә мохтаҗ. Мин – педиатр, аны аякка бастырырга ярдәм итәчәкмен», – дидең.

Рәсем: Наталья Васильева





– Дөресен әйтәм: мин синең кызыңны үз балам кебек яратам. Гомер буе яраттым. Ул синең дә, минем дә балам. Нинди пычрак сүзләр атсаң да, мине ничек мыскыл итсәң дә! Тапкан ана түгел, баккан – ана! – дип тезеп китте Наилә ханым һәм... тораташ булып катты...

Ишек янында мәет төсе кергән Кәүсәрия басып тора. Ул каты-каты басып, әнисе янына килде һәм пышылдап кына үтергеч сүзләре белән чагып алгандай итте:

– Димәк, үз әнием түгел? Ничә ел миннән сер яшереп, ялганлап яшәдең?!

Аннан, йөрәк әрнеткеч үпкә белдереп, кинәт кенә әтисенә борылды:

– Ну әти! Әнинең гәүдәсе суынганчы ук аны җитәкләп өйгә алып кайттыңмы? Дөресен әйткәндә, сез икегез дә мине туйдырып бетердегез. Күрәсем дә килми, – дип, агуын чәчеп, үз бүлмәсенә кереп бикләнде.

– Кәүсәрия, кызым... Мин сине үз кызым кебек яратам! Яшәвем синең өчен генә. Синсез көнем караңгы төнгә әйләнәчәк. Гафу ит мине, кызым! – Бүлмә ишеге каршына басып Наилә үксеп елый. Ә тегесе ашыга-ашыга киемнәрен җыя...

Кәүсәрия зур сумкасын тотып бүлмәсеннән чыгуга, Наилә аның каршысына тезләнде.

– Беркая да җибәрмим, кызым! Беркая да! Китмә!

– Син миңа әни түгел! Син миңа беркем түгел!

Ул туфли белән әнисенең кулларына басты, аннан аягын күтәреп, аның эченә типте. Бөтен көченә, авыртудан егылсын дип типте. Шуннан соң чыгып китте. Үткәнгә ишекне нык итеп ябып.

Әти-әнисе белән бәйләгән җепне кире ялганмаслык итеп өздем, дип ышандырды үзен Кәүсәрия. Әтисенә һәм әнисенә булган үпкәсе мәңге бетмәслек. Берничә көннән Рушанның фатир хуҗасы яңа хәбәр алып кайтты. Кәүсәрия аларны ташлап киткән көнне әтисен паралич суккан икән.

– Әтиең шул көнне үк үлгән. Өченче көнне җирләгәннәр. Әниең бу кайгыны ничек кичерер? Янына кайт, кызым! – дип, карчык күз яшьләрен сөртеп ялварды.

– Ялган! Алай тиз үлмиләр. Алар хәйлә белән мине кире кайтарырга уйлый. Хәер, дөрес хәбәр булса да... Алар үзләре мине өйдән куып чыгарды. Ә аңа кадәр ул ничә ел минем әни булып икейөзлеләнеп кыланган. Берсен дә күрәсем килми, – дип елады Кәүсәрия.

Рушан диплом яклаганда Кәүсәриягә 18 яшь тулды. Яшьләр, язылышып, егетнең туган ягына киттеләр.

Уникe ел узды. Рушан медицина институтын да күптән тәмамлады. Яшьлек хыялын тормышка ашырып, хирург булып эшли. Кәүсәрия – балалар йортында шәфкать туташы. Хастаханәдә урын булса да, анда күчәсе килми. «Балаларымны ташлап китә алмыйм», – ди ул.

Ир белән хатын яшь чактагы кебек бер-берсен сөеп, ихтирам итеп яши. Тик бер нәрсә икесенең дә эчен кыра – Кәүсәрия бала таба алмый.

Башта балага уза алмый аптырады. Ахыр чиктә йөкле булгач, бәла килеп чыкты: бала ана карынында үлде. Ел буе кайгыдан айнымады. Рушан, төрлечә күңелен күреп, хәленнән килгәнчә аның саулыгын, нервларын сакларга тырышты.

Бер елдан соң, бераз тынычлангач, тәрбиягә кыз алырга булдылар. Булачак ана сабыйны бер күрүдән яратты: кызчык күзләрен тутырып аңа карауга, сөенечтән йөрәге тибүдән туктаган кебек тоелды.

«У-а-а-а», дип, бәләкәч сузып елап җибәрүгә, Кәүсәриянең маңгаеннан тир бәреп чыкты. Каушаудан түгел, ә рәхәтлектән, бала анасы булу бәхетеннән. Баланы кулларына алып күкрәгенә кысты һәм башка ансыз яши алмавын аңлады.

Кызларына хәзер 3 яшь. Бик акыллы, матур булып үсә. Үзе шаян, үзе шук! «Без моңа кадәр баласыз ничек яшәдек икән», – дип, әти-әнисе сөенеп бетә алмый.

Күптән түгел Кәүсәрия сәер төш күрде: үзе уйнап үскән ишегалды икән. Ә өченче каттагы тәрәзәдә ниндидер хатын-кыз шәүләсе. «Әни!» дип кычкырып уянып китте ул, салкын тиргә батып. Сөйләп биргәч, Рушан барысын да аңлады. Шул көнне үк хатынын юлга әзерләп, вокзалга илтеп куйды. Вагонга утырыр алдыннан хатын, үз-үзенә урын табалмыйча, иренә елышты.

– Мин кайтканда ул исән булмаса... – дип пышылдады Кәүсәрия, иренең күкрәгенә башын куеп. Рушан аны юатып, тынычландырып, поезд күздән югалганчы карап калды.

...Хәзер ул туган йорты каршында басып тора. Балачактан күңелгә якын якты тәрәзәләр, ишегалдының кичке саф һавасы. Тәрәзәдә – кайчандыр ул «әни» дип өзелеп дәшкән гәүдә шәйләнә.

Кәүсәрия, аякларын чак сөйрәп, өченче катка күтәрелде. Менә таныш ишек, кыңгырау төймәсен дә алыштырмаганнар. «И Ходаем! Хәзер йөрәгем сикереп чыга... Эчемдә учак янган кебек. Әнекәем, бәгырькәем! Без башка бервакытта да аерылышмабыз. Безне аерып торучы бердәнбер киртә – ишек кенә. Әни!..»

Ул калтыраган кулы белән төймәгә басты. Тынлык... Тып-тын, хәтта йөрәк типкәне ишетелә.

– Кем бар анда? Хәзер ачам.

Әнисе тавышын ишетүгә, Кәүсәрия куырылып куйды. Газаплы да, рәхәт тә хисләр өермәсендә калды ул.

Ишек төбенә кадәр үк ачылды. Бусаганың теге ягында – чал чәчле, бөкрәеп беткән карчык...

– Кем син? – дип кабатлап сорады ул.

Кәүсәрия яшенә буылып, бертын сүз башлый алмый торды.

– Мин дөм сукыр диярлек. Кешеләрнең шәүләсен генә күрәм. Кулыгызны сузыгыз әле, зинһар өчен, – дип дәвам итте карчык сүзен. Кәүсәрия, аны кочаклап, күкрәгенә кысты. Әнисенең ябык куллары хатынның битенә үрелде...

– Кәү... Кәүсәрия! Синме бу? Кызым... минем! Кызым кайткан! Мин көттем... Өметемне өзмәдем!

Аның бите буйлап шатлык яшьләре ага иде.

Кәүсәрия әнисе алдына тезләнеп, аның кулларын кат-кат үпте, үзе бертуктаусыз елады.

– Әйе, мин бу, әнием! Мин кайттым. Моннан соң беркайчан да аерылмаячакбыз. Кичер мине, әни!

КИТАП УЛ — ЛӘЗЗӘТ

Резеда СӘЛАХОВА,
К. Тинчурин
исемендәге
Татар дәүләт драма
һәм комедия театры
артисты

КИТАП УКУ УЛ...

– Кайчакта эш, кайчакта ял. Эш буенча күп әсәрләр укырга туры килә. Кайчак күңелгә хуш килмәгән әсәрләр белән танышырга кирәк була. Андый уку ләззәт бирми, әмма барыбер фикерләү сәләте киңәя, аңны арттыра ул. Ә инде үзеңә ошаган китап укысаң, ләззәт тә аласың, рухи яктан баеисың да, күңелең белән ял да итәсең. Мин эмоциональ кеше булгач, китап укыганда рәхәтләнеп елыйм да, рәхәтләнеп көләм дә. Китап уку ул – эмоцияләр төрлелеге.

УКЫРГА МӘХӘББӘТ УЯТКАН КИТАП...

– Мәктәп елларында Әмирхан Еникине укыган чакларга туры киләдер «мәхәббәт» уяну. Бездә аның «Җиз кыңгырау» дигән кызыл төстәге китабы бар иде. Шундагы хикәяләрне кайтып-кайтып укый идем. Бигрәк тә «Бер генә сәгатькә», «Матурлык», «Мандарин сатучы» хикәяләре балачак хәтеренә уелып калган. Әмирхан аганың теленең матурлыгы, сюжетларының күңелгә ятышлылыгы өчен яратканмындыр ул хикәяләрне укырга. Мөгаен, Әмирхан Еники миндә китапка карата мәхәббәтне тудыргандыр да.

МИНЕ /ДӨНЬЯГА КАРАШЫМНЫ/ ҮЗГӘРТКӘН КИТАП...

– Галимҗан Ибраһимовның «Адәмнәр» повесте. Әлеге әсәр белән беренче тапкыр танышканда алтынчы сыйныфта укый идем. Аның ни дәрәҗәдә тетрәндергәнен, ничек тәэсирләнгәнемне әле дә хәтерлим. Ул вакытта мин әле 1921 еллардагы куркыныч чор турында белми идем. Ибраһимовның бу әсәрен хәзер дә бик еш искә алам. Ул вакыт белән чагыштырганда бүгенге дөньяның никадәр җитешле икәнен аңларга, һәрнәрсәнең кадерен белергә өйрәтә ул.

ҮСМЕР ВАКЫТЫМДАГЫ ДУСТЫМ-КИТАП...

– Энциклопедияләр! Күчеш чорына җиткәндәрәк апам белән миңа әнием кызлар өчен энциклопедия бүләк иткән иде. Бөтен кызларда да булгандыр ул андый китап. Нинди генә сорау туса да, апам белән шуңа мөрәҗәгать итә идек. Мәктәп фәннәренә кагылышлы энциклопедияләрне дә ул вакытларда үз итә идем. Еш кына реферат яздыралар иде, бу кечкенә фәнни эштә ул китаплар минем ярдәмчеләрем булды. Һәрвакыт өстәлемдә иде алар. Ул вакытта интернет юк. Бар сорауларга җавапны китаптан эзли идек.

ӨСТӘЛ КИТАБЫМ (НИ ӨЧЕН НӘКЪ ӘЛЕГЕ КИТАП?)...

– Алар берничә. Әмма иң якыны – Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без – 41 нче ел балалары» повесте. Үземә начар булганда да, рәхәт булганда да нәкъ шушы китапны алып кабат-кабат укыйм. Авыр шартларда кешеләрнең ни дәрәҗәдә оптимист булып калуы, бүгенге проблемаңның чүп икәнен аңлата да куя. Геройларның шаяртулары, укытучылары белән мөнәсәбәтләре, беренче мәхәббәтләре, аларның кызыклы мажараларга эләгүләре шундый тәмле һәм камил тел белән язылган, күңелне бик күтәрә. Шулай ук чыгышы белән Әфганстаннан булган америка язучысы Халед Хоссейнинең романнарын укыйм. Әлеге романнар буенча татар театрлары спектакльләр чыгара башлады. Безнең театр да шушы авторга мөрәҗәгать итсен иде дә, шунда берәр геройны уйнасаң иде дигән теләк белән янам.

ХӘЗЕР УКЫЙМ...

– Алар шактый. Эш буенча күп укырга туры килә. Казан театр училищесында III курс студентларына сәхнә теле укытам. Алар хәзер программа буенча сигез-ун минутлык проза әсәре сөйләргә тиеш. Көн саен студентларым сайлаган хикәяләрне укыйм. «Казан утлары» журналы кесә китаплары чыгара бит. Берсен дә калдырмый укып барам. Заман авторлары белән танышам. Ни кызганыч, хәзерге авторларның күбесе урам теле белән яза. Әмма стилистикалары төрлечә. Икенче белемем буенча филолог булгач, телләрендә аермалар табу, чагыштыру кызык бер шөгыль минем өчен.

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДАГЫ ӨЧ ЯРАТКАН ӘСӘРЕМ ҺӘМ АВТОРЫМ...

– Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар»ы, Әмирхан Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе», Гаяз Исхакыйның «Көз»е.

БАСМА ҺӘМ ЭЛЕКТРОН КИТАПНЫҢ УҢАЙ ҺӘМ ТИСКӘРЕ ЯКЛАРЫ...

– Электрон варианттагы китапларны укырга бик яратмыйм, хәлбуки, аны юлга алырга уңайлырак булса да. Бездә болай да замана чире – гел телефонда утырабыз. Күзләр экранга карап шактый арый. Шуңа күрә мин үзем басма китап тотып уку яклы. Аның исе дә башка, укуы да рәхәт, күзләр дә бозылмый кебек.

УКЫРГА КИҢӘШ ИТӘМ...

– Яраткан авторым М. Мәһдиевнең «Без – 41 нче ел балалары» китабын татар халкы арасында укымаган кеше булса, укыгыз, яме. Һәм тагын бер күңелгә хуш килгән роман, аны һичшиксез һәрбер кеше укырга тиеш дип саныйм – Э. Ремарк «Возлюби ближнего своего».



КИТАП АКЫЛНЫ ТӘРБИЯЛИ



Фото: Анна Арахамия

«Китабыгыз тормышымны үзгәртте...» – дип еш язалар аңа. Хәер, китаплары аның үз тормышын да баштанаяк үзгәртте – исемен бөтен татар дөньясына танытты. Татарстан Милли китапханәсе ел саен китапханәдән иң күп алынган татар китаплары исемлеген игълан итә: соңгы елларда Гөлсинә Галимуллина китаплары анда иң беренчеләрдән булып атала. Китап кибетләре аның әсәрләрен киштәләрнең иң алдына куя: сорау зур! Китапханәчеләр укучыны аның белән очраштыру өчен җай эзли... Әдәби китаплары белән танылган журналист Гөлсинә ГАЛИМУЛЛИНА белән уңыш серләре турында сөйләшәбез.



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Сез үзегезне «язучы» дип әйткәнне яратып бетермисез...

– «Язучы» статусына лаек булу өчен Габдрахман Әпсәләмовның «Алтын йолдыз»ы, «Агыла болыт»ы, Гомәр Бәшировның «Намус»ы, Мирсәй Әмирнең «Саф күңел»е кебек романнар язып, милләтеңнең ул һәм кызларын дөнья мәйданында таныта алырлык геройлар тудырырга кирәк. Күптән түгел Журналистлар берлегендә гомер буе «Ватаным Татарстан» газетасында эшләгән Илсөяр Хәйруллина белән очраштык. «Син бит язучы Гөлсинә!» – диде ул миңа. Аңа да шулай дип җавап бирдем: «Чын язучы булыр өчен «Намус» романы югарылыгындагы әсәр язарга кирәк», – дидем. Мин – журналист. XXI гасырның көчле характерлы, язмыш тарафыннан җибәрелгән сынауларны акыл белән җиңеп яшәүче хатын-кызлары тормышын әдәби сюжетка корып язучы журналист. Бу дөньяга һәркем үзенең ипие белән туа. Ипием – каләм булачагын Аллаһ сиздергән. 4 нче класста укыганда газетада мәкаләләрем басыла башлады – хәбәрче булып киттем. «Саба таңнары» газетасының авыл хуҗалыгы бүлегендә эшләдем – шушы темаларга яздым. Ә китапка тотынуым... 2006 елда районда республика күләмендәге бер зур семинар булды. Шунда урыннарыбыз бер ханым белән янәшә туры килде. Сөйләшеп киттек. «Мин үзем Әгерҗе районыннан, әмма язмыш сезнең якларга алып килде. Тормышым турында роман яза алыр идегез», – диде ул шунда. Журналистның берсе дә мондый сүзгә битараф кала алмас иде... Ике атнадан ялга чыгарга тиеш идем. Көчкә көтеп җиткездем – роман язарлык язмышны тизрәк тыңлыйсы килә. Без очраштык. Ул – укытучы, ире башка берәү янына чыгып киткәч, ике бала белән калган. Кеше фатирында, бер тиенсез... Тыңлыйм-тыңлыйм, тик роман язарлык тема күрмим. Мин укыган әдәби китапларның һәрберсенең эчендә төше бар. Монда кайда соң ул? Кинәт әңгәмәдәшемә: «Безнең районнан фатирны ничек алдыгыз соң? Андый зур акчалар керер җирегез булмаган бит», – дигән сорауны бирдем. «Сез миңа иң соңгы сүземне әйттерәсез», – диде дә туктап калды. «Шуны әйтсәгез, мин, бәлки, нидер яза алырмын», – дим. Суррогат әни булган икән ул. «Кайсы районнан телисез, шуннан йорт алып бирәбез», – дигәннәр аңа. «Начар юлга басу түгел бит бу. Мин – сау-сәламәт хатын, балаларымның киләчәге өчен кемнедер бәхетле итәм дип уйладым һәм шушы адымга бардым», – диде ул. «Мәхәббәт аланы» дигән повестем шулай туды. «Идел» журналы аны берничә санга бүлеп бастырды.

Еллар узды. 2012 ел җитте. Редакциядә соңгы елым – тиздән лаеклы ялга китәргә тиешмен. Кисәк кенә авырый башладым. Аерым чирем дә юк, әмма эчке дөньямда нидер бара... Бер дустым хәл белергә килде. «Безнең күрше Һаҗәр апа турында газетага яз әле. Китап чыгарды, шундый матур шигырьләре бар», – ди. Миңа кинәт көч керде. Һәрбер зур эш алдыннан кешегә шулай көч иңәргә тиеш... Һаҗәр апаның китабын кулыма алгач, соңгы битендәге бер язуга игътибар иттем. Кемнәрнең китап чыгарырга теләге бар, мөрәҗәгать итегез диелгән иде анда. Шуны укыдым да терелдем! Минем дә язган хикәяләрем күп – китап чыгарып карарга кирәк! «Ватаным Татарстан» газетасы журналисты Ильмир Мингалиевка шул ук көнне шалтыраттым. Бер атнадан ул элемтәгә үзе чыкты: «Гөлсинә ханым, туплап җибәргән әйберләрегез арасында «Мәхәббәт аланы» дигән повестегез бар. Хатын да укыды, килен дә... Без бу геройга сокландык. Әйдәгез, аерым китап итеп әзерлик. Әгәр бу китап белән аудитория җыясыз икән, сездән әдәби китаплар язучы көчле язучы чыгачак», – диде. Бу сүзләр минем өчен зур мотивация булды.

Шул көннәрдә «Кара-каршы» тапшыруын карарга туры килде. Журналист Энҗе Шәйхетдинова алып бара иде аны. Шуннан соң ук «ВКонтакте»да аның бер постына юлыктым: «Бәхетле тормышымның бер генә сәгатен кире кайтарыр идем дә, кабат бәхетле булып яшәп карар идем», дип язган. «Бүгенге бәхетле мизгелләрнең кадерен белергә кирәк, ә үткәннәргә инде кире кайту юлы юк», дигән комментарий калдырдым. Директка хат килеп төште: «Гөлсинә апа, сез мине кем беләндер бутадыгыз ахрысы. Мин бит сезнең авыл Данилның хатыны», – дигән. Чыннан да, журналист Энҗегә язам дип, аның адашына – бөтенләй белмәгән кешегә язганмын! Чибәр ханым, матур киенгән, чит илләргә сәяхәтләрдән кочак-кочак фотолар куйган... Бәхетсезлекнең эзе дә юк! «И-и, Гөлсинә апа, чит илләрдә нишләп йөргәнемне белсәгез?! Килегез, сөйләшеп утырырбыз – китап яза аласыз хәтта», – дип җавап бирде ул. Таңга кадәр тыңладым мин аны. Ире бик иртә мәрхүм булган. Бер хәсрәт икенчесен алып килгән: каратэ белән шөгыльләнгән улының, ялгыш сугудан соң, үпкәсе белән кабыргасы арасында шеш барлыкка килгән. Операцияне бездә ясамаганнар – улын аякка бастыру өчен ул чит илгә йөри башлаган. «Ак бураннар аша» дигән китап шулай туды... Ун елда 14 китап бастырдым.

Димәк, сездә тарихы булмаган китап юк?

– Реаль тормышта булмаган кеше турында китап язуны кирәк дип тә уйламыйм. Ул бит инде әкият... Мин көчле холыклы хатын-кызның ничек итеп акылын тәрбияләп, тормышта уңышка ирешүе турында язам. Үз гаиләсен, горур исемен саклау өчен батырлык үрнәге күрсәтеп яшәүче хатыннарны әдәбият мәйданына чыгардым. Бүген милли геройларны татарның мең дә бер кешесенә генә туры килә торган бәхетсез җаннар алыштырды. Бомжлар, сихерчеләр, никахсыз тапкан баласын күршесенең ишек төбендә калдырган хатыннар... Болай булырга тиеш түгел бит!

Сезнең укучыгыз кем, Гөлсинә ханым?

– Нигездә, укытучылар, табиблар, тәрбиячеләр. «ВКонтакте»да миңа күбрәк алар яза – яңа китабым чыгуга, иң беренче булып, үз тәэсирләре белән алар уртаклаша. Әмма укучыларым шушы даирә кешеләре генә дигән сүз түгел бу. Һич юк! Социаль челтәрләрдә фикерен язарга һәркемнең кыюлыгы җитми бит. Ә очрашуларга кемнәр генә килми! Татарстанның 60 процент районын йөреп чыктым – китап укучылар белән очраштым дип әйтә алам. Апас, Буа, Азнакай районнарына инде бишәр тапкыр чакырдылар, күп тапкырлар Әлмәттә булдым. Дәртләнеп, илһамланып, сөенеп кайтам ул очрашулардан.

Акылны китап белән тәрбияләргә кирәк, дисез. Ә үзегез нинди китаплар укыйсыз?

– Фикер киңлеген арттыра торган китаплар укырга яратам. Алар, әлбәттә, күбрәк рус телендә. «Уход за мозгом» – бу минем өстәл китабым. Аны бөтен кешегә укырга тәкъдим итәм. Көн дәвамында башыбызга бик күп мәгълүмат керә: кирәге дә, кирәкмәгәне дә. Бөтен күргән, ишеткәнне сеңдереп барасың килә икән, баш мие шартларга да мөмкин бит. Шуңа күрә үзебез өчен мөһим булган мәгълүмат белән генә кызыксынырга кирәк.

2019 елдан бирле Сөембикә-ханбикә темасын өйрәнәм. Кайсы язучы аның турында нәрсә язган – барысын да укып чыктым. Миңа иң ошаганы Фатих Урманче әсәре булды. Төрек язучысы Илгаз Ваһап Нәүрүзхан да Сөембикәбезне чын милли герой итеп биргән. Рабит Батулланы да укыдым. Китап бик матур башлана, әмма ахырда ханбикәне ничек сурәтләгәнен әйтергә дә телем әйләнми... Кире үз хәлемә кайту өчен бер ай вакыт кирәк булды. Мөсәгыйт Хәбибуллин романын да укыдым. Үзем өчен шулкадәр күп мәгълүмат алдым. Әмма Сөембикәнең ирләре белән интим мөнәсәбәтләрен тәмләп, бизәп бирүен кабул итә алмадым. Кирәкми иде... Кирәкми иде! Гафу итегез, нервлансам тавышым бетә... Сөембикә – дәүләт белән идарә иткән бердәнбер ханбикә. Безнең өчен символик образ. Бүгенге көндә Сөембикә турында нәрсә генә укысак та, аның якты рухы җаныбызга үтеп керергә, калебебезне яктыртырга тиеш.

Изге гамәл кылуны һәр кеше булдыра алмый, чөнки бу хис бәндәсенә Аллаһ бүләге итеп бирелгән, дип язасыз. Мондый фикергә килергә нәрсә этәрде?

– «Изгелеккә тартылам» дигән проектым бар. Мәдәни мирасны саклау елы уңаеннан игълан иткән идем мин аны: төрле кешеләр туган авыллары китапханәләренә, мәктәпләргә китапларымны бүләк итте. Һәм шушы проектта мин көткәннәр катнашмады. Моңарчы бөтенләй аралашмаган, күрмәгән кешеләр кушылды. Шунда уйладым: изге хис – Аллаһ бүләге, телең белән изге булам дип әйтеп кенә күңелең белән изге була алмыйсың.

Проектлар дигәннән. Алар миндә берничә. Иң беренчесе менә ничек туды. 2016 елда Бельгиядә яшәүче татарлар очрашуга чакырды. Самолетта уйланып кайтам. Туфан Миңнуллинның сүзләре искә төште: «Исемеңне чит илдә белеп тә, әгәр үзеңне туган авылыңда танымасалар, син шәхес түгел», – ди ул. Һавада чакта ук ниятләдем: туган авылымда – Эзмә урта мәктәбендә иң яхшы укучылар өчен үз премиямне булдырам! Китаплар сатам – акча керә бит... Шуннан бирле уку елы дәвамында иң күп «бишле» алган укучыларга премия биреп киләм. Ә соңгы елларда сертификатлар тапшыра башладым. Улым Алимның бакча үзәге бар: җиңүче укучылар бездән агач үсентеләре килеп ала. Утырткач, фотога төшереп җибәрәләр, «Менә сез бүләк иткән алмагач никадәр үсте, инде алмаларын ашыйбыз», – дип язалар... 2017 елда бакчада алмагачлар буяп йөргәндә башыма уй килде: «Гомер буе журналистикада эшләдем – каләм тамагымны туйдырды. Бу өлкәгә дә үз өлешемне кертергә тиешмен», – дим. Университетның журналистика факультетында укыган, газета-журналларда иң күп мәкаләләре чыккан студентларга тапшырам бүләгемне. Моңарчы акчалата премия бирә идем, узган елдан башлап махсус калфак чиктерәм. Инде менә иң актуаль темага материал язган журналистларга да үз бүләгемне бирә башладым. Үзем яза алмаган темаларга тотынган журналистларга соклануым да бу минем. «Китап тәмен белеп укучы» дигән проектым бар. Социаль челтәрләрдә укучылар белән гадәттә турыдан-туры аралашам. Гүзәлия Халикова-Закирова дигән укучым китапларыма бик тирән анализ ясый башлады. «Кем булыр икән бу?» – дим. Әдәби әсәрнең җелегенә үтеп укый ала торган укучылар күп түгел. Табибә, медицина фәннәре кандидаты икән Гүзәлия ханым. Мине сөендергән мондый укучыларны үзем дә сөендерергә теләдем – аларга да махсус калфаклар ясатам. Тагын бер бүләгем «Иҗади эшләүче китапханәгә» дип атала. Мәсәлән, Кумбашы авылы (Киров өлкәсе Малмыж районы) китапханәсе – шундыйлардан. Гадәттә китапханәгә очрашуга читтән иҗат әһелләрен чакыралар, ә аларның кунаклары – үз кешеләре: шәфкать туташы, абыстай, ветеринария табибы... Фикерле, гамьле кешеләр! Тормышта үрнәк алырлык авылдашлары.

Сез беркайчан кагылмаячак темалар бармы?

– Бар! Журналист булып эшләгән чагым. Райондагы бер колхозга командировкага киттем. Ферма мөдире хатын-кыз иде анда. Тәрбиягә бала алган була ул. Үсеп җиткәч, шул бала төрмәгә эләгә. Һәм әнисе хәлен белергә баргач, улы аны көчли... Бер төн эчендә хатынның чәчләре агара. Боларның барысын ул ачыктан-ачык сөйләде. Миңа бу вакытта 40 яшь кенә әле. Ананың кичергәннәрен йөрәгем аша уздыра алмадым, күрәсең... Укучыны шаккаттыру теләге көчле иде: кайтуга мәкаләне язып, редакторга күтәреп тә кердем. Редакторыбыз Тәлгать Нәҗмиев миңа ул чакта болай диде: «Гөлсинә, журналистикада кагылырга ярамаган темалар бар. Әйе, кемдер кагыла... Тик ул кеше син булырга тиеш түгел». Мондый адәмнәрнең урыны әдәбият мәйданында була алмый.

Язылмаган тагын нindидер кагыйдәләрегез бармы?

– Тормышта Аллаһы Тәгалә җибәргән билгеләрне табып, «укып» яшәргә тырышам. Аларны «күрү» кирәкмәгәнгә хафалану, борчылулардан саклый. Әйтик, каядыр барырга җыенам, әмма юлга кузгалмас өчен мең сәбәп чыга. Димәк, бу миңа билге – анда барырга тиеш түгелмен.

Еш кына артка – үткән юлга борылып карыйм: Аллаһы Тәгалә мин сорамаган бер нәрсәне дә бирмәде. Күзләрем әтинекенә охшаган – кечкенә. «Балаларымның күзләре иремә охшаса икән», – дип теләдем. Икесенең дә күзләре Фәргатьнеке!

Айгөлдән соң туган кызым үлде минем... Егерме көнлек баланың мәетен күтәреп хастаханәдән кайттым. Төн сакларга авылдан әнием килде, күршебез Мәймүнә абыстай керде. Шок хәлендә идем: үземне тынычландырыр өчен укырга бер дога белмим... Шул кичне, әгәр хисләрне конт-

рольдән ычкындырсаң, мизгел эчендә башың китүе мөмкин икәнен аңладым. Төн уртасы. Караватта бер гөнаһсыз балам ята... Кисәк, әллә нәрсә булды: әни белән абыстай күземә дүрт булып күренә башлады... Әни бик курыкты, тиз генә салкын су белән битемне юдырып, урамга алып чыкты. «Кызым, артык тирәнгә кереп уйларга ярамый. Сөяргә Айгөлегез бар, тагын балагыз булыр», – диде. Айнып киттем... Абыстайның: «Гөлназ кызыңны гел дога белән искә алсаң, ул сине җәннәт бакчасы алдында көтеп торыр», – диюе яңадан тормышка кайтырга булышты. Ана кеше өчен баласын мәңгегә югалтудан да авыр хәсрәт юклыгын аңладым. 1983 елдан башлап, балаларымның исәнлеге, тәүфыйгы өчен дип, елга ике тапкыр Коръән укытуны гадәткә керттем. Хәсрәтне җиңүнең юлы бер генә – Аллаһка якынаю. Аллаһ күктә дә, җирдә дә түгел, ул – безнең йөрәктә. Бала үлеме аша гомерем буена җитәрлек сабак алдым. Әйе, Аллаһ безгә нәрсә сорасак, шуны бирә. Ә мин бер кызым һәм бер улым гына булсын иде дип теләдем... Уйларың белән бик сак булырга, ялгыш уйлавыңны аңлауга шунда ук тәүбә итәргә кирәк.

Стивен Кинг дигән язучы: «Иң курыкканым – иртән уяну һәм башымның бушлыгын, анда бернинди дә сюжет булмавын аңлау. Бөтен язучыларга да хас фобиядер инде бу», – ди. Сездә дә буламы андый чаклар?

– Юктыр... Китапны язарга утырганчы героем белән күп тапкырлар очрашам, аның тормышын тәмам өйрәнеп бетәм. Диктофоным тула. Диктофон белән бергә башым да тула: ми күзәнәкләренең 80 процентына язылачак китаптагы сюжет линияләре кереп утыра... Кем белән генә сөйләшсәм дә, кая гына барсам да, уемда – язылачак китап юллары. Геройларым белән бергә төрле вакыйгалар эчендә кайныйм, ниндидер матур җирләрдә йөрим... Аннары вакыт булган саен, утырып шуларны бушата башлыйм. Бушаткан саен рәхәт була бара... Утыруга илһам килә – әйтерсең лә яңгыр ява... Китап язмаганда җиңелрәк.

Сезнең геройлар барысы да көчле хатын-кызлар. Тормышта авырлыкларга очрап та, аягында басып кала алган, егылган җирдән күтәрелгән ханымнар. Укучыларыбыз арасында да тормыш сынаулары белән очрашучылар бардыр, аларга нинди киңәшләр бирер идегез?

– Беренче чиратта, китапларымны укырга тәкъдим итәм. «Әдәби марафон»да катнашучы Розалия исемле ханым көтмәгәндә бүләк бирде миңа. «Гөлсинә апа, баламны югалттым... Бик авыр кичердем. Шул көннәрдә китапларыгыз дәва булды, рәхмәт», – диде... Тege яки бу героегызга ошыйсым килә дип еш язалар. «Сезнең китабыгызны укып, башкача яши башладык», – диләр. Үзебезнең Саба кызы Лилия Вафина китапханәдә очрашуда: «Ефәк кульъяулык»ны укыгач, Айгүзәл кебек чигү теләге уянды», – дигән иде. Бүген алар бөтен татар дөньясына танылган чигүчеләр... Мин язган ханымнарның барысының да уртак бер сыйфаты бар – алар әхлакларын югалтмаган. Алар Аллаһка якын. Юк, берсе дә дини фанатлар түгел – шөкер итә белүчеләр. Гамәлләре, күңелләре дөрес. Дөньяда шуңа омтылырга кирәк.

Хатын-кызның кайсысы утызда ук картая, ә кемдер 60–65 тә дә матурлыгын югалтмый. Моның берәр сере бармы икән?

– Миңа менә – 65, үземне яшь калдым, дип әйтә алмыйм. Илледән узгач, һәр ел, синнән сорап тормыйча гына, «үзенеке»н ала инде ул. Битнең дә, чәчнең дә төсе үзгәрә. Бу табигый халәт: аны берәү дә туктата алмый. Дөрес, үзен хөрмәт итәргә гадәтләнгән хатын-кыз йөзенбитен тәрбияли, гәүдә авырлыгын нормада тота. Күпмедер дәрәҗәдә шушы төркемгә керәмдер. Һөнәрем буенча гел халык арасында кайнагач, үземне һәрвакыт контрольдә тоту яшәү рәвешемә әйләнде.

Ниндидер бер шөгыле булган кеше тиз картаймыйдыр дип уйлыйм. Минем өстәлемдә ноутбук, киявем бүләге – «Коръән» китабы, улым бүләк иткән тегү машинасы тора. Тегәргә бик яратам! Тагын – бакчада эшләргә! Анда мин арымыйм да – бакча миңа энергия бирә. Улым Алим бу яктан миңа охшаган... «Коръән»не җырлап укыйм дия алмыйм әлегә: һәр атнаның чәршәмбе көнендә үзебезнең мәхәллә мәчетенә укырга йөрим. Намазга 40 яшемдә баскан идем. Кызым Айгөл миннән бер айга гына соңрак укый башлады. Алимның студент чакта, гариза язып, гаеттә катнашырга дип кайтканын гомердә онытасым юк... Күңеле тулы матур гамәлләр аның. Минем туган авылым Эзмәдә ике ташландык чишмәне яңартты: Иҗат һәм Бәхет чишмәсе дип исем куштык. Зират өе иске иде – яңаны салды. Киленем Эльвира – кызым кебек. Киявемнән дә бик канәгатьмен: акыллы, гыйлемле, галим кеше безнең Фәһим. Бүгенге көндә Риза Фәхретдин китапларын тәрҗемә итү белән шөгыльләнә. Балалары бәхетле булу да яшьрәк күрсәтәдер хатын-кызны.

Сез әле сәяхәтләр дә яратасыз...

– 2018 елда миңа зур хаҗ кылырга насыйп булды. Җәннәт бакчасына – Мөхәммәд пәйгамбәрнең кабере янына да бардык. Рауда дип атала ул урын. Кеше шулкадәр күп иде – консервадагы балыклар кебек басып тордык. Намазны да шул килеш кенә укыдык... Икенче көнне безне «Коръән» күргәзмәсенә алып киттеләр. Бер Чаллы хатыны: «Без хәзер Раудага барабыз», – ди. «Мин дә яңадан барыр идем», – дим. Пенсиягә чыгуга, курсларга йөреп, үземә кирәк дәрәҗәдә инглиз теле өйрәнгән идем. Гарәп кызына: «Бүген Россиягә кайтып китәбез, кертсәгез иде», – дип аңлата алдым. Унбишләп кенә идек без анда. Мондый мөмкинлек чыгу бөтен дөньямны тетрәндерде. Күңелем бик нечкәрде – гел яшь түктем. Шунда: «И-и Раббым, шушы урынга басып, яңадан Гомрә хаҗы кылырга насыйп ит», – дип дога кылдым. Быел менә көтмәгәндә «Милли китапханә» китапларымны сатып алды. Аллаһы Тәгалә Гомрә хаҗына чакыра дип юрадым моны. Үзем сезнең янда утырсам да, күңелем белән инде күптән Мәккә, Мәдинә шәһәрләрендә, зур мәчетләрдә намаз укыйм. Дөньялар гына тыныч булсын! Анда барып, шушы теләкне теләп дога кыла алачакмын дип сөенәм...

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Яшьләр

Без үскәндә гаилә мәсьәләсенә бик җитди карадылар. Ә хәзер тормышлар матур булса да, аерылышучылар саны күбәйде. Матди яктан алга китсәк тә, рухи яктан ярлылана барабыз.

Яшьләр никахсыз гына яшәүне хуп күрә. «Гражданский брак», диләр. Бик күңелсез күренеш бит бу. Карап күзең туймаслык чибәр кызлар үз бәяләрен төшерә шулай. Мәхәббәтенә тугрылыклы төпле егетләр, беренче көннән үк никах укытып, ЗАГСка кереп язылыша. Тормышын әнә шулай башлый.

Безнең сабый чак ачлык, фәкыйрьлектә үтте. Үсмер чаклар шомлы елларның караңгы вакыйгалары белән чорналган. Колхозлашу елларындагы күз яшьләре, динне бетерү өчен көрәш, дин әһелләрен сөрүләр, киселгән мәчет манараларының җирдә аунаулары безнең яшь йөрәкләрдә җуелмас яра калдырды.

Дүрт тәрәзәле кечкенә генә өйдә 9 бала белән 11 җан яшәдек. Ипине бервакытта да туйганчы ашаган булмады. Көнгә юка гына бер телем эләгә, анысы да алабута кушып пешергән ипи. Игеннәр элек ел да уңмаган шул. 1921 елгы ачлык турында күпләр белә. Безнең гаиләдән дә бер бала ачтан үлгән. Әти белән әни моны бик авыр кичергән.

1935 елда тагын ачлык. Бу ишле гаиләне ничек ашатырга дип бик кайгырган әти. Икмәк эзләргә дип чыгып киткән җиреннән ике айга югалып торган. Ике айдан коры сөяккә калып, ике пот кукуруз бөртеге күтәреп кайтып кергән. Эшкә чыккач, аны: «Син – халык дошманы, колхозны сөймисең, сине сөргенгә сөрәбез», – дип, типкәли-типкәли кыйнаганнар. Ике тапкыр алырга килгәннәр, качып калган. Өченчесендә милиция белән килгәннәр. Башка качар урын булмагач, әти мунчада сайгак астына кереп яткан. Ләүкә астындагы салкын судан әтине иртән генә табып алганнар... Ул 1935 елда вафат була. Әни 36 яшендә сигез бала белән кала.

Әниебез белемле иде. Аның әтисе мәдрәсәдә укыткан. Качып-посып булса да, әни безгә дә дини белем бирде. Бабай исә сөргендә юк булды.

Без яланаяк үстек. Дәресләргә кадәр бездән биш чакрымдагы урманга барып, энем белән юкә кабыгы әзерли идек. 11 яшьлек энем шуннан чабата үрә. Әниләр кояш белән басуга китә. Бригада саен алты-җиде «бәхетсез» кыз, яланаяк чык ярып, таң белән әниләргә иярәбез. Әниләр эшләгәндә бала арбасындагы энекәшне карап торырга кирәк. Авылда балалар өчен бакча юк. Өч ел энемне карадым. Аннан да авыррак эш юктыр, дим. Ач килеш, кояшка карап көнеңне үткәр әле син! Мәктәпкә баруны бер рәхәтлек кебек көтәбез. Анда да тамак ача. Кухня ясап, аш пешерә башладылар. Борчак суы гына инде анысы да. Бер класстан 42–48 бала, этешә-төртешә, ашарга йөгерәбез. Үзебез яланаяк, өстебездә киндер күлмәк...

1939 елда игеннәр уңды. Колхозчыларның икмәк салырга капчыгы да, бурасы да юк. Ашлыкны капка төбенә генә алып килеп бушаталар. Ике энем кайтып та керми, көшел барлый. «Иң кечкенә көшел – безнеке. Малик бабайларныкы Урал тавы кадәр», – диләр. Сәбәбен әни сабыр гына аңлата. Халык шат. Клублар эшли башлады. Урамнан яшьләр җырлап уза.

Күңелемнән генә болай ди идем: «Ипигә туйсам, үземнән түбәнрәкләргә ярдәм итәр идем». Сүземдә тордым, мөмкинлек булганда мохтаҗларга өлеш чыгардым. Район җитәкчелеге «Алтын йөрәкле кеше» медале белән бүләкләде. 1941–1945 елларда тылда намуслы хезмәт иткәннәргә дә медаль бирелде. Аны кадерле ядкарь итеп саклыйбыз.

Көн дә 30 километр юл йөреп, Актаныш урта мәктәбен тәмамладым. Иртән ике бәрәңге тыгып чыгып китәбез. Юл буендагы үләннәрне, кырдагы башакларны җыеп ашыйбыз. Ярты кеше гәүдәсен күтәреп каршыга чыккан бүреләр, хәер соранып кайтканда юлда үлгән сабый балалар, карт-карчыклар әле дә күз алдында. 250 г ипи бирәләр дигәч, Минзәләдә педучилищеда укыдым, аннары читтән торып Алабуга пединститутын тәмамладым. Авыр чакта безне өмет яшәтте. Булганына шөкер итеп, рәхмәтле булдык. Ә хәзер тормыштан шөкер итеп, канәгать булып яши белмиләр. Шунысы эчне пошыра.

Салиха ӘХМӘТОВА.
Актаныш.

Әнкәебез Бибигалия Мәгъсүм кызы бик динле кеше иде. Ел да уразасын, биш вакыт намазын сәбәпсез калдырмады. Барлык дини бәйрәмнәрне хөрмәтләп, кунаклар җыеп Коръән укытуларны үзенең изге бурычы санады.

Аның вафатына быел көз 20 ел булды. Үлемнән куркымады ул, бары Аллаһы Тәгалә каршында җавап бирүдән генә курыкты. Унбер бала табып, шуларның җидесен үстереп аякка бастырган Герой-ананың урыны оҗмахта булса иде дип, догадан калдырмыйбыз. Унбер баласының дүртесе бик яшьли дөнья куя. Миннән өлкәнрәк Фиргать абыем 9 яшендә башы сызлап вафат булды. 1941 елда туган Фәрит абый да биш яшендә дөньядан китkән. Аның «Поезд килә, поезд чаба / Тимер юлны кыздырып. / Безнең әти кайтыр әле / Кара чәчен туздырып», дип үзе чыгарган җырын әнкәй еш кабатлый иде. Әти яраланып сугыштан кайтып кергәч, абый, куркып, әнкәй артына поса. «Бу әти түгел, бу – немец», – ди.

Безнең әнкәй – Буа районы Әлки авылы кызы. 1912 елда туа ул. Бабай мәрхүм бик гыйлемле кеше иде. Алар гаиләсе урта хәллеләрдән саналган. Үзләренең көмәч пешерү цехлары, Чуашстанның Яльчик авылында көмәч сату лавкалары булган. Бернинди батракфәлән тотмаганнар, фәкать үз көчләре белән генә көн иткәннәр. Утызынчы елларда аларны да кулакка чыгарып, йорт-җирсез калдырганнар. Моны читтән килүчеләр түгел, шул авыл кешеләре башкарган. Шунда башлап йөрүче активистның кызы безнең авылда кияүдә иде. Тормышының рәте-башы булмады. Атасы аркасында күпме авырлык күрсә дә, әнкәй алар турында начар сүз сөйләп, яманлап йөрмәде. Нинди киң күңелле, олы йөрәкле булган икән безнең әнкәйләр.

Кулакларны сөрү башлангач, бабай гаиләсен алып Мәскәүгә чыгып кача. Ә әнкәй 1931 елда Килдураз авылы егете – әтиебез Хәсәнҗан улы Нигъмәтҗанга кияүгә чыгып кала. Аның туганнары күп иде. Ел саен Мәскәүгә кунакка баралар иде. Бабай бик чая кеше булганлыктан, барлык кирәк- яракны шуннан җибәреп кенә торды. Илленче елларда иттарткыч бездә генә булгандыр, мөгаен. Бөтен күрше-тирә савыт-сабага, чуен, табага безгә керә иде. Мәскәүдәге туганнарыбызның балалары җәй саен безгә кайтты. Дүртбиш бала икешәр-өчәр ай торып китә. Әле бөтен урам баласы бездә иде, чөнки бездә кызык. Безнең бакчада нинди генә җиләк-җимеш, яшелчә үсми!

Әнкәйнең хәтеренә сокланмаган кеше булмагандыр. Аның пәйгамбәрләр тарихын сөйләгәнен авыз ачып тыңлап утырабыз. Соңыннан үзем дә пәйгамбәрләр тарихын китаплардан укыдым, ләкин әнкәй кебек итеп яттан сөйли белмим. 15–20 куплетлы бәетләр чыгарып сөйли иде. Озак еллар ике авылның абыстае (әти озак еллар имам вазыйфасын башкарды, Буа районы Килдураз авылында мәчет төзетеп, дүрт ел анда имамлык итәргә дә өлгерде), остабикә булып йөрде. Бервакытта да гайбәт сөйләмәде, бездән дә сөйләтмәде. Әтиебез Нигъмәтҗан белән 65 ел бергә гомер иттеләр. Әтиебез 89 яшендә, әнкәй 90 ны тутырып дөнья куйдылар. Урыннары оҗмахта булсын.

Әхтәм МӨХӘММӘТҖАНОВ.
Казан шәһәре.

Мин 22 ел тәрбияче булып эшләдем. Ул еллар тормышымның иң күңелле чоры булды. Балаларны яраттым, һәркайсы үз балам кебек бик якын иде. Үзләре дә гел миңа тартылды. Кем баласы булса да, аларны аермадым, бертигез күрдем.

Группада 3–5 яшьлек 33 бала. Ул вакытларда балалар белән җәйне Аккош күле янындагы дачада уздыра идек. Анда икешәр ай булабыз. Без – бер төркемдә ике тәрбияче. Атна саен һәрберебез унҗидешәр баланы мунчада юындыра. Сирәк кенә әти-әниләр дә булышкалады. Безнең төркемдәге балалар авырмый иде. Дачада да авырган балабыз булмады. Без намус белән эшләдек, акчага табынмадык. Беренче урында балалар торды. Балалар илнең иң кадерле кешеләре иде ул вакытта.

Фатир мәсьәләсен хәл итү өчен, 1989 елда икенче эшкә күчәргә туры килде. Аннары реформалар башланды, бакча бинасын сатып ук җибәрделәр. Казанның Зур Кызыл урамында урнашкан иде ул. Ике генә төркем, йокы бүлмәләре дә юк, балалар раскладушкаларда йоклый. Менә шушы бакчага обкомның беренче секретаре Мусинның оныгы, беренче секретарь Усмановның оныклары, обкомның өченче секретаре Гайнуллин абыйның кызлары, вуз укытучыларының балалары да йөрде. Барысы белән дә уртак тел табып, матур эшләдек. Гайнуллин абыйны Мәскәүгә эшкә алгач та, кайткан саен гаиләләре белән безгә кереп, мине күреп китәләр иде. Башкалар да, бәйрәмнәрдә үзләре килеп, котламый калмады. «Яратабыз сезне! Рәхмәт яхшы тәрбиягез өчен», – дип язган котлау сүзләрен әле дә саклыйм.

Безнең урамда тагын өч бакча урнашкан. Анда ияләшеп китә алмаган авыр холыклы балаларны да участок табибы юлламасы белән безгә китерделәр. «Галина Алексеевна, миңа ул балаларны җибәрмәгез инде, үзләренең бакчаларына йөрсеннәр», – дисәм, «Түзәрсең, син түзем кеше», – ди иде.

Һәр эшне намус белән башкарырга кирәк. Ләкин балалар бакчаларында эшләүчеләр тагын да кешелеклерәк, тагын да намуслырак булырга тиеш. Без бит кеше тормышы өчен җавап бирәбез. Һәрбер ата-ана өчен үз баласы кадерле. Без баланың кимчелекле яклары турында да бик уйлап, әти-әниләрнең күңелен яраламаслык итеп кенә әйтергә тырыша идек.

Хәзер тәрбиячеләр турында төрле сүзләр йөри. Бүлмәдә балалар барында тәрәзәләрне ачып куеп, махсус салкын тидерәләр, дип тә зарланалар. Әгәр чын булса, бу бит зур җинаять. Бакчаларда андый тәрбиячеләргә урын булмаска тиеш. Тәрбияче эше – авыр һәм бик җаваплы. Кешеләрнең иң кадерлеләре – балалары белән эшли тәрбиячеләр. Аларга сабырлык, тырышлык телим. Күбрәк елмаерга кирәк, балалар тәрбияченең начар кәефен күрергә тиеш түгел. Бер гөнаһсыз сабыйлар әле алар. Яратуга – ярату, хөрмәт белән җавап бирәләр.
Мин тәрбияләгән балалар әле дә мине урамда күреп, әллә кайдан танып ала. Рәхмәт сүзен ишетүе шулкадәр рәхәт.

Зәбидә МОРТАЗИНА.
Казан шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адр ес: Казан,
Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA



КОЛХОЗ КЫЗЫ ӘЛФИЯ



Лилия
ГӘРӘЕВА

«Кызыл бәйли, кызыл кия / Колхоз кызы Әлфия...» дигән җыр бар иде бит элек. Нәкъ Әлфия апага атап чыгарылган диярсең. Дөрес, кызыл бәйләп, кызылдан киенүен белмим, ә менә колхоз кызы булуы хак. Мәктәпне тәмамлаганнан бирле гомере буе колхоз эшендә ул. Әлбәттә, колхоз эше дип язу гадәт буенча гына, колхозлар күптән юк инде. Исеме үзгәреп, оештыручысы алышынса да, күпләр аны күңеленнән һаман да колхоз дип йөртә...
– Яшьрәк чагың булса, тагын сыер саварга керер идең, әйеме, әни? – ди аңа улы.
– Керер идем, ике дә уйламас идем...
Ришаты дөрес әйтә, эштән һич туйганы юк әле Әлфия апаның. «Эш күп», – дип зарланучыларга аптырый ул. Тегесен-монысын уйлап, күңелсезләнеп утырырга вакытың калмагач, әйбәт бит инде. Эш – гомерлек юлдашы аның. «Сыгылып төшәрдәй чакларымда эш белән юандым, ярый әле эшем бар», – ди 43 ел стажы булган терлекче. Бүген Әлфия апага 65 яшь, пенсиягә чыкканына ун ел, ул әле дә һәр иртәдә йөгереп эшенә бара.

Чит илләрдәге кебек

– Фермадан бер дә китәсе килми шул, апаем. И-и, бүгенге фермалар элеккеге шикелле түгел инде. Кызыга-кызыга эшләрлек. – Әлфия апа боларны ихластан әйтә. – Элек без иртәнге дүртенче яртыдан эштә булыр идек. Хәзер сыер савучылар җидегә генә килә. Өч сменага өчәр савучы. Сыерларның ашарына таратасы юк, асларын чистартасы юк, сөтне ташырга сөзәргә кирәкми. Чит илләрдәгедән бер дә ким түгел хәзер үзебездә дә...

«Август–Лениногорск» җәмгыятенең Ялтаудагы сыер фермалары турында әйтүе аның. Чынлап та, монда хәзер бар да автоматлаштырылган икән.

– Шул рәхәттә дә эшлисе килми бит яшьләрнең, – дип гаҗәпләнә ул. – Акчалары да авыл җиренә күрә начар түгел. Яллары да бар. Без ялсыз да эшләдек.

Беренче тапкыр фермага эшкә 1979 елның ноябрендә килә Әлфия апа.

– Бер айга ничек тә түзәрмен, дигән идем... «Сыер савучылар ялга китте. Фермада эшләргә кеше юк», – дип, бик үтенеп сорагач, ферма мөдире Мөкътәс абыйның сүзен аяк астына салырга кыенсындым. Кызым Ләйсәнгә алты гына ай иде ул чакта. Балам кечкенә, чыга алмыйм, дисәм дә гаеп итмәсләр иде югыйсә.

Ә ферма кызлары чаялар! Кулларындагы сәнәкләре биеп кенә тора. Ни арада чүмәләгә батыралар да, мунча түбәсе кадәр өемне каерып алып, ни арада сыерларга өләшеп тә чыгалар. Ул да булмый, иңнәренә көянтә-чиләк менеп куна. Йөгермәсәң, апараның куесын башкалар ташып бетерә, синең сыерларга онлы су гына торып кала. Аның белән сөтне ничек арттырасың?

– Эшли алырмынмы икән? Адәм көлкесенә калмасам гына ярар иде дип курыккан идем, өйрәндем тагын, – ди Әлфия апа. – Күршедәге Закирә апа белән бергә эшләдек. Иртән мине уята күр, ди идем. Ул чакта сыерларны да кул белән сава идек әле. 25 сыер! Дөрес, барысын да савасы түгел үзе, кайсысының бозаулар чагы җиткән – сөт бирми, кайсысы кысыр... Көненә 110 литр тирәсе сөт савыла иде. Куллар арый иде инде.... Хәзер бер сыер көнгә 30 литр сөт бирә, ул вакытларда 10 ны сава алсак, бик күп дип саналды.

Авыл кешесе болай да иртүк тора. Олы йорт килененең йокысы аеруча да кыска. Әлфия апаның йоклаган чагын берәр тапкыр күрдеме икән кояш?!

Матур яшәгән идек тә...

Әлфия Сафина – Лениногорск районының Керкәле авылы кызы. Газинур Фарукшинның: «Керкәле авылы кайда – / Биек тау итәгендә», – дип җырлаганын хәтерлисезме? Әнә шул биек таудан җиләк җыеп үскән кыз Ялтау егете Хәдискә насыйп булган икән бит. 1976 елның җәендә Сафиннар йортына яшь килен килә. «Бигрәк пар килгәннәр!» – дип соклана күршекүлән. Хәдис – авылның бер дигән гармунчы егете, шофер. Яшь киленнең өздереп карый торган коңгырт күзләрендә – тәвәккәллек, җитез хәрәкәтләрендә – эшкә батырлык, уңганлык...

«Гомергә эш белән юандым, ярый әле эшем бар», – ди 43 ел стажы булган терлекче.

Тату гаиләнең бәхетен тагын да арттырып, бер-бер артлы сабыйлар туа. Дүрт балага гомер бирә алар. Лилия, Ләйсән, Илфат, Ришат – Әлфия апаның дүрт терәге.

– Матур кеше иде Хәдис, – ди ул ире турында. – Матур гәүдәле кешеләр була бит, аның да гәүдәләре шулай төз, зифа иде. Ярдәмчел, уңган да үзе. Шофер кеше көндез – колхозга, кич авылдашларына эшли бит ул. Кеше гозерен кире какмады, шулкадәр күндәм, эшкә карусыз иде. Азып-тузып та йөрмәде, тәртипле булды. Яңа өй салырбыз дип тырышты. Тату, матур яшәгән идек тә...

Аның «иде» дип сөйләшүе сискәндерә. Яхшы, игелекле кешеләрнең гомере никтер кыска була. Әллә соң андыйлар ахирәттә дә исәптә микән? Үзе яратып эшләгән, гел карап, төзәтеп торган машинасы астында калып һәлак була Хәдис абый. Ремонт вакытында әнә шундый фаҗига килеп чыга. Нинди үкенечле үлем... Ялтауны гына түгел, бөтен тирә-якны тетрәндерә бу авыр хәбәр. 37 яшьлек ирен гүргә иңдергәндә ничекләр түзелгән? Олы кызына – 15, иң кечесенә 1 генә яшь була бит әле.

Балалар хакына

– 36 яшемдә дүрт баламны кочаклап ялгыз калдым. Күземә беркем, бернәрсә күренмәде – балаларымны гына уйладым. Кеше баласы кемгә кадерле? Аларны чит-ятлардан кактырасым-суктырасым килмәде, – дип, тормышының фаҗигале елларын искә ала әңгәмәдәшем. Күпне кичергән авыл апаларына хас тыйнаклык, язмыш белән килешү сизелә аның сүзләреннән. Ул беркемне гаепләми, бернәрсәдән зарланмый. «Кемнәр ярдәм итте соң, Әлфия апа? Берүзең дүрт балаңны ничек үстереп бетердең?» – дим. 1993 нче еллар бу. Саклык кассаларында халыкның акчасы янган, эшләгән өчен хезмәт хаклары түләнми торган чорлар.

– Туганнарым, авылдашларым булышты, – ди ул. – Хәдисне җирләгәннән соң, тагын Мөкътәс абый әйтә: «Әлфия, акчасы да күбрәк – үгезләр карарга кер әле син, – ди. – Балаларыңны үстерәсең бар. Кул астында җигүле атың да булыр...» «Ат җигә белмим бит, Мөкътәс абый», – дим. «Колхоз үзе өйрәтә ул», – дигән иде. Башыңа төшсә, өйрәнәсең икән. Берьюлы иллешәр үгез карадым. Карадым, дип, балалар белән бергәләп карадык. Балалар белән генәме, туганнарга кадәр булышты! Иремнең Галия апасы, асларын гына

Фото: Анна Арахамия

Кичәге тормыш белән бүгенгене чагыштыра торган да түгел. Бүген беркем дә кул белән 25 сыер саумый.

булса да чистарта торам, дип, иртүк фермага менәр иде. Галия ападан күргән игелек безнең!

Үзем генә куркам, улым Илфатны да үзем белән эшкә уятып алып чыгам. Бәләкәй булса да, ир заты бит. 9 яшеннән ат җикте. Кем ничек булдыра ала, шулай булыштылар. Әле дә ярдәмнәреннән калдырмыйлар.

Ничек кенә хыяллансалар да, ире белән яңа өй салырга өлгерә алмый алар. Ул елларда колхозга «щитовой» йортлар кайта башлый. Әлеге дә баягы шул изге күңелле Мөкътәс абый инде, Әлфия, тәвәккәллә, ди. Ул вакыттагы колхоз җитәкчесе булган Айдар Хисмәтуллинга бүген дә рәхмәтле Әлфия апа. Йортның ярты хакын колхоз түли, яртысын үзе эшләп түләп бетерә. Ул вакыттагы акча белән 25 мең сум – авыл кешесе, ялгыз хатын өчен бик зур бәя. Бер ел дигәндә төзеп тә чыгалар.

Иренең кешелеклелеген дә онытмаганнардыр, Әлфия апа үзе дә абруена тап төшерми – авыл халкы бик хөрмәт итә бу гаиләне. Ялгыз хатын капкасын тугыз тәрәзә күзли, диләр. Ире барып булышса, хатынының көнләшүе дә сер түгел авыл җирендә.

Әлфия апа фикеремне кырт бүлә:

– Көнләшергә беркайчан да сәбәп бирмәдем. Нинди ярдәм кирәк, әйт кенә, диләр иде. Бервакыт яшенләп яңгыр килә. Болында чапкан печәнебез бар иде. Печәнеңне алып кайтабыз, дип, Идрис абый килгән. Туганнар, күршеләр, авылдашлар – берсе дә гозеремне кире какмады.

Эш анасы

Кайнанасы белән 32 ел яши алар. Гыйлембаян апаның үзе турында да бер язма язарлык. Ике ятимгә әни булып килә ул. Үзе дә җиде бала таба.

– Алар бик тату булдылар. Авылның иң күркәм, иң хөрмәтле гаиләсе бу, – дип сөйли Әлфия апаның күршесе Минзилә Садриева. – Безнең авылга килгәндә Әлфия әле үзе дә бик яшь, 19 яшьлек кенә иде бит. Хәдиснең сеңелләре кияүгә дә чыкмаганнар иде. Ишле мал-туарлы, туган-тумача өзелеп тормый торган олы йорт иде элек-электән үк. Кияү-киленнәр кайтса, егерме бишәр кеше булалар. Әлфиянең «уф» дигәнен дә ишеткәнем юк. Гыйлембаян апа шушы өйдә олыгаеп дөнья куйды. Улын җирләгәч, ничә еллар Әлфия белән яшәде. Килене каккан булса, аның барып сыеныр балалары күбәү иде. Берсенә дә бармады, шушында торды.

Өч баласы – Әлмәттә, бер кызы күршедәге Иске Иштерәктә төпләнгән Әлфия апаның. Ләйсән авыл клубында эшли икән.

– Безнең әни беркайчан да эштән бушамады. Эштән туйган чагы булмады аның, – ди ул әнисе турында. – Фермадагы малларны карап төшә дә, үзебезнекеләр янына чыгып китә. Әлегә кадәр ике сыер асрады. Бергә калдырганына яңа гына әле. Аның янына сарыклары бар, бозаулары... Бигрәк мал җанлы ул безнең...

– Авылда яшәп, ничек мал асрамыйсың, – дип аптырый Әлфия апа. – Абзарындагы шул терлегең ашата да, яшәтә дә. Эшләп-эшләп тә, колхозларның акча түли алмаган чакларын да күрдек. Түләсәләр дә, күпме генә иде инде ул... – Ашатырына булса, сыер саву гына эшмени?!

Ялтау урамнарын тузанга күмеп, элеккеге шикелле көтү чыкмый инде авылда. Түбән очта сыерны бер Әлфия апа гына асрый бугай. Закирә, Хәмзәнә, Лениза апалар сөтне аннан ала. Тагын кайдан алсыннар? Кибет юк бу авылда, автолавка гына килә. Кирәк-яракны әбиләргә шәһәрдәге балалары ташый. Әлфия апаның да атна саен кунак. Бер атнада – бер баласы, икенче атнада – икенчесе... Дүрт баласына биш онык аның.

– Таләпчән иде әни, – дип, балачагын искә ала Ләйсән. – Фермадан кайтыр вакыты җитсә, дүртебез дә сикереп торып, тизрәк эшкә тотынабыз. Эшләтә белде ул безне. Әтиебез булмаса да, әнинең тырышлыгы аркасында юклык күрмәдек. Дүртебезне дә берәм-берәм Әлмәт базарына алып барып, киендереп кайта иде. Юмарт ул, бездән бернәрсәне дә кызганмады. Дүртебезне дә укытты, туйлар уздырып башлы-күзле итте.

Әлфия апаның бавырсак пешерергә осталыгын да белдек. Анысын да Ләйсән әйтте.

– Авылда әнинең бавырсагыннан башка гына өйләнгән яки кияүгә чыккан кеше булмагандыр. Туйга гел аннан пешертәләр. Әле тагын бәйләргә ярата ул. Оекбашларны да гади итеп кенә түгел, бизәкләп бәйли. Укыган вакытта без аңа, мондый бизәк белән бәйлә, дип, заказ бирә идек. Без кушканча бәйләп куя торган иде. Гомер буе ипине мичтә үзе пешерде. Әни турында уйласам, күз алдыма гел аның нәрсәдер эшләгән чагы килә. Башка чагын белмим дә... Без аны ачуланабыз да инде, җитте, тукта, ял ит, дибез. Үзенә тотарга пенсиясе дә җитәр иде. Ә ул гел без дип яши.

– Эшем җайлы бит әле, – ди Әлфия апа. Фермада учетчик-лаборант ул. – Яшьләргә урын кирәк, син кит инде, дисәләр, бер көн дә эшләмәм. Әле алай димиләр бит. Эшләп тора күр, диләр. Беркөнне зоотехник Фоат әйтә: «Әлфия апа, «Карусель» белән сауганны да күрдегез, инде роботларны да күрсәгез», – ди. Шулай дип кызыктырып торганда, ничек эшләмисең?!

Исән-сау гына торса, малларын бетерергә дә исәбе юк әле Әлфия апаның. Буш абзарны күз алдына да китерә алмый ул. Сыеры мөгрәп каршы алмаса, сарыклары кычкырмаса, тавыклары кыткылдамаса – йортында ни ямь? Яшәү яме – эштә, ди Әлфия апа.



Гүзәл ХИСМӘТУЛЛИНА,
олылар һәм балалар психологы,
гештальт-терапевт

«БАШЫН КОМГА БАТЫРА...»

«Узган ел гаиләбезгә зур сынау килде – миндә авыр чир таптылар. Мондый вакытта һәркем якыннарына таяна. Газиз кешең өчен борчылу, хәлен белешү табигый хәл бит. Мин дә иремнән кайгырту, борчылу, кызыксыну, «Борчылма, без бу чирне җиңәрбез, бар да яхшы булыр», дигән сүзләр көттем. Ләкин... ул миннән сәламәтлегем турында бер тапкыр да сорашмады, борчуларымны уртаклашмады. Табибка күренеп кайткач та, ничек булды, ниләр әйттеләр, ничек дәваланырга куштылар, дип кызыксынып карамады. Аның үзен шулай тотуына бик үртәләм, үпкәлим. Үземне кадерсез, кирәксез кеше итеп тоям. Минем хәтта сәламәтлегем өчен көрәшү теләгем дә сүнде.... Ул ник үзен шулай тота икән дигән уй тынгы бирми». (Исемем редакция өчен генә.)

Авыр хәлдә калганда күпләр үзен кечкенә бала кебек тота. Качышлы уйнаган сабыйны күз алдына китерегез әле. Ул битен куллары белән каплый да, без аны күрмибез дип уйлый. Кичереп булмаслык авыр хисләр тудырган күңел газабыннан качар өчен чынбарлыкка күз йому бу. Мин бу турыда искә төшермәсәм йә булмаса бөтенләй онытсам, әлеге проблема үзеннән-үзе бетәчәк дип ышану. Чынбарлыкны ничек бар шулай күргәннән соң, моны кичерерлек көчең юк икәнен аңлагач: «Бар да яхшы булачак, бар да әйбәт, минем бер проблемам да юк», – дип, үз-үзеңне ышандырырга тырышу. Бу – психологик саклану чарасы булган инкарь итү механизмы. Инкарь итүнең көче шуның кадәр зур, ул кешегә чынбарлыкны кабул итәргә мөмкинлек бирми. Кабул итәргә авыр булган, бигрәк тә кисәк, көтелмәгәндә килеп чыккан вакыйгаларны кеше автомат рәвештә кире кага.
Бу механизм негатив мәгълүматтан читләшергә, шул рәвешле һәлакәттән качып калырга мөмкинлек бирә. Әйтеп киткәнемчә, моның нигезендә балалык эгоцентризмына хас әйбер – мин моны кабул итмим икән, димәк, бу юк дигән фикер ята. Кеше һәрдаим, аңсыз рәвештә диярлек, шушы инкарь итү механизмын кулланып яшәргә мөмкин. Игътибар итсәгез, күңелсез хәбәр килгәндә күбебез, «юк, булмас, мөмкин түгел, бу дөрес түгелдер», дип, тискәре фактларны кире кагабыз. Кеше үзенең уй-фикерләрен, хисләрен, талчыгуларын, ач булуын кабул итмәскә мөмкин. Бу инде, үз чиратында, организмның бөтенләй эштән чыгып, хәлсезләнеп, авыруга сабышуына китерә. Инкарь итүне кеше тормышының күп өлкәләрендә күрергә була.

Нишләргә? Иң беренче – проблеманы кабул итәргә, аның проблема булуын танырга. Беренче адым – күрү булса, икенче адым – аны факт буларак кабул итү. Менә хәзер шушы ситуация бар, без әлегә аңа бәя бирмибез, без аны бары кабул итәбез. Өченче адым – шушы проблеманы чишү өстендә эшләү, авырлыкларга әзер торып, аларны ерып чыгу өчен юллар эзләү.

Бу ханымга киңәшем: әйе, ирегез проблеманы кабул итәргә теләми, аңа күз йома. Әлбәттә, аның үз-үзен шулай тотуы сезне үпкәләтә. «Син ник кызыксынмыйсың, хәлемне сорашмыйсың?» – дип, аңа дәгъва белдереп кенә хәл үзгәрмәячәк. Үзегезнең хис-кичерешләрегезне ирегезгә белдерү кирәк, билгеле. Ләкин моны дөрес итеп җиткерә белергә кирәк. «Мин – хәбәр» ысулын кулланыгыз. Мәсәлән: «Син мине үпкәләттең», – дип түгел, «Синең үзеңне шулай тотуың, минем хәлем белән кызыксынмавың, сорашмавың мине рәнҗетә», – дип әйтү мөһим. «Бәлки, боларны кабул итү сиңа авырдыр, минем авыруымны күрү кыендыр», – дип, ачыктан-ачык әйтеп сөйләшегез.

Гаиләдә кемнеңдер сәламәтлеге югалу авыр ситуация, билгеле. Бу вакытта кайгырмый, борчылмый гына булмый. Ирегез дә кайгыра. Кайгыруның төрле стадиясе бар. Беренче стадия – кире кагу. Безнең бу хәл белән килешәсебез килми, аны кабул итәргә теләмибез. Икенчесе – сатулашу: «Ник болай килеп чыкты, ни гаебем бар?» Аннары – килешү, хәлне кабул итү.

Хат авторының ире беренче стадиядә – кире кагу стадиясендә тукталып калган. Психологиядә «контактларны өзү» дип тә атыйлар моны. Аның үз-үзен болай тотуы – җаваплылыктан качарга омтылудан. Бәлки, аны гаиләдә шулай үстергәннәрдер, җаваплылык йөкләмәгәннәрдер, тормышта да үз өстенә артык җаваплылык алырга теләмидер. Болай яшәве җайлырак бит.

Беркем дә беркемне үзгәртә алмый. Үзгәрер өчен кешенең үз теләге булырга тиеш.
Идеаль кешеләр юк. Ир-ат үзен болай тота икән, монда ул үзе генә гаепле дип уйларга кирәкми.
Без үзебез ничек ирек бирәбез, башкалар безгә шундый мөнәсәбәттә була.

Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.

«РӘНҖЕМӘ МИҢА, КЫЗЫМ...»

Ул аның каберенә еллар үткәч кенә кайта алды. Юк, еракта – диңгез-океаннар артында яшәгәнгә түгел, күңеле тартмаганга.



Мәдинә АВЗАЛОВА

...Әнә алар иртә таңнан ашыга-ашыга кайсы кая җыена. Әнисе башта әтисен ишеккә кадәр озата бара. «Соңга калам...» – ди кызчык, әнисенең әтисе кочагыннан чыгасы килмичә торуын күреп. Аннан әнисе аны машинасына утыртып мәктәпкә илтә. Көн саен шулай. Тиздән аңа 14 яшь тула. Ә әнисе аны һаман кулыннан ычкындырмый. «Миңа шулай тыныч», – ди. Ял көннәрендә дә алар гел бергә. Йә циркка, йә спектакльләргә баралар... Рәхәт чаклары булган икән аның да.

Ә бер көнне җай гына, матур гына барган тормышның асты-өскә килде. Аларның тормышы түгел, бөтен дөнья үзгәргән сыман тоелды Гөлназга. Җәй уртасы иде. Шундый матур көннәрнең берсендә җыйнаулашып бакчага киттеләр. Бу эсседә өйдә ни эшләп ятасың, бакчада рәхәт ичмасам: саф һава, һәр тарафта чәчәкләр, җиләк тә өлгереп килә әнә... Чүп үләне утап алҗыганнан соң, әтисе машинасына утырды да, «балыкка» дип, ике-өч чакрымдагы күлгә китеп барды. Әнисе Гөлзилә аңа: «Әллә бармыйсыңмы? Иртәрәк кайтып китәрбез дигән идем. Кичен кунаклар килә», – дип тә карады, әтисе кул гына селтәде. Янәсе, өлгерәбез әле. «Мин тиз, бер-ике чуртан гына эләктерәм дә...»

Караңгы төшә башлады. «Тиз кайтам, диде бит. Ни булды икән?» Күлгә юл бер генә: Гөлзилә кызын кулыннан эләктереп алды да, төнгә кереп барган чокырлы-чакырлы юл буйлап йөгерәатлый, машина киткән якка юнәлде. Шул чагында әнисенең бәргәләнүләрен, су тирәли арлы-бирле чабуларын, «бәгърем» дип, өзгәләнүләрен Гөлназның гомергә дә онытасы юк. Әнисе әтисенә гел шулай дип дәшә торган иде: «бәгърем»... Әтисе җир упкандай юк булды. Көттеләр, һаман көттеләр. Әнә бит машинасы кул кырыенда гына. Аңа берни булмаган. Гөлзилә белән Гөлназ машина янында төн чыктылар. Таң атуга янә йөгереп бакчага кайттылар. Аннары.. Аннары башларына кинәт килеп төшкән олы кайгыдан акылдан язар дәрәҗәгә җиткән әнисен хастаханәгә алып киттеләр. Бөтенесе күз ачып йомганчы булды. Әтисенең үле гәүдәсен судан тартып чыгарганда әнисе бер генә сүз әйтте: «Бетте...» Ул чагында Гөлназ моны үзенчә аңлады. «Бетте, әни, бетте... әтине таптылар», – диде ул әнисен юатырга тырышып. Әтисез калганнан соңгы, көннән-көн сүнә барган тормышны күз алдына китереп әйткән булган икән әнисе.

Әнисе хастаханәдә чагында кызны әбисе карады. Карап торган бердәнбер улының юлына очраклы гына чыккан бер наркоман кулыннан вафат булуында ана киленне гаепләде. «Ник ялгызын җибәрдең?» Күрәчәгеңне күрми гүргә кереп булмый. Кем уйлаган шундый фаҗига буласын? Ул гел шулай ялгыз йөри иде бит. Шулай да... Әнисенә бу сүзләр җитә калды. Кадерле кешеңне югалту хәсрәтенә үзеңне гаепле хис итү ачысы да өстәлде. Менә монысы инде авыр иде. Бу тойгыдан арыну да, качу да мөмкин түгел иде.

Хастаханәдән кайтуының беренче көнендә үк әнисе күрше хатынны чакырып, табын әзерләде. «Бәгыремне искә алыйк», – дип, чәркә тулы аракыны эчеп җибәрде. Аның гомергә эчкәне юк иде. Өйләрендә гомумән дә спиртлы эчемлекләрнең булганы юк иде. Күрше хатын да аннан калышмады. Кайгысын уртаклашты. Шул көннән барысы да үзгәрде: әнисе дә, тормышлары да. Үткәне хәзер инде матур әкият булып тоелган кыз өчен көн саен кабатланып торган ямьсез күренешләр беркайчан бетмәс сыман тоелды. Балага мөнәсәбәт үзгәрде: Гөлназ аның өчен әллә бар, әллә юк... Эштән кайтып кергән әнисенең күзенә берни күренми. Ашарга пешерсә пешерде, пешермәсә – юк. Яшел елан аны бик тиз буып алды. Әтисенең мәрхүм булуына ел дигәндә, ул, үзе әйтмешли, тәмам «бетте». Кайнана киленен үгетләп тә, ачуланып та карады. «Балаң кызганыч», – дип тә акылына китермәкче булды. Тик файдасыз. Аңа барыбер иде.

Көннәрдән бер көнне ул эшсез калды. Зур һәм дәрәҗәле оешманың баш бухгалтерын хөрмәтлиләр, яраталар иде. Гөлзиләнең белмәгәне юк иде. Аны «аяклы компьютер» дип йөрттеләр. Эчә башлаганын белделәр, уңайсызланып кына, эштән китүен сорадылар. Берсе дә ярдәм итәргә ашыкмады. Хәер, эчкән кешене, бигрәк тә хатын-кызны эчүеннән туктату бик авыр. Якыннары булышса гына. Ә аның булышырдай кешесе юк. Хатын өчен эштән китү янә бер стресс булды. Ничек яшәрләр хәзер?.. Гөлназ мәктәптә вакытта ул шешәдәшләр эзләп, урамга чыгып китә башлады. Һәм... Шулай йөри торгач, юкка чыкты. Әбисе белән Гөлназ аны урам бетереп эзләде. «Берәрсендә утырадыр гына, әйдә, кызым, безгә», – дип үгетләде әбисе. Юк, Гөлназга әнисен табарга кирәк. Аны беркөнне урамда күргәннәр. Димәк, ул монда – якында гына. Иртәгә табар ул аны, һичшиксез табар... Кыз шулай уйлады.

Һәм чыннан да тапты. Дөресрәге, каршысына әнисе үзе килеп чыкты. Гөлназ сыйныфташ кызлары белән мәктәптән кайтып килә иде. Нииндидер ир белән айкала-чайкала барган хатынны күрүгә, кыз ачыргаланып кычкырып җибәрде. «Әнием, мин сине бер ай эзлим бит инде, бер ай... Син нигә өйгә кайтмыйсың? Мин бит ялгыз, мин куркам». Алсу бит алмалары суырылып калган, янып торган күзләре тоныкланган, куе-бөдрә чәчләре нидәндер укмашып каткан хатынны йөгереп барып кочып алды кызы. Танымаслык булып үзгәргән әнисенең үз-үзен тотышы бик сәер иде. Ул кызына – йөрәк пәрәсенә бермәл хәйран калып карап торды да, аннан бөтен көченә этеп җибәрде. Кыз ыгы-зыгы машина чабып торган юл кырыена барып төште. Һәм авыртудан түгел, кимсенүдән, әнисенә рәнҗүдән кычкырып елап җибәрде. Бу тамашаны котлары алынып күзәтеп торган сыйныфташлары, йөгереп, Гөлназ янына килеп җиттеләр. Торгызып, калтыранган кулларыннан җитәкләп алдылар. Ә әнисе аңа әйләнеп тә карамады. Таныш булмаган чит-ят ир белән китеп барды.

Өенә кайткач, идәндә тәгәритәгәри елады Гөлназ. Кызлар алдында оят иде. «Хурлык, хурлык, әби, нишлим хәзер?» Әбисе баланы күкрәгенә кысты: «Берни дә эшләмисең. Син гаепле түгел. Мин синең яныңа күчәм. Бергә булырбыз», – дип юатты оныгын. Күршеләренең әйтүенә караганда, бала белән опека бүлеге хезмәткәрләре кызыксына башлаган иде инде.

Гөлназ әнисен башка эзләмәде. Кайтмас инде дип, өметен өзде. Ә ул көтмәгәндә, берни булмагандай кайтып керде. Гөлназ кухняда савыт-саба юа иде. Әбисе исә: «Өемә барып киләм», – дип чыгып киткән иде. Ишектән керүгә үк, кухняга үтеп, Гөлназның кулыннан тәлинкәсен алды да, «үзем», дип юарга кереште. Кыз имәнеп китте, ни әйтергә белми, телсез калды. Өнеме бу аның, төшеме? Аракы исе дә килми. Эчмәгән, әллә эчүен ташлаган? Кыз тәрәз кырыена килеп утырды. Ялгыш терсәге белән тәрәз төбендә үсеп утырган яран гөленә кагылды. Ул шап итеп идәнгә төшеп ватылды. Шунда гына әнисе уянып киткәндәй булды: «Харап иттең яраткан гөлемне!» «Синең дә яраткан әйберең булыр икән...» Гөлзилә кызының мыскыллы сүзләрен ишетмәмешкә салышты. Үзе гаепле. Хәзер баласына барын да аңлатырга, аңлашырга кирәк иде. Аңлар микән? Әнә нинди зур кыз булган ул. Их-х, әтисе күрсә, ниләр дияр иде икән?!

Әйе, аларның икесен дә авыр сөйләшү көтә иде. Гөлзилә зур бүлмәгә чыгып утырды. Янына кызын чакырып алды. Сөйләвенә караганда, ул айга якын наркология диспансерында яткан. Имеш, аны урамнан табып алып илткәннәр. Хатын үзенең анда ничек эләгүен белми дә. «Башка эчмәскә ант иттем, кызым. Эчмим, үлгәндә калдым. Хәзер безнең синең белән яңа тормыш башлана», – диде әнисе әллә кызын, әллә үзен ышандырырга тырышып. Гөлназ аны кочып алды: «Мин ышанам сиңа, әнием. Син бит әти барында бөтенләй эчми идең». «Әтиең барында күп нәрсә башкача иде лә ул...» Алар икәүләшеп елап та алдылар. Гөлназ өчен бөтен бәла, бөтен авырлыклар артта калды. Һәрхәлдә, аңа шулай тоелды. Әнисе аны тагын янган учакка ыргыта, өметсезлектә, көннән-көн буа барган караңгылыкта калдыра алмый ич инде. Ул – аның әнисе, бердәнбер якын кешесе. Әбисен исәпкә алмаганда, әлбәттә. Кыз укуын тәмамлап килә. Хәзер институтка әзерләнә. Архитектор булу – күптәнге хыялы.

Гөлзилә кызын башын аска иеп тыңлап утырды. Гөлназы аның үзенә охшаган. Ул да куйган максатына

Фото: ru.freepik.com

Үз-үзеңнән качу мөмкин түгел. Моны ул яхшы аңлады. Балачагының авыр мизгелләре аны артыннан калмый озата барды.

ирешмичә, әйткәнен үтәмичә калмый иде. Укырга да керер, зур, дәрәҗәле кеше дә булыр. Икеләнми: холыклары, нәселләре шундый аларның! Тик менә сөекле иренең үлеме генә аяктан екты, адәм мәсхәрәсенә калдырды аны. Кайгыга биреште ул.

Гөлзилә эшкә бик тиз урнашты. Өйләреннән ерак та булмаган бер кафеда бухгалтер булып эшли башлады. Гөлназ имтиханнарын гел «биш»легә тапшырып, институтка керде. Барысы да ул уйлаганча, уңышлы барды. Әнисе эшли, ул теләгән җирендә укый. Әбисе дә ташламый, хәлләрен белешеп тора. Тагын ни кирәк?! Кыз бәхетле иде. Фәрештәләр качкан өйгә янә нур иңде, ямь керде. Әнисе дә танымаслык булып үзгәрде. Әйтерсең аны алыштырып куйдылар! Янында Гөлназы булган Гөлзиләгә берни кирәкми иде. Тормыш вак-төяк мәшәкатьләр белән дәвам итә торды.

...Гөлназның 4 нче курста укыган чагы. 8 Март бәйрәме алдыннан студентлар, җыелышып, ресторанга киттеләр. Егетләр чакырды – кызлар теләп риза булды. Сөйләшеп-көлешеп, күңел ачып утырган бер мәлдә ресторанга әнисе белән бер ир-ат килеп керде. Гөлназ әнисенә текәлеп карады да имәнеп китте: эчкән! «Бетте...» – диде ул, әнисенең сүзләрен кабатлап. Дөресрәге, кабат башланды... Шул чагында ничек кенә ялвармады кыз әнисенә, нинди генә җылы сүзләр әйтеп, акылына китерергә тырышмады – файдасыз. Бар әйткәне: «Кайта тор. Мин хәзер...» – шул булды. Гөлназ аны елый-елый, тәрәзәдән күзен алмыйча таңга чаклы көтте ул чагында. Әнисе иртәгесен дә, бер атнадан соң да кайтмады. Тагын югалды. Кыз аны эзләп эшенә барды. «Юк ул», – диделәр. Яшел елан чире кагылган кеше һәрчак упкыннан бер адымда йөри. Чак кына тайпылды исә, аны тотып калу мөмкин түгел. Гөлназ бу хакыйкатьне үз җилкәсендә күп мәртәбәләр татыды инде. Ачуы да чыкты, кызганды да ул әнисен. Нинди бәхетле иде алар әтисе барында! Бергә булсалар, берни кирәкми. Юктан да юаныч, шатлык таба торган иделәр.

Шуннан соң Гөлзилә шактый вакыт күзгә күренми торды. Әллә нигә бер Гөлназга шалтыратып, хәлен белешкәләде. Әнисенең бу кыланмышларыннан тәмам күңеле кайткан кыз үзен аның белән бик коры тотты. «Әйе», «Юк»тан башкасын әйтмәде. Яши-яши ул инде мөстәкыйльлеккә өйрәнгән иде. Көндезен укыды, кичләрен эшләде. Үзенә җитә торган иде. Айлар арты айлар үтә торды. Гөлназ да инде укуын тәмамлап килә әнә. Диплом якларга әзерләнеп йөргән иң авыр көннәре... Ярый әле янында әбисе. Терәк ул аңа, таяныч. Канатландыра, юата белә. Бик ярата ул аны. Авыр чакта ялгыз калдырмады, ташламады әбисе. Аның: «Хастаханәдән шалтыраттылар. Әниеңнең хәле начар...» – дигән хәбәренә кыз тирән борчуда калды. Ул әле аның исән булуына, кайдадыр якында гына йөрүенә, кайчан да бер кайтып күренәсенә өметләнеп яши иде. Эчкечелек юньлегә илтми. Ул хәерсез юлның ахыры бер генә.

Гөлназ, дөньясын онытып, хастаханәгә чапты. Йөзе белән стенага борылып, бөгәрләнеп яткан әнисен күрүгә, янына килеп утырды да, кара куе чәчләреннән сыйпый-сыйпый, еларга керешге. Әнисе аңа таба борылуга, кыз үзе дә сизмәстән сикереп торды. Караватта хәлсез яткан, йөзе кара янып, күз төпләре шешенеп, танымаслык хәлгә килгән әнисе аңа йөрәкне өздереп алырдай таныш та, шул ук вакытта чит тә иде... «Нишләдең, әни? Нишләттеләр сине?» Телен көчкә әйләндереп, әнисе аңа бер генә җөмлә әйтә алды: «Рәнҗемә миңа, кызым». Әйтерсең ул шушы сүзләрне әйтер өчен генә баласын көтеп торган. Соңгы мәртәбә Гөлназын күреп, гафу үтенеп, кызының кулында мәңгелеккә күзләрен йомды.

...Бу хәлләргә биш еллап вакыт узып китте. Гөлназ теләгәненә иреште. Тырыш, үҗәт ятим балага Ходай юлларын ачты. Ул оста белгеч булараk үзен бик тиз танытты. Талантлы архитектор дөньякүләм үткәрелә торган зур-зур киңәшмәләргә барып, абруйлы кешеләр белән очраша, уртак проектларда катнаша башлады. Һәм... көннәрдән бер көнне аны ерак диңгезләр артындагы илләрнең берсенә эшкә чакырдылар. Ул ике дә уйламады – чит телләрне яхшы белә, аралашу тәҗрибәсе җитәрлек – шундук риза булды. Чит илгә китүенең тагын бер җитди сәбәбе – ара-тирә күңелендә давыл булып күтәрелгән авыр хатирәләрдән качу. Бүгенгесе ничек кенә уңышлы булмасын, үткәне аңа барыбер тынычлык бирми, кимчелекле булу тойгысыннан һич кенә котыла алмый ул. Аның хәле боз астында йокымсыраган диңгезне хәтерләтә. Менә ул уянып китәр, бөтен җанын айкап ташлар сыман. Ә Гөлназның барын да онытасы, онытыласы килә.

Әйе, китеп дөрес эшләде ул. Күңеле тулганда, фатирыннан кул сузымында гына урнашкан диңгез буйларында йөргәндә, берәүгә дә сөйли алмаган эч серләрен аягына ята-ята бәргәләнгән дулкыннар белән туйганчы серләшә ала. Берниндиы киңәшкә дә, киңәшчегә дә мохтаҗ түгел ул хәзер. Вакытлар үтүгә, туганнарыннан ераклашырга, алар белән аралашмаска дигән сәер уеннан да кире кайтты. Ни өчендер ул аларга үпкәле иде. Ә хәзер, киресенчә, алар янындарак булырга, элемтәләрне өзмәскә тырыша. Әнисенең сүзләрен исенә төшергәндә сискәнеп куя. Әтисе үлгәннән соң ике дөнья арасында бәргәләнеп йөргән бичара әнисенә ничек рәнҗесен, ничек үпкәләсен?.. Биреште, адашты, югалды... Нишлисең... Көчле холыклы булып чыкмады аның әнисе. Югалту кемнедер әнә шулай таптап китә, ә кемнедер, киресенчә, тимердәй нык итә.

...Биек наратлар арасында калган кабергә борылып карый-карый, Гөлназ зираттан чыгу юлына борылды.

ӘНИЛӘР ТӨРЛЕ БУЛА...



Марат
КӘБИРОВ,
язучы

Автобуста янәшә утырып кайта идек ул ханым белән. Әниләр турында сүз чыкты да ничектер чишелеп китте. Аңлыйм инде, мондый нәрсәләрне теләсә кемгә сөйләп булмый, таныш түгел кешегә түгелеп, бушанып калыйм, дигәндер. Шуңа мин кирәксез сораулар бирмичә генә, тыңлап бардым.

– И-и, аңламассың инде аны… Экономия дип кенә дә әйтеп булмыйдыр. Киемнәрен дә челтәргә әйләнеп беткәнче киеп йөри бит, нинди төстә икәнен дә белерлек түгел. Яңаны кайтарып бирсәң дә кидереп булмый, сандыгына салып бикләп куя. Ашау ягын да гел кысып кына тора: ит ашамый, баллы нәрсәләргә исе китми, бар белгәне – ботка да бәрәңге. Кеше белән аралашмый. Хәтта оныклары да аның янына кайтмаска тырыша, чөнки бөтен нәрсәгә кысылып утыра: «Утны сүндер, суны күп агызма, шикәрне күп салма, чәйне чамалап…» Монысы гына бер хәл әле, врач язып биргән даруларның да яртысын гына эчә. Үзенчә экономия ясый. Янәсе, шулай итсәң арзангарак төшә. Шуннан моның кан басымы күтәрелеп китә. Ә врачларга: «Сез биргәннең барысын да җиренә җиткереп эчеп барам», – дип алдаша.

– Дарулар шулкадәр кыйммәтлемени соң? – дигән булам, сүзне дәвам итәргә теләп. – Хәер, бардыр инде…

– Юк, аена биш меңнән артмый. – Ханым шулай зарланган кебегрәк сөйләсә дә, тавышында бернинди нәфрәт-фәлән юк. Ниндидер җылылык, хәтта бераз шаянлык та ялтырап китә. – Аның пенсиясе өчен бу әллә ни бәя түгел. Анысын да күп очракта үзем сатып алам. Азык-төлеген дә кайтарып торам, кием-салымын да. Кими, дим бит, ашамый да. Саклый. Акчасын да саклый ул, пенсия алган саен банкка салып куя. Югыйсә зур чыгымнар чыгарып эшлисе эше дә юк. Барысы да җитеш. Кайчагында үзе дә мактанып ала ул миңа: «Миллионнан артык акчам бар», – ди. Бардыр, әллә ничә ел буе җыя бит инде. Ашау-эчүдән, киемнән баш тартып җыя. Якыннары, күршеләр, ахирәтләре: «Ник шулай бомж сыман киенеп йөрисең, ашавыңны да кысасың?» – дип сораса, күз дә йоммыйча: «Балаларга ипотека түләргә ярдәм итәм, бөтен акча шунда китә», – дип сөйли икән. И-и, Аллакаем…

Ханым бер мәлгә тынып калды. Аның сүзне икенчегә боруыннан куркып, мин тагын сорап куйдым:

– Ярдәм итәме?

– Әйе, менә! – ханым моңсу гына елмайды. – Безнең гомергә ипотека алган булмады. Иремнең хезмәт хакы әйбәт, үземнеке дә ярап торырлык. Әнидән бер тиен дә сораганым юк. Мәктәпне тәмамлау белән үз көнемне үзем күрдем. Тик аны бит барысы да белми. Күршеләр кайвакыт мине шелтәли: «Ник әниеңне карамыйсың, берәр юньлерәк күлмәк алып бирсәң, хәерчегә төшмәс идең», – диләр. Кыен булып кала…

Кайчагында бернәрсә дә аласым килми. Үзенең акчасы җитәрлек, алсын, киенсен, ашасын. Алмый икән, димәк, аңа шулай рәхәт. Аннан, балаларым авызыннан өзеп, нигә мин аңа нәрсәдер сатып алырга тиеш соң әле? Ул банкны баетсын, ә мин сатып алыйм… Кайчагында шулайрак уйлыйм, пыр тузам эчтән генә. Тик барыбер алып кайтам инде. Бәлки, монысы ошамагандыр, дип, бүтән төрле кием алам. Ә ул барыбер сандыгына тыгып куя… Соңыннан бөтен туганнарга, күрше-күләнгә сөйләп йөри: «Балаларыма, оныкларыма акча бирәм», – ди. Бермәлне: «Ник шулай сөйләнеп йөрисең?» – дип шелтәләп алган идем, үпкәләде. «Мин үлгәч, барыбер сезгә кала бит ул», – ди.

Ярар инде… Миңа аның акчасы кирәкми. Теләсә ничек җыйсын, теләсә кая куйсын, хет берәр приютка мирас итеп калдырсын… Анысында эшем юк. Тик ул үзен чикләмәсен иде, хет мин кайтарган әйберләрне кисен, ашасын иде. Ә мин аңа барыбер буш кул белән кайтмыйм инде, кайтмаячакмын да. Аны мин карарга тиеш бит инде. Менә әле дә киемнәр төядем, ризыклар алдым…

Ханым тагын моңсу гына елмаеп куйды. Ә бераздан, үзенең шулай ачылып китүенә үкенгәндәй, миңа карап алды да гафу үтенде. Гаепләми генә тыңлап килгәнем өчен рәхмәт тә әйтте. Һәм тиздән ике зур сумкасын сөйрәп, ишеккә юнәлде.

Мин дә аны моңсу елмаеп озатып калдым. Гаепләмәдем. Үзен дә, әнисен дә. Үзенә бераз сокланып та куйдым бугай әле. Ә әниләр… Олыгайган көннәрендә нинди генә хәлгә төшсәләр дә, алар барыбер безнең әниләр бит инде.





«МӨХЛИСӘ АПА, ЧЫГЫП АЛ!»



Эльмира ЗАКИРОВА

Безнең өй зур – алты почмаклы. Бабкай, әти белән әни, мин, сеңлем шул болын чаклы өйдә яшибез. Ләкин безнең яшәешне, безнең дөньяны Мөхлисә апалардан, алар өеннән башка күз алдына да китереп булмый. Без шул өйдә дә яшибез кебек тоела миңа кайчак. Иртән торуга шунда йөгереп керәбез. Болай гына, бер сәбәпсез дә. Аларда күңеллерәк, чәйләре дә тәмлерәк кебек. Кайчак кунып та калабыз. «Түткәйләргә кереп чыгам әле», – дип, әни дә бертуган апаларыннан көнгә ничәмә тапкырлар урыйдыр. Мөхлисә апа үзе дә әллә ничә кереп чыга безгә. Йә сөт кертә, йә мунча яктым, дип хәбәр итә, йә магазинга һинд чәе кайткан, дип сөенче ала. Әти белән әни көне буе мәктәптә чакта, бабкай берүзе ямансулап ятмасын дип, хәл-әхвәл белешеп тора. «Әткәй, кабак бәлеше салдым, керерсең, яме» яки «Әткәй, тары тәбикмәге белән чәй эчәргә кер, озаклама», – дисә, лыштыр-лыштыр галошларын сөйрәп, таякка таянып, сакалын сыпыра-сыпыра бабкай юлны чыга башлый, аның артыннан койрык кебек без тагылабыз. Кешеләр күп булып, без һаман шунда буталсак, түземе төкәнгән Мөхлисә апа: «И-и бәбекәйләрем, өегез болын кадәр, барыгыз, бераз шунда чыгып уйнагыз әле», – дип тә әйтеп куя. Чыгып киткән булабыз да, тагын кабат кереп җитәбез. Магниты бар диярсең!



Минем сөт әнием дә әле ул Мөхлисә апа! Үз әниемнең күкрәкләре шешкәч, тугач та мине имезгән. Аның Гөлсинәсе белән бертуганнар кебек без, аермабыз дүрт кенә ай.

Мөхлисә апалар минем өчен – аның биш баласы, төпчекләре Гөлсинә туып, озак та үтми бакыйлыкка күчкән Кәбир җизни рухы, кара сыер, сарыклар, усал ата каз, аклы-сорылы песиләре, хуш исле печән белән тулы сәндерә, җәйләрен өй тулы халык барында карават чыгарып куела торган кар базы келәте... Колхозга көн саен ике тапкыр ипи пешерә торган ак мич... Ком белән ышкып юылган ап-ак баскычлар... Җәйге кичләрдә, көтү кайтып, сыерларны саугач, бөтен күрше-тирәне җыя торган капка төбендәге утыргыч... Аларга җәйләр җәйләргә кайткан бетмәс-төкәнмәс кунаклар... Ул кунаклар – кайчандыр бик яшь килеш авылдан чыгып китеп, инде бер якын туганы да калмаган күршеләр була, гадәттә. Сары гәрәбә муенсаларын тагып, эре чәчкәле крепдешин күлмәкләрен җилфердәтеп, эрбет чикләвеге, мүк җиләге каклары, тәм-том төяп, Североуральскидан кайтучы Фәрдәнәттәй, пароходтан төнлә Әҗәкүл пристанендә төшеп калып, иртүк Шәркасыйм абый бензовозында кайтып кергән, күчтәнәч «крантеллары» (сушкиклиндерләрне шулай әйтәләр бездә) белән сыйларга яраткан Уфа Җәмилә апа, Ижаудан – «дур инәй» (Мөхлисә апаның килендәше «зур җиңгәй»не шулай йөртәләр иде)... Мөхлисә апаларда халык күбәя башласа, бер күзе сукыр шул бәләкәй Җәмилә апа сандык кадәр олы чемоданын сөйрәп, безгә күченә. Бабкай аны бик жәлли, бәләкәйдән ятим калып, Уфага китеп барган иде, ди. Бер яһүд врачы гаиләсенә бала караучы булып урнашкан. Шул врач гаиләсенең башлыгын «хозяин» дип йөртә, аның хатыны Циляны, аларның балаларын гел мактап сөйли. Олы яшьтә инде ул, әниләр Җәмилә апа дип йөрткәч, без – бала-чага да аңа шулай эндәшәбез. Ә бервакыт Җәмилә апаның «хозяин»ы Ефим Борисович та, безнең яшьтәге балалары Рита һәм Марикны ияртеп, авылга кунакка кайтты. Мөхлисә апа бәлеш салып, төшләр пешереп, чөгендер катыклары оетып, үзенчә зурлап, ашка алды аларны. «Махлиса апа, бик тэмле!» – дип, яһүд Кушнер татарча мактый-мактый ашагач, и шаклар каттык инде! Кайчак бер-ике сүз булса да татарча әйтүе өйдәгеләр күңеленә дә хуш килде. Без, 7-8 яшьлек кызлар (сеңлем дә Рита исемле, кунак кызы белән адашлар), үзебез дә оялып кына русча сөйләшергә тырышабыз. Тик әллә каушаудан, әллә артык тыйнаклыктан, кирәк чакта русча сүзләр искә төшми интектерә! Ә Ефим Борисович безне бәрәңге кәтмәнләгәндә дә, көянтәләп су ташыганда да, урманда чәчәкләр җыйганда да, Сөн буендагы комлыкта йөгерешкәндә дә, Рита белән Марик бадминтон уйнаганда да черт тә черт фотога төшерә. Гел фотоаппаратын үзе белән йөртә ул абый.

Кушнерны тагын бер нәрсә хәйранга калдырды. Ул да булса – Мөхлисә апа салган ипиләр. Ул кайнар ипинең тәмлелеге! Аның хуш исе! Безнең очка, юк, бөтен авылга шул ис таралып, борыннарны, җанны кытыклый! Миче өлгерүгә, Мөхлисә апа башта кызыл күмерләрне кисәү агачы белән казан астына тартып китерә, аннары юкә пумала белән көлләрен сыпыра, кызыл көле җемелдәп торган мич төбенә агач көрәк белән ипиләрен тыга, йөзе килгәнме дип карап-карап ала... Пешеп чыккан кап-кайнар күмәчләр инде бераздан ат арбасына тезелә... Басуда, амбар алдында, ындыр табагында эшләүчеләр «Мөхлисә ипием» мактый-мактый ашыйлар.

Аларның өе кечкенә, бер генә бүлмәле. Мич янынннан чәчәкле чаршау сузып, аш-су әзерләү почмагы да көйләгәннәр. Сәке дә шул якта. Кышкы чатнама суыкларда аның астында бөдрә бәрәннәр бәэлдәшә. Сарык, бәрәннәрен имезергә кереп, тояклары белән «ток» итеп тибенеп куя, мин, котым алынып, сандык өстенә менеп басам! «И куркак җан!» – дип көлә Мөхлисә апа яратып. Кышларын калай мич кертеп куялар. Анда ялкынланып янган каен тузлары ниндидер серлелек иңдерә. Өй жылынып, ямьләнеп китә. Җәйләрен түрдә ак ашъяулык ябылган түгәрәк өстәл, вазадагы урман чәчәкләре,

зәңгәр кыңгыраулар, ак кылганнар, ачык тәрәзәдән кергән урамдагы авазлар әллә нинди купшылык өсти шул кечкенә генә өйгә. Кечкенә булса да, анда барысы да сыя! Менә шунысы табышмак инде безнең өчен. Мөхлисә апа үзе, Казандагы олы кызы кайтарып куйган 3 яшьлек оныгы Булат, уртанчы кызы укытучы Вәсимә, флотта хезмәт итеп кайтып өйләнгән улы Илгиз һәм килене Рәйханә (Миләүшәләре тугач, алар башка чыкты), армиядән кайткан улы Индус, мәктәптә укучы Гөлсинә… Мөхлисә апаның бер кызык гадәте бар: өч чакрымдагы Яңа Байсарга җәяүләп почта ташучы Шәмсекамал апаны да, югары очка кайтучы Хәят әбине дә чәй эчәргә чакырып кертә. Алай гынамы, авыл аша узучы гел таныш түгел юлчыларны да, жәлләп, тәрәзә шакып өйгә чакыра, табынга дәшә. Кайбер карчыкларны аштан-мазардан ияртеп кайтып, кундырып ук җибәрә. Андыйларга урын түрдәге караватта инде! Аларга кадер-хөрмәт инде! Гөлсинә, Индуслар кайсы раскладушкага, кайсы сандык өстенә ята ул кичне.

Аларда каз өмәсе гаҗәеп бер вакыйгага әйләнә. Чөнки анда без – бала-чага да катнашабыз! Каз каурыйларын сыдырып, мендәрләргә дигән мамыгын җыеп барабыз да чиләкләргә ак чәчәкләр кебек каурыйларны салып, су буендагы карлы сукмакларның як-ягына сибеп кайтабыз. Шулай итсәң, алдагы елда да казлар уңа, ди Мөхлисә апа.

Әти белән әни педсоветта йә политукуда чакта, Рита белән мин дә шатлана-шатлана Мөхлисә апаларга керергә ашкына башлыйбыз. Һәм шунда кунып та калабыз. Бераздан үзебезнең өйгә чыгасы килә килүен, ә монда инде ут сүнгән, бар да йокларга яткан! Бозлы тәрәзәдән безнең өй, утлары белән балкып, морҗадан күтәрелүче төтеннәре белән ымсындырып (иртәнгә җылы булсын дип мичкә якканнар инде!), бигрәк серле күренә. Берсендә сеңлем, әниләр янына чыгам, дип, мышык-мышык елый ук башлады. Нишләсен Мөхлисә апа, фуфайкасын элеп, киез итеген киеп, елак кызны әти-әнисенә тапшырырга чыгып китте. Ә мин – үз кызлары кебек йөрим. «Биш»ле алсам да, математикадан мәсьәлә чыкмаса да, юлның теге ягына уктай атылам. Чабып килгән хутка шул ук тизлек белән капкадан кереп тә китәр идем дә… Ата каз муенын сузып, ысылдап килә башлый. Шәрран ярып кычкырам инде: «Ата казыгыз талый! Мөхлисә апа, чыгып ал!» Кирәкле кишер яфрагы димә инде! «И кызым, тими ул, тими, курыкма», дип сөйләнә-сөйләнә, мине җитәкләп алып кереп китә Мөхлисә апа. «Ай-яй, каты чаба идең! Син килеп бәрелүдән коймалар инерция буенча бертын селкенеп тора иде хәтта!» – дип, әле дә искә ала Гөлсинә. Ул бер класска югарырак, җитмәсә, математикадан шундук чишеп ата мисал-мәсьәләләрне, дәрестә тыңлап утырмыйсыңдыр, дип, апа роленә кереп, әрләп тә куя. Аннары мичтә тәгәрәткән бәрәңге ашарга чакыралар. Безнеке дә тәмле инде ул кабыклы бәрәңге, ләкин боларныкы – бөтенләй башка. «Сезнең бәрәңге бигрәк тәмле! Йомырка тәмнәре килә!» – дип ычкындырам. Бөтенесе пырх итеп көлеп җибәрә. Ә чәй янына туралы май, балан бәлеше, кош теле, лимонлы карамельләр, баллы прәннекләр куела. Самавыр чыжлап утыра. Аның чыжлавы гел тынмый бугай бу өйдә.

Аларга кич утырырга Саниятттәй, Зәкияттәй, Гатикәттәйләр, Мөсаллия җиңгәчәй, Сәрби әбекәй, күрше Хәйдәр корткалары җыела, Сәфәрдән Зөләйхәттәй утырмага килә кайчак. Бәйләм бәйлиләр, дөнья хәлләрен сөйләшәләр, егерме ел элек булган Бөек Ватан сугышы афәтләрен әрнеп искә алалар, кайтмый калган туганнарын юксыналар. Шунда әбиләрнең берсе сигезенчеләрдә укучы Индустан: «Улым, ул каһәр суккан сугыш булмас микән кабат?» – дип, шомланып сорап куя. «Юк, әбкәй, бүтән сугыш булмаячак!» – ди Индус. Ул әбинең сөенүләре! «Улың сугыш булмый дип әйтте бит, Алланың рәхмәте яугыры!» – дип куюлары… Шул малайны ир бала, зур кеше итеп күреп, ихлас ышануларын әйт! Оборона министры әйткәнмени! Аннары сүз клубта укытучылар куйган «Зәңгәр шәл»гә, Хәйдәр корткасында фатирда торучы укытучы кызларның шунда оста итеп уйнауларына күчә, ике көн рәттән клубта халык соравы буенча күрсәтелгән һинд киносын да телгә алалар, ул да булмый радиодан парторг Газетдинов абый чыгышын тын да алмый тыңлыйлар… Һава торышын, төрле сынамышларны искә төшерәләр. «Азат хатын»да, «Социалистик Татарстан»да шулай язганнар дип, берәр вакыйганы сөйләп китәләр. Без – бала-чагадан «Мең дә бер мәзәк» китабын кычкырып укыталар. Ул әбиләрне шыпырт кына тыңлап, сүзләрен күңелдән үткәреп утырырга яратам мин. Күп вакыт оеп китеп, шунда гына йоклап та калам…

Ә иртәнге биштә инде радиодан: «Өфө һөйләй! Өфө вакыты менән…» дигән тавышка уянып китәбез. Безнең авылда гел шулай: башта Уфа тапшыруларын тыңлыйлар, Фәридә Кудашева, Илфак Смаков җырлары яңгырый. Гөлсинә, тиз генә киенеп, мәктәпкә киткәнче, бәкедән су алып кайтырга җыена. Мин дә үзебезнең өйгә ашыгам: форма күлмәк киясе, китап-дәфтәрләрне портфельгә тутырасы бар. Иртәнге алтыда инде «Казан сөйли! Хәерле иртә, хөрмәтле радио тыңлаучылар!» дигән җанга якын тавыш сәламли. Мәктәпкә атлаганда урам буйлап Илһам Шакиров җыры озатып кала:

Таң белән бергә / Ирекле илгә / Яңа җыр килә гөрләп, / Хәерле иртә теләп…

Көйдән көйгә, җырдан җырга күчеп, иртәнге концерт бара. Әлфия апа Афзалова, безнең якташ апа үзенең җыры белән әллә кайларга алып китә:

Сагындырды сызылып таңнар атуы, / Әнкәемнең иркәләп уятуы…

Җыр дулкынында газиз әнием, кадерле Мөхлисә апабыз турында уйлап, рәхәтлеккә коенып, дәрескә ашыгам.

…Еллар узгач шул таңнар, иртәләрнең сагындырып, үзәкләрне өзеп искә төшәсен, балачакның һәр мизгеле кадерле хатирәгә әйләнәсен без әле күз алдына да китерә алмыйбыз ул чакта…

Фотода: (сулдан уңга) сеңлем Рита, Гөлсинә, мин, кунак кызы Наилә һәм Мөхлисә апа. 1965 ел.

BARS MEDIA .GROUP

6+

татар 23 җыры

КАЗАН ЭКСПО

И.ШАКИРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

17 ДЕКАБРЬ 17.00

КАЗАН.2022

ТАТАРЖЫРЫ.РФ

ВСЕ БИЛЕТЫ KASSIR.RU

260-72-72

ООО «КАССИР.РУ ПОВОЛЖЬЕ». ОГРН 1141690018788

РЕКЛАМА

ТАУЛАР ИЛЕНӘ СӘФӘР

Юл йөрүдән, яңа җирләр, яңа урыннар белән танышудан, җырдагыча, мәңге туймамын! Сәяхәтләр чын-чынлап тормышны ямьле, башкаларның ничек яшәвен күреп, уйланырга, кайвакыт тормышка карашны тамырдан үзгәртергә мәҗбүр итә.



Гөлназ ХӨҖҖӘТОВА

Исән чакта йөреп кал,
Яхшыларны күреп кал.

Җәйге ялда быел Таулар иле – Дагстанга барырга карар кылдык. Соңгы ике елда россиялеләр өчен иң популяр тараф бу. Табигатенең чиксез гүзәллеге үзенә шулай ымсындыра, чакыра, кызыктыра... Үз машинабыз белән, ял итәргә туктый-туктый, ике тәүлектән артык бардык.

Каһарман-шәһәр Волгоград аша үткәндә Мамай курганына тукталдык. Батырлык үрнәге булган бу урыннарны күрү күптәнге хыялым иде. Мемориаль баскычының һәр басмасы, стеланың һәр сурәте, динамиклардан әкрен генә таралган моңлы аһәң, һәйкәл булып баскан һәр сын тарих сөйли монда... Диварларга сугышчыларның исем-фамилияләре языльп эленгән байрак-исемлекләр, уртада дөрләүче мәңгелек ут, каравылда торучы яшь солдатлар – һәммәсе дә күңелдә хисләр өермәсен куптара: өзелгән күпме гомерләрне югалту ачысы һәм батырлык алдында баш ию... Монда дөнья мәшәкате, проблемалар артка чигә, төссезләнә...

Волгоградны чыгып, юлны дәвам иттек. Алда – Калмык далалары. Табигать күзгә күренеп үзгәрә: агачлар, сирәгәеп, кыска һәм кәкре-бөкре куакларга әйләнә, уңга карасаң да, сулга карасаң да, алга һәм артка күз ташласаң да – иркенлек, киңлек. Авыл-шәһәрләр бик аз, киң буш кырда сарык йә сыер көтүе генә утлап йөри. Һавасы да башка монда – иркенлек исенә көтү исе, сарык исе кушылган. Төнне Комсомольск дигән бистәдә кунакханәдә үткәрдек. Аны эзләп табу – үзе бер маҗара. Күз алдына китерегез: кичке сәгать сигез (кояш монда иртә бата), кап-караңгы, урамдагы бер генә баганада да ут юк. Авылда, гомумән, аз-маз ут яктысы тәрәзәләрдән күренә дә, ике кибет ачык иде – шунда бер-ике кеше шәйләнә. Тып-тын. Башка беркем юк, хәтта этләр дә өрми. Еракта аллы-гөлле утлар күреп, шунда ашыккан идек – юкка сөенгәнбез, бәлки, кунакханәдер дип килгән җиребез урыс капкасы шикелле итеп эшләнгән зур капка булып чыкты. Аның артында – ачык мәйданчык, аннан кабат йортлар китә. Утлар дигәнебез – шушы капка башына эленгән гирлянда лампочкалары икән... Навигатор буенча кунакханәне таптык. Арзан гына бәягә бер йорт бирделәр – аш, йокы бүлмәсе, душ, туалеты бар. Бер генә кимчелеге – сулары тозлы һәм тәмсез, исле. Шуңа күрә дә икенче көнне төш вакытында Дагстанның Манаскент бистәсенә – үзебез яшәячәк кунак йортына килеп җитүгә, иң беренче соравыбыз су турында булды. «Безнең краннардан чишмә суы ага», – диде безне каршы алган Заира ханым. Чынлап та, таулар илендә һәр җирдә йомшак, тәмле, күңелгә тынычлык, тәнгә сихәт бирә торган чишмә суы икән.

Калмыкиядә очраган авылларның йортлары акшарлап куелган таштан гына, мүкләнеп-яшелләнеп беткән шифер түбәләр, агач капка-коймалар. Дагстанга килеп керүгә исә шундук чирәп түбәле, нигездә, икешәр катлы йортлар, биек таш койма һәм бизәкләп-матурлап эшләнгән биек капкалар күзгә ташлана. Куаклар да яшел биек агачлар белән алмашынды. Адым саен басу йә бакчаларны сугаручы каналлар очрый. Еракта – томаннар артында таулар шәйләнә. Исәнме, Дагстан! Менә син нинди икән!

«Кешене өч нәрсә бәхетле итә: мәхәббәт, кызыклы эш һәм сәяхәт итү мөмкинлеге», – дигән Иван Бунин.

Манаскент

Без килеп урнашкан Манаскент – киләчәктә зур һәм бай туристик шәһәр булуга йөз тоткан авыл. Ул башкала Махачкаладан 32 чакрым гына ераклыкта, Каспий диңгезе буйлап сузылган. Бар җирдә төзелеш кайный – кунакханәләр, диңгез буена ук сыенып утырган күп фатирлы зур йортлар төзиләр. Вак-төяк берничә кибетләре бар, әмма шуның белән шул. Былтырлы-быеллы моңарчы күрелмәгән туристлар агымы биредә, димәк, үсәсе көннәре алда әле авылның.

Ачның күзе – икмәктә,
тукның күзе – хикмәттә

Урнашу белән, әлбәттә, беренче эш итеп ашау ягын кайгырта башладык. Кунакханәнең үз кафесы бар. Меню карыйбыз. Чәйне чәйнеге белән алсаң – 200 сум, бер өлеш салат шулай ук 200 сум... Һм-м-м...

– Ә нинди салат?

– Кыяр, помидор, борыч һәм яшел тәмләткечләр.

– Тагын нинди бар?

– Бүгенгә шушы гына...

Бакча тутырып, таралып яткан кыярларыбыз, кызарып пешеп калган помидорларыбыз күз алдына килде. Алай, монда шулардан әзерләнгән бер өлеш салат бик түгәрәк бәя йөри икән... Нишлисең, алып карыйк... Ике кисәк ипигә заказ биргән идек. Иң элек шуларны китерделәр: ипи савытында ике зур юка көлчә (алар аны ләвәш дип йөртәләр, әмма безнең кибетләрдә сатылучы юка камыр белән бу ләвәшнең бер уртаклыгы да юк, әбиләребез мичтә пешерә торган көлчә бу). Аннан зур тәлинкәгә өеп салынган салат килде – һич арттырусыз, дүртәүләп көчкә ашап бетердек без аны. Шулай ук бик зур тәлинкәгә салынган пылау, беребезгә – голубцы (өч зур борыч эченә тутырганнар, өстәп, тәлинкә читенә туралган помидор һәм пешкән бәрәңге куелган), итле аш килде. Никадәр ачыккан булсак та, ризыкларны ашап бетерә алмадык. Мул салалар икән монда һәм барысы да телеңне йотарлык тәмле!
Иң мөһиме: тәмләткечләре дә тау халыкларына хас итеп күз алдына китергәнчә артык түгел, таман гына! Бар ризыклары да итле, хәтта чәй янына бирелә торган чуду да! Безнеңчә кыстыбый инде – фарш кыстырып ясала. Дөрес, эремчекле, кабаклысын да тәкъдим итә-



■ Сап-сары вак комы, киртләч барханнары, шулар өстендә житез исүче кайнар жиле белән... Сарыком барханнары бу.



■ Салтин тарлавыгы диварлары үзе бер әкияти дөнья.

ләр. Алга таба инде без чамасын белеп кенә заказ бирә башладык – бер тәлинкә ризык ике кешегә артыгы белән җитә!

Шаулый диңгез

Каспий безне ак башлы дулкыннары белән каршы алды. Әкрен җилдә дә гел дулкынланып тора. Гомумән, диңгезгә керү дулкыннар белән шаяруга кайтып кала. Ярдан инде 2–3 метр эчкә керден – су әле гел билдән генә, аның каравы, бөдрәләнеп килгән дулкыннар һаман кире чыгу юлына этәләр. Диңгез төбе чиста рәхәт ком, шуңа су үтә күренмәле түгел, болганчык яшькелт төстә. Җылы-ы-ы! Интернетта Каспий суы августта яңа сауган сөт шикелле җылы була дип укыгач, көне дә эссе, суы да шул дәрәҗәдә җылы булгач, кайда, ничек суынырбыз икән дип уйлаган идем... Юк, алай түгел икән! Ул чынлап та җылы, әмма җиләс җылы. Кич барсаң да, иртә таңнан килсәң дә, суы рәхәт салкынча гына булып тора. Суда сәгатьләр буе ятсаң да туңмыйсың!


Халык кунакчыл һәм гади

Дагстанда бик күп милләт яши, шуңа күрә уртак аралашу теле булып рус теле хезмәт итә. Үзебез яшәгән отельдә эшләүчеләрнең дә үзара русча сөйләшүләренә шаһит булдык. Халык биредә бик ачык күңелле, ярдәмчел. Юл сорап туктаганда гына да эчәргә-юынырга су тәкъдим итәләр, тәфсилләп аңлаталар, хәерле сәфәр теләп, озатып калалар. Адым саен мәчет. Күпчелек хатын-кыз тездән түбән итәктән, озын җиңле кофтадан, яулыктан йөри. Су коенырга да шул ук киемнән керәләр. Ирләр дә диңгезгә футболка, озын шорты белән керә, әмма безгә – ачык киемнәрдән йөрүче туристларга карата кырын караш сизмәдек. Шулай да, җирле халыкның традицияләрен хөрмәт итеп, экскурсияләргә чыкканда тыйнак киенү кирәк.

Экскурсияләр

Дагстан табигате искиткеч матур. Таулар бер-берсен кабатламый – алар сине бар яклап уратып алган, һәркайсы үзенчәлекле. Түбәсенә болытлар утырып ял итә торганнары да, тоташ нарат урманы белән капланганы да, пычак белән кисеп төшергәндәй, шоп-шома, тип-тигез битле кыя-ташлары да, мультфильмнарда күрсәтә торган – берсе артыннан берсе үсеп чыккан сөзәк-түгәрәк башлылары да – нинди генә юк!.. Һәм әнә шул төрлелекләре белән истә дә калалар. Беренче мәртәбә тауларга сәяхәткә кузгалгач, сихри гүзәллеккә юл буе исем китеп бардым, кайтканда исә миңа монда шундый таулар иде, бу урында туктап ял иттек, ә менә моннан безгә юл бик кыска калды, дип искә төшереп бардым. Ә мин юлны хәтердә калдыра белми торган, ориентир дигәнне бөтенләй санламый торган кеше!

Шушы матурлыкны оста итеп сатарга өйрәнә җирле халык: тау серпантиннарында гүзәллеге белән әсир итә торган урыннарга таган ясап куйганнар: таулар өстендә атынып сурәткә төшәсең килә икән, акчаңны түлә дә рәхим ит! Сулак каньонын сәйран кылу нокталарында чират тезелгән. Ул – Европадагы иң тирән каньон санала, тирәнлеге 1920 метрга кадәр җитә. Миңа калса, Сулакның үзенә җәлеп итә торган төп үзенчәлеге





Тоботны бар куәте-дәрте белән күрер өчен май-июнь айларында килү кирәк, әмма августта да гайрәте соклангыч!



Сулак каньоны. Ел саен бирегә дөньяның төрле почмакларыннан меңләгән турист, фотограф, рәссам, гомумән, матурлыкка гашыйк җаннар агыла.

бөтенләй башка – ул җете фирүзә төстә! Бу якларга килгәнче интернет киңлекләрендә сурәтләрен караганда мин аны азмы-күпме фотошоп белән матурлаганнар дип уйлаган идем. Юк икән! Сулак каньоны чын-чынлап бөтерелә-бөтерелә сузылган зәңгәр ука тасманы хәтерләтә. Таулар биеклегеннән ялтырап, үзенә тартып-ымсындырып тора...

Минем күңелдә иң якты, иң җете тәэсир калдырганы – Салтин тарлавыгы һәм шарлавыгы булды. Гуниб районы тауларына урнашкан ул. Табигать шулкадәр зур көчкә ия ки, тау елгасы тоташ кыядан аска томырылып, сәнгать үрнәге булырдай шарлавык ясаган. Әйтеп бетергесез сихри матурлык! Көньякның кайнар һавасыннан монда килеп кергәч, җиләс, рәхәт... Аяк астында су чупырдый. Тау елгасының салкынлыгы 100 сумга арендага бирелгән бутыйлар аша да сизелеп тора. Әкрен генә эндәшсәң дә, тавыш диварларга килеп бәрелеп, катлы-катлы кайтаваз булып биеккә тарала... Әмма табигать белән күзгә-күз калып, аулакта хозурлану мөмкин түгел – туристлар агымы туктаусыз алышынып тора. Фотога төшәләр, шарлавыкның уйнак тамчылары белән шаяралар, кыю егетләр хәтта чума-чума су керә!

Тагын бер табигать могҗизасы – таулар арасында җәйрәп яткан чүл... Атаклы «Белое солнце пустыни» фильмын шунда төшергәннәр. Чүл Дагстан тыюлыгына кергән, бархannар арасында чаян, елан кебек хәшәрәтләр дә яши, диделәр. Шөкер, аларны күрергә туры килмәде. Хәер, иге-чиге булмаган туристлар агымы янына килүдән үзләре дә куркадыр, дюнаның тыныч почмагында гомер кичерәләрдер, мөгаен.

Таулар илендә туристлар күңеленә хуш килерлек кызыклы һәм матур урыннар бик күп, әмма аларга барып җитү бик җиңел түгел. Шуларның берсе – Тобот шарлавыгы – диңгез өстеннән 2500 метр биеклектә, Хунзах платосында урнашкан. Тобот елгасы тау битенә кадәр ыргылып килә дә 70 метр биеклектән аска ташлана. Экскурсияләргә без үз машинабызда, навигатор белән бардык. Татарстан киңлекләреннән рәхәт җилдерергә күнеккән тимер атыбыз өчен бик җиңел булмады – тырышып, югарыга таба барасың-барасың да, 180 градуска борылып, тагын өскә ашыгасың. Өстәвенә, урыны белән юл убылган да берьяклы гына калган. Андый урыннарга әллә каян кычкырып, күренеп торган билгеләр куелган. Җитмәсә, җирле халык бик кызу йөри, тау юлында юл кагыйдәләрен санлауны артык кирәк тапмый – менә бу адреналин! Шулай да тоташ тау-таш иле Дагстанда юлларның төзеклегенә сокланмый мөмкин түгел – бар җирдә дә тип-тигез, шоп-шома асфальт!

Дагстанга туристлар затлы сервис һәм бар дөньяңны онытып ял итү өчен түгел, гүзәл табигате белән хозурланыр, тынгысыз мәшәкатьләрдән арынып торыр, мәгърур таулар гайрәтен үзенә сеңдерер, көч җыяр өчен килә. Дөньяның иң борынгы шәһәрләренең берсе булган Дербент, тарихи кирмәннәр, таулар арасында – цивилизациядән читтә үз тормышлары белән яшәүче авыллар, серле мәгарәләр, лианаларга уралган Самур урманы... Карар, күрер, сәйран кылыр урыннар бихисап биредә. Һәр кеше күңеленә хуш килерлек ял табачак. Таулар иле күңел түрендә үз урынын алды. Монда кабат әйләнеп килүләр насыйп булсын!


Фото: Анна Арахамия



Клиника сайты: oncoprofi@mail.ru
Клиника адресы: Казан, Себер тракты, 23
ВК адресы https://vk.com/oncoprofi_clinic_kazan

VKда язылган өчен барлык төр медицина анализларына – **15% ташлама***

Язылу өчен телефон: 8 (843) 215-00-03
8.00–20.00 сәгатькә кадәр.

*акция 1 декабрьгә кадәр дәвам итә

Реклама

ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ – МИҢНӘР

«Миңле кеше – бәхетле кеше», диләр безнең халыкта. Имеш, миңнәре никадәр күбрәк булса, шулкадәр бәхетлерәк була кеше. «Сипкелле кеше – сөйкемле кеше» дигәнен дә искә төшерик. Ләкин шул бәхет белән сөйкемлелек арасында кеше сәламәтлегенә зур зыян сала торган миңнәр, тиредәге таплар кебек, яман булмаган шешләргә бүген табиблар аеруча игътибар итәргә чакыра. Моның ни өчен шулай булуын «Онкопрофи» онкологик чирләрне кисәтү медицина клиникасы табиб-онкологы, хирург Ренат ХАҖИӘХМӘТОВ белән ачыклыйбыз.

Алсу ШАКИРОВА

Ренат Илдарович, онкологик авырулар арасында тәндәге яман шеш еш очрыймы?

– 2021 ел нәтиҗәләре буенча Татарстанда тиредәге яман шеш авырулары беренче урынга чыкты. Рейтингта «Топ-1» булу бу очракта бер дә сөенерлек нәтиҗә түгел. Шунысы гаҗәп тә: тиредәге үзгәрешләрне кеше үзе дә күрә ала, шикләнеп, табибка мөрәҗәгать итә ала югыйсә. Эчке органнардагы яман шешне табуы күпкә катлаулырак, күптөрле тикшеренүләр таләп итә. Ә монда үзгәрешләр күз алдында диярлек. Шулай да безнең дошман бик хәйләкәр – гади миңнәр, тән тиресендәге таплар кебек күренергә мөмкин ул.

Куркыныч тудыра торган миңнәргә кайсылары керә?

– Тиредәге күптөрле миңнәрне невуслар дип атыйбыз. Алар яссы, тире белән тигез, тиредән бераз күпереп торучы, чәчәк кәбестә кебек, тән төсеннән аерылып торырга, берьюлы берничә төсле, күк зәңгәр, кара булырга мөмкин. Меланомалар пигментсыз да була. Андыйларын сәламәт тирдән аеруы да бик авыр. Бу хәтта табибка да кыенлык тудырырга мөм-

кин. Тәҗрибәле табиб-онколог кына төрле зурайткыч пыялалар, дерматоскоп ярдәмендә аларны танып ала.

Димәк, кешенең үзеннән дә бик күп әйбер тора. Үз тәнеңдә нәрсәгә игътибар итәргә кирәк? Кайсы очракта кичекмәстән табибка күренергә?

– Халыкара сәламәтлек саклау оешмасы (ВОЗ) тәнендә пигмент таплар, яңа невуслар чыккан йә элеккегеләре үзгәргән очракта һәр кешегә елга бер тапкыр онколог-дерматологка күренеп торырга киңәш итә. Әйе, сүз яңа невуслар турында гына бармый. Моңа кадәр бер дә борчымаган миңегез үзен сиздерә башласа, аның зурлыгы, төсе, структурасы үзгәрсә, бу инде табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк дигән сүз. Еш кына җәй айларында кояш астында озак вакыт уздырганнан соң яисә ял итеп кайтканнан соң тәндәге яңа невусларга игътибар итә пациентлар. Шулай ук элек бер дә борчымаган миң киемгә эләгә башласа, еш җәрәхәтләнсә дә табибка күренергә кирәк. Бюстгальтер эчендә калып, уңайсызлык тудыра торган миңнәренә дә игътибарлы булырга тиеш хатын-кызлар. Мәсәлән, эчке кием эчендә калган миңнәр кырылып, кайвакыт ялкынсынып тора башлый, сыекча да бүленеп чыгарга мөмкин. Бу шулай ук табибка күренер өчен бер сигнал. Мондый очракта операция кирәк, чөнки даими зарарланып, әрнеп тору нәтиҗәсендә яман булмаган шеш яман шеш стадиясенә күчә.

Миңнәрнең барысын да күреп булмый бит. Аларны ничек карап бетерергә?

– Әйе, кайвакыт пациент бер миңенә зарланып килә, җентекләп карау нәтиҗәсендә бөтенләй башка миңдә яман шеш табабыз. Гәүдәнең арткы ягына, күз күреме җитмәгән урыннарда да качып калырга мөмкин алар. Шуңа күрә квалификацияле табиб-онколог кына сезне карап, барлык миңнәрегезне тикшереп чыга ала. Олыгайган саен, тиредәге яман шешнең кайбер формалары барлыкка килү куркынычы арта. Шуңа күрә олы яштәге әти-әниләрегезгә дә игътибарлы булырга кирәк. Физик мөмкинлекләре чикле булу сәбәпле, алар үз тәннәрен тулысынча күреп бетерә алмый, моңа тиренең табигый сырлары да комачаулый. Аларны да кайгыртырга онытмагыз. Безнең клиникада булган пациентлар бу яктан белемле инде – алар үзләрен генә түгел, әти-әниләрен, туганнарын да карап, шикле урыннарына игътибар итә ала. Ләкин бары тик табиб-онколог тәнне тулысынча яхшылап караганнан соң гына төгәл диагноз куя ала.

Тән тиресендә үзгәрешләр күргән кеше, беренче чиратта, дерматологка мөрәҗәгать итә. Онколог-дерматологка соңрак, юллама белән генә мөрәҗәгать итәргә күнегелгән...

– Онколог-дерматолог – тиредәге яман булмаган һәм яман шешләр белән көн саен даими рәвештә эшләүче белгеч. Ул онкологияне таный, тәндәге куркыныч янаган бер генә шешне дә күрми калмый. Онколог-дерматологка мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек булмаган очракта дерматологка гына да барырга була, әлбәттә. Шикле очракларда ул инде белгечкә җибәрәчәк. Ләкин вакытны сузмыйча, туры дерматолог-онкологка бару күпкә нәтиҗәлерәк.

Кайберәүләр тәндәге миңнәрне алдырыр өчен косметологка да мөрәҗәгать итә бит. Бу үз сәламәтлегеңә бөтенләй битарафлык билгесе түгелме?

– Кызганыч, бездә хокук-норматив яктан җаваплылык даирәсе чит илдәге кебек төгәл бүленмәгән. Пациентлар, бигрәк тә яшьләр, тәндәге пигментларны бетерү, сөялләрне алдыру өчен косметологка бара. Гистологик тикшеренү, операция өчен махсус материаллар турында сүз дә бармый мондый очракта. Берникадәр вакыттан соң, операция ясаткан урында рецидив барлыкка килеп, ул пациентлар безгә мөрәҗәгать итә. Җөй өстеннән пигмент тап үсә башлагач, куркуга калалар. Еш кына ул пигмент тагын да тизрәк үсә әле. Без яңадан операция ясыйбыз, гистологиягә җибәрәбез. Алдан ук ахыры ничек буласын уйлап, квалификацияле белгеч белән киңәшләшү зарур.

Ренат Илдарович, сезнең клиникада квалификацияле тикшерү ничек уздырыла?

– Барысы да табибка килүдән башлана. Беренче чиратта табиб-онколог пациентның бөтен тәнен җентекләп карап чыга. Бездә бу – алтын стандарт. Пациент зарланган миңне генә тикшермибез без. Мәсәлән, уң кулындагы тапны күрсәтергә килсә дә, бөтенләй башка урынында куркыныч янаган берәр невус табылырга мөмкин. Игътибар итәрлек невуслар булса, табиб дәва билгели. Ул динамикада күзәтү генә дә булырга мөмкин. Якын арада планлы операция билгеләгән очраклар да бар. Бер йә берничә шешне берьюлы алырга да туры килергә мөмкин.

«Онкопрофи» медицина клиникасында операция нинди шартларда уза?

– Анализ биргәннән соң, пациентны билгеләнгән көнгә операциягә чакыралар. Операцияләрне клиникада атнасына алты көн ясыйбыз. Беренче кабул итүдән башлап, җөйдәге җепләрне алуга кадәрге тулы цикл буенча дәвалау каралган бездә. Операция биш минут эчендә өлешчә (местный) наркоз астында уза, пациент берни авырту да сизми. Ярага косметик җөй салына. Операциядән соң җөй калмасын өчен дә кирәкле дәваны киңәш итәбез. Пациент шул ук көнне өенә кайтып китә, эшенә йөри. 10–14 көннән соң табиб яңадан карап, гистология нәтиҗәләре белән таныштырып, озатабыз.

Операция ясаганда нинди ысуллар кулланасыз?

– Лазерлы, радиодулкынлы җайланмалар бар, сыек азот ярдәмендә криодиструкция методы да кулланабыз, скальпель ярдәмендә классик ысул белән дә ясыйбыз. Кайсы ысулны куллану отышлырак буласын табиб билгели.

Профилактик чараларга килсәк, аянычлы нәтиҗәдән сакланыр өчен нишләргә киңәш итәсез?

– Татарстанда онкология белән ел саен күбрәк кеше авырый. 2021 елгы нәтиҗәләр буенча яман шеш диагнозы белән һәр 38 нче кеше очраша. Профилактик чаралар күрмәсәк, мең кешенең һәр ун-унбише берничә елдан онколог-дерматологка киләчәк. Ул вакытта инде яман шеш дигән диагноз белән... Тиредә яман шешне кисәтү өчен бик гади әйберләр таләп ителә: иренмичә табибка барырга гына кирәк.
Үз сәламәтлегегезгә аңлы рәвештә игътибарлы булыгыз!

КИЧКЕ АЛТЫДАН СОҢ...

Һәр кеше үз тормышында бер тапкыр булса да, төнгә каршы ашарга ярамый дигәнне ишетми калмагандыр. «Кичке алтыдан соң ашыйсың икән, тазарасың» дигән уй безнең аңда нык утыра. Тынычланыгыз! Ашарга була, әмма чамасын белеп. Интегративлы медицина табибы, диетолог, нутрициолог, health-коуч Айгөл ФАЗЛЫЕВАга кичен дөрес туклану буенча сорауларыбызны бирдек.

Кичке алтыдан соң ашарга киңәш ителми дигән фикер бар. Әгәр төнге унберләргә кадәр йокламыйсың икән, бу очракта нишләргә?

– Әйе, кичке алтыдан соң ашарга киңәш ителми. Тик бу кагыйдә кичке тугызда, унда йокларга ятучылар өчен генә. Йокларга өч-дүрт сәгать кала кичке ашны тәмамлау – иң идеаль вариант. Әмма шуны да истән чыгармагыз: туклануның иң соңгы вакыты – кичке сигездә.

Кичке аш нинди булырга тиеш?

– Кичке ашта сыер ите булмавы яхшы, чөнки ул эшкәртелү өчен озак вакыт таләп итә. Бу исә йокы сыйфатын начарлата. Шуңа күрә дә туклану җиңелчә, балансланган булса яхшы. Өстәлдә җиңел үзләштерелә торган аксымнар: балык, диңгез продуктлары, кош ите, йомырка, кузаклылар; клетчатка: яшелчәләр (термик эшкәртелү узганнары да ярый); углеводлар: ботка һәм көрпәле оннан пешкән ипи булу шарт. Гомумән, сыер итен атнага бер-ике тапкыр – төшке аш вакытында гына ашарга киңәш итәм.

Кичен, эштән кайткач, гадәттә, гел капкалап йөрисең.

– Күпләрнең кичке ашлары шактый күләмдә углеводлардан тора. Мондый рацион белән ашап туйганнан соң да капкалап аласы килә башлый, бу исә артык авырлык җыюга китерә, шикәр диабеты авыруы башлану ихтималын тудыра. Әгәр дә кичке ашыгыз төрлеләндерелгән һәм балanслы икән, капкалап алу теләге булмас.



Йоклар алдыннан кара чәй эчү зыянлы түгелме? Нинди чәйгә өстенлек бирергә?

– Бүген күпләр хроник стресстан интегә, шуңа күрә йоклап китә алмый җәфалана. Кичен кара чәй эчү гадәте дә бу хәлне авырайта, чөнки анда кофеин бар. Кофеин нерв системасын ярсыта, баш мие эшчәнлеген активлаштыра, йөрәк тибешен ешайта. Йокларга кимендә өч сәгать кала эчелгән бер стакан кара чәй йокысызлык сәбәбе булырга мөмкин. Шуңа күрә төштән соң үләнле һәм тынычландыра торган чәйләргә өстенлек бирегез. Бигрәк тә бөтнек, ромашка, лимон бөтнеге, лемонграсс, кара карлыган яфрагыннан пешерелгән чәйләр файдалы булыр.

Йоклар алдыннан су эчәргә ярыймы?

– Йоклар алдыннан су эчәргә ярый, әмма күп күләмдә түгел. Көнлек су режимының төп өлеше кичке сәгать җидегә кадәр эчелергә тиеш. Кичен сыеклык күбрәк эчелә икән, ванна, душ кирәгез. Шул рәвешле бөерләргә килгән артык йөктән котылырсыз.



КЫТАЙ КЫЗЛАРЫНЫҢ МАТУРЛЫК СЕРЕ

Гуаша — битне массажлауның борынгы техникасы. Элек-электән үк Көнчыгышта популяр булган, чөнки файдасы күп: матдәләр алмашы активлаша, җыерчыклар тигезләнә, лифтинг нәтиҗә бирә, йөз тонусы яхшыра, кан һәм лимфа әйләнеше тизләнеп, биттәге кайбер «йоклаган» урыннар «уяна». Гуаша массажын таштан йә сөяктән эшләнгән махсус әсбаплар кулланып ясыйлар. Башка массажлардан төп аермасы да шул. Гуаша массажы серләренә Кытайда туып-үскән, кытай медицинасы белгече Гөлчәһрә ИМАМУ өйрәтә.



















■ Гуаша массажын косметик май белән ясыйбыз. Тәнегезгә туры килгән майны сайлагыз. Кокос һәм миндаль мае аеруча файдалы булыр. Крем белән массаж ясарга ярамый, гуаша әсбабы тирене тарттырачак.

■ Массаж ясый башлаганчы, махсус гуаша таягы белән аскы казналык сөяге башланган урын тирәсендәге өч япьле нерв ноктaларын «ачабыз». (Бу вакытта авырту сизәсез икән, димәк, нерв системагызда проблема бар дигән сүз. Аны массаж белән бетереп була.) Колак артларыннан да йөртеп, лимфа йөрешен ачып җибәрәбез.

■ Гуаша өчен ясаган махсус әсбап – «кыргыч» белән муендагы лимфаларны да ачабыз. Моның өчен колактан аска таба сыпырабыз. Бу кан әйбәт йөрсен өчен кирәк. Әзерлегебез шуның белән тәмам. Хәзер биткә гуаша массажы ясый башлыйбыз. Массаж ясаганда төп шарт: һәр хәрәкәтне ун тапкыр кабатлыйбыз, шуннан соң өч тапкыр муендагы лимфаларны ачабыз.

■ Бер кул бармаклары белән иякнең очын тотып торып, «кыргыч»ны колакка таба ун тапкыр йөртәбез. Шундый ук хәрәкәтләрне борын яфрагы тирәсеннән колакка таба ясыйбыз. Күз төбе тирәсеннән – чигәдән өскәрәк урнашкан кояш энергиясе ноктасына кадәр дә гуаша әсбабы белән йөртәбез. Лимфаларны ачарга онытмыйбыз.

■ Борын өстеннән дә йөртәбез. Һәм борын яфрагы тирәсендәге ноктaларны массажлыйбыз. Бу ноктaлар хатын-кызларның кече оча сөягендә урнашкан органнары өчен «җаваплы».

■ «Кыргыч» белән маңгайның уртасыннан чигәгә таба, кашлардан чәчләр үсә башлаган урынга таба йөртәбез һәм лимфаны ачабыз. Битнең бер ягына ясаганнан соң, икенче ягында да нәкъ шул хәрәкәтләрне кабатлыйбыз.

■ Ике як биткә дә гуаша массажы ясап бетергәч, дулкынлы гуаша әсбабы белән егермешәр тапкыр битне өскә күтәртәбез. Ул булмаса, бармакларны йодрыкка төйнәп, бармак буыннары белән ясасагыз да була.

■ Бармаклар белән дә битне өскә таба, аннан соң йөз кырыйларыннан муенга таба сыпырып төшерәбез. Моны өч тапкыр ясыйбыз.

■ Күзләр тирәсен бармак очлары белән йомшак кына массажлыйбыз. Күз төбендәге нокта турында онытмагыз. Ул ноктага көн саен йөз тапкыр әкрен генә баскаласагыз, күзләрнең күрүе бермә-бер яхшырыр. Гуаша массажын көн саен ясарга гадәтләнегез. Кичен ясасагыз, йокыгыз яхшырыр, иртән битегез алсуланып китәр, йөздәге шешенүләр бетәр. Тагын да матурланырсыз!

QR-код аша кереп, күнегүләрне видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



Балан бәлеше

Урамда – ноябрь, баланнарга инде күптән бал керде. «Аш-су» сәхифәсенең бүгенге кунагы Айгөл МӨБАРӘКШИНА укучыларыбызга балан бәлешен пешерү серләрен ачмакчы. Күпләр өчен балан бәлеше ул – әни бәлеше. Айгөл дә әнисе Рәвия апа өйрәтеп калдырганча – тышын кетердәвек итеп, әчлеген мул салып пешерә аны. «Әнием Актаныш районы Татар Ямалысы авылыннан иде. Бик матур яклар ул. Агыйдел буенда күлләр күп, күл уртасында – утраулар. Әни балачактан ук көймә белән шул утрауларга кереп, әрәмәдән шомырт, бөрлегән, баланнар җыйган.
Без үскәндә дә әти белән икесе көз көне күп итеп балан җыеп кайталар иде. Ул баланнарны зур-зур бәйләм итеп бәйләп, түбә кыегына элэләр. Балан бүкәнләү, диләр аны. Көннәр суыткач, балан бүкәнен өйгә алып кереп бөрчиләр», – дип, балачагының иң матур хатирәләрен уртаклаша Айгөл. Бу уңган ханым – Туполев җәмгыяте филиалы – Казан авиация заводының җәмәгатьчелек белән эшләү бүлеге белгече. Татарстанда җитештерелүче самолетлар, завод эшчәнлеге, хезмәттәшләре турында шулкадәр мавыктыргыч итеп сөйли ул. «Бик кызыклы һәм иҗади минем эшем», – ди Айгөл. Эше генә түгел, гаиләсе дә иҗади аның. Әтисе – Роберт Сәлахиев Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Аның шигырьләренә язылган җырларны Филүс Каһиров, Вил Усманов, Гөлнара Габидуллиналар репертуарыннан ишетергә мөмкин. Рәвия апа исән булса, алар быел алтын туйларын бәйрәм иткән булырлар иде... Әнисенең рухын яд итеп, бер елны да балан җыймый калганы юк Айгөлнең. Якыннарын балан бәлешле табынга җыеп, нәкъ әнисе кебек кунак сыйларга ярата ул. Баланнар балланган чакта бергәләп шул бәлешне пешереп карыйбызмы?!



Кирәк

Камыр өчен: 100 г атланмай / 2-3 аш кашыгы кибет каймагы / 1-2 аш кашыгы үсемлек мае / 1 йомырка / ярты чәй кашыгы тоз / 1 аш кашыгы шикәр комы / 100 мл кайнаган су / он.
Әчлек өчен: 1 килограмм бөрчелгән балан / 300 г шикәр комы / 3 аш кашыгы он (арыш оны яхшырак).

Эш барышы

- Яхшылап юылган баланны ике кат целлофан капчыкка салып, чуен савытта пешерергә куябыз. Чуен төбенә бер бармак киңлеге су салына. Капчык авызын бәйләргә кирәк. Балан әнә шулай парланып бер сәгать чамасы пешә.
- Пешкән баланны савытка бушатып, шикәр комы һәм он салып болгатабыз.
- Тирән савытка йомшарган атланмайны, каймак белән үсемлек маен салабыз, тоз белән шикәр өстибез. Шуңа бер йомырка сытып, камыр басабыз. Суны азазлап кына камырга куша барабыз. Онны үзегез чамалагыз: камыр – уклау белән җәярлек, әмма каты булмасын.
- Кул белән басарлык булгач, камырны куна тактасына төшереп, үзләнгәнче әвәлибез, аннары ике өлешкә бүләбез. Берсе – бәлешнең төбенә, икенчесе – капкачына.
- Бәлеш төбенә дигәнен таба читеннән чыгып калырлык итеп җәябез һәм төбе майлы табага салып, тигезлибез. Камыр өстенә әчлекне бушатып, бәлешне капкачы белән каплыйбыз.
- Бәлеш читен матурлап бөрәбез. Уртасын чәнечке белән тишкәлибез һәм 180–200 градус кызулыктагы мичтә 40 минут пешерәбез. Йөзе аллангач, бәлеш әзер.

Балан бәлеше салкын килеш тәмлерәк. Мәтрүшкәләр салып чәй пешерик тә, барысын да тизрәк табынга чакырыйк. Чәйләрегез тәмле булсын!


















Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.





Өйнең яме — гөлләрдә


Каланхоэ

Каланхоэны күпләр дәвалау үзлегенә ия гөл дип кенә уйлый. Ләкин аның купшы чәчәк ата торган төрләре дә бар. Мәсәлән, кибетләрдә каланхоэның каландива төренә караганын – кызыл, ал, сары чәчәклеләрен еш күрергә була. Әлеге төр селекция юлы белән чыгарылган, табигатьтә очрамый. Кибеттән сатып алу белән беренче бурыч – гөлне яңа туфракка күчереп утырту. Туфракның әчелеге нейтраль, ә савыт элеккегесеннән бераз гына зуррак булырга тиеш. Алдагы елларда исә гөлне ел да күчерү таләп ителми, чөнки аның тамыр системасы акрын үсә. Кояш нурлары туры карамаган якты урынны ярата, көнчыгышка яки көнбатышка караган тәрәзә төпләрендә яхшы үсә. Фитолампа куллансагыз, аны төнгә сүндерергә кирәк, каланхоэ – кыска көн үсемлеге. Һаваның дымлылыгына һәм температурага таләпчән түгел, корыда да яхшы үсә. 15 градустан 30 градуска чаклы булган температура аның өчен бик кулай. Бу гөл – суккулент, ягъни яфраклары су запасын туплаучан. Шунлыктан аңа суны чамалап, туфрагы кипкәннән-кипкәнгә генә сибәләр. Каланхоэның чәчәк бөреләре көздән формалаша башлап, кышка чәчәк ата. Ашламалар белән тукландыруны да көзге якта башкаралар. Кибетләрдә суккулентлар өчен сатылган ашламалар каланхоэ өчен дә ярашлы. Иң мөһиме: анда азот микъдары күп булмасын. Декоративлыгын югалтмасын өчен, гөлне кисеп, формалаштырып торырга кирәк. Моны чәчәк атып бетергәч башкаралар. Карт гөлләрне яшәртү өчен өске өлешен бөтенләй кыркып алырга була.



Башка гөлләр үстерү турында да укыгыз.

Фикусларның төрләре бик күп. Үрмәлесе, агач кебек үскәне, куаксыманнары да бар. Бенджамин фикусын, каучуклысын, эре яфраклы төрләрен иң популярлары дип әйтергә була. Инжир агачының да фикус булуын күпләр беләме икән?

Нинди төргә караса да, фикуслар һаваның югары дымлылыгын, җитәрлек күләмдә яктылык, иркен урын һәм җылылык ярата. Урын алыштырганны һәм үтәли җилләрне өнәмиләр. Шулай ук салкынга да чыдамсызлар. Кышын өйдәге дымлылыкны арттыру өчен махсус һава дымландыргыч, гөлгә әледән-әле су бөркү яки янына савыт белән су кую кебек ысуллар кулланырга туры килә. Дымлылыкны яратса да, фикуска суны чамалап кына сибәргә кирәк. Сугарыр алдыннан гөлнең туфрагы 2-3 см тирәнлектә коры булырга тиеш. Бу аеруча бенджамин фикусына һәм каучуклысына кагыла. Ә менә үрмәләп үсә торганнарына һәм кәрлә төрләренә суны ешрак сибәләр.

Матурлыгын югалтмасын өчен, гөлне формалаштыру да мөһим. Моны яз көне башкаралар. Идәндәге чүлмәкләрдә үсүчеләренең озынлыгын 1 метр, ә өстәлдә яки тәрәзә төбендәгеләрен 40 см калдырып, ботак очларын кисәләр. Ләкин бер кискәндә 20 сантиметрдан да күбрәк кисмәскә кирәк. Яздан алып көзгә кадәр фикус ашлауга да мохтаҗ. Минераль һәм органик ашламаларны чиратлаштырып ашласаң яхшы. Фикусны ботак очын тамырландырып үрчетәләр. Яшь вакытында ул ел да күчереп утыртуга мохтаҗ, ә менә зур гөлне күчермиләр, бары туфрагын гына өлешчә алыштыралар. Фикусны «гаилә гөле» дип тә йөртәләр. Имеш, фикус үскән өйгә уңыш, гармония һәм муллык килә икән. Ышаныргамы, юкмы – анысы һәркемнең үз эше, ә менә бүлмәдәге һаваны чистартуы хак.


Фикус


Ясмин

Тропиклар үсемлеге булган ясминне бүлмә шартларында үстерүе җайлы гына түгел. Ул яктылык ярата, ләкин туры караган кояш нурларын өнәми. Көньяк тәрәзә төбенә куясыз икән, җәйге якта аны җиңелчә күләгәләргә туры киләчәк. Яктылык җитмәсә, бөтенләй дә чәчәк атмый ул. Җылы вакытта ясминне балконга яки бакчага да чыгарып куярга мөмкин. Әмма кояш нурларына акрынлап өйрәтү мөһим. Һава температурасына таләпчән түгел. Шулай да кыш көне җылылык 13 градустан артмаган салкынча урын кирәк. Җылы бүлмәдә кышлаган ясмин яхшы үссә дә, чәчәк бөреләре яралмый. Яздан көзгәчә иң кулай температура – 18–24 градус җылылык. Суны күпме сибәсе өйдәге температурага бәйле. Эссе вакытта гөлне һәр өч көн саен сугаралар. Гөлнең туфрагы дымлы, ләкин юеш булмаска тиеш. Кышын исә атнага бер сугару да җитә. Ара-тирә 1 литр суга 1 чәй кашыгы алма серкәсе яки берничә тамчы лимон согы кушып сибү файдалы. Ясмин өчен һаваның дымлылыгы югары булу кирәк. Язын һәм җәен әледән-әле су бөркеп, гөлне коендырып торырга туры киләчәк. Сыгылмалы ботакларына терәү куеп яки шкаф башына үрмәләтеп үстерәләр. Язын кыскартып кисеп, гөлне формалаштыру мөһим. Яшь вакытта гөлне – ел да, картларын ике-өч елга бер күчереп утырталар. Ясминне ботак очындагы яшь тармакларны тамырландырып үрчетәләр. Чәчәк аткан вакытта гөлне йокы бүлмәсендә тотарга ярамый, исеннән баш авыртырга мөмкин.

Фото: ru.freepik.com

тест: сез юмарт кешеме?

Юмартлык – иң матур сыйфатларның берсе. Материаль ярдәм генә түгел, башка берәүнең ихтыяҗы өчен көчеңне, вакытыңны сарыф итү дә юмартлыкның бер төре. Бу тестны узып, әлеге сыйфатның үзегездә никадәр булуын тикшереп карый аласыз.

1. Бер белмәгән мохтаҗ кешегә бөтенләйгә акча бирә алыр идегезме? Әйе, кеше чынлап та мохтаҗ икән, бирәм. *(1 балл.)* Юк, алар хәер эстәүне һөнәр итүчеләр. Теләнү бизнесын үстерергә телəгем юк. *(0 балл.)*

2. Якыннарыгыз сездән ярдәм сораса, күңелегездә ризасызлык барлыкка киләме? Килә, үз мәшәкатем үземә җиткән. *(0 балл.)* Юк, бик рәхәтләнеп булышам, якыннарга булышырга кирәк. *(1 балл.)*

3. Өстәмә ял көнегез килеп чыкса, сез аны үзегезгә багышламыйча, якыннарыгыз өчен сарыф итә алыр идегезме? Үземә багышлыйм, миңа да ял кирәк. *(0 балл.)* Якыннарыма багышлыйм, минем дә, аларның да күңелләре булачак *(1 балл.)*

4. Көтелмәгән керем алсагыз, нишләр идегез? Үземә күптән кызыккан әйберемне алам. *(0 балл.)* Якыннарыма бүләкләр алып, аларны сөендерәм. *(1 балл.)*

5. Кибеттә күптән эзләгән әйберегезне таптыгыз, ди. Ләкин ул соңгысы һәм аны башка берәү алырга кызыга. Сез нишләр идегез? Теге кешегә юл куям, үземә башка әйбер карармын. *(1 балл.)* Бик кирәк дип тапсам, ничек тә бирмәскә тырышам. Ул кеше икенче җирдән эзләсен. *(0 балл.)*

6. Туктап, юл буенда кул күтәреп торучы таныш түгел кешене утыртыр идегезме? Әлбәттә, моның бер авырлыгы да юк. *(1 балл.)* Утыртмыйм, аның уенда ни икәнен белмим бит. *(0 балл.)*

7. Заказ бирүченең түләргә акчасы юклыгын белсәгез, заказны арзанга гына башкара алыр идегезме? Юк, ризалашмыйм, эш өчен тиешле күләмдә түләнергә тиеш. *(0 балл.)* Әйе, ризалашам. Савап дигән әйбер дә бар бит әле дөньяда. *(1 балл.)*

8. Хәер соранып торучы бала яныннан тыныч кына узып китә аласызмы? Әйе, хәер сорану аларның кәсебе дип беләм. *(0 балл.)* Ничек тә булышырга тырышам. *(1 балл.)*

9. Кемгәдер өегездәге берәр әйбер бик ошаса, аны бүләк итә аласызмы? Үземә дә бик кадерле әйбер булса, бүләк итмим. *(0 балл.)* Әгәр чынлап та бик ошатса, бүләк итәм. *(1 балл.)*

10. Компаньонызыгыз өчен кафеда үзегез түлисезме яки һәркем үзе өчен үзе түләргә тиешме? Сумма артык зур булмаса, үзем түлим. *(1 балл.)* Һәркем үзе өчен үзе түли. *(0 балл.)*

Балларны саныйбыз:

0–5 балл. Үзегез өчен файда күрмәсәгез, сез кемгәдер булышырга атлыгып тормыйсыз. Бәлки, элегрәк сезнең юмартлыктан бик нык файдаланучылар булгандыр, шуңа кешеләргә ышанычыгыз югалгандыр. Иң якыннарыгызга гына булса да юмартлык күрсәтегез, алар моны бәяләп, үзләре дә шулай җавап бирәчәк.

5–8 балл. Сезне һич тә саран кеше дип әйтеп булмый. Сорасалар, мөмкинлеккә карап, һәрвакыт ярдәмгә килергә әзерсез. Шулай да ярдәм итәм дип, бар эшегезне ташлап йөгермисез. Якыннарыгыз өчен сез юмарт кеше. Үзегезне алдатырга һәм файдалануларына ирек бирмисез.

8–10 балл. Сезгә үтә дә юмартлык хас – һәрвакыт һәм һәркемгә ярдәм кулын сузасыз. Әлбәттә, бу бик яхшы сыйфат, сезгә һәрчак таянырга була, ләкин үзегез турында да онытмагыз. Чаманы югалтмагыз, башкаларның ихтыяҗын үтим дип йөреп, алар тормышын яшәп, алар теләгән үти башлавыгызны тоймый да калырга мөмкин.

йолдызнамә декабрь

Кучкар. Вак нәрсәләргә игътибар итеп, мөһимен күз уңыннан ычкындыруыгыз бар. Декабрь – идеяләрне тормышка ашыру артыннан чаба торган вакыт түгел. Сыналган алымнар белән генә эш итегез һәм ашыкмагыз.

Үгезбозау. Үз фикерегез никадәр генә дөрес булып тоелса да, башкаларга белдерүдән тыелып торыгыз. Сезнең үҗәтлекне агрессия дип бәяләүләре бар. Гомумән алганда, уңышлы һәм тотрыклы ай.

Игезәкләр. Гадәти булмаганча фикерләү сәләтегез һөнәри өлкәдә абруегызны күтәрергә ярдәм итәр. Нинди генә үзгәреш булса да, ахыры яхшы тәмамланачак. Дөрес юнәлешне язмыш үзе күрсәтә.

Кысла. Гаиләгезгә күбрәк игътибар бирегез. Өстегезгә зур җаваплылык алырга туры килүе мөмкин. Бу, башлыча, эш белән бәйле. Командировка тәкъдим итсәләр, баш тартмагыз, ул сезнең өчен файдалы булачак.

Арыслан. Үзгәрешләрдән курыкмагыз, алар уңыш китерәчәк. Акчалар белән саграк эш итегез, төрле афёралардан ерак торыгыз. Карьерагыз үсешенә ныграк игътибар итегез, җитәкчелеккә үзегез турында ешрак белгертегез.

Сөмбелә. Хезмәттәшләрегез белән аңлашылмаучылык килеп чыгуы бар. Ашыгыч карарлар кабул итмәгез. Бюджетыгызны бик уйлап планлаштырыгыз, «иминлек мендәре» турында кайгыртыгыз. Эшегезнең нәтиҗәләрен бәяләр вакыт.

Бизмән. Язмыш сезгә күңелле сюрпризлар әзерли. Тормышыгызны баштанаяк үзгәртердәй вакыйга көтелә, бу яшәү урынын алмаштыру белән бәйле булырга мөмкин. Мөһим карарларны яңа елга кадәр кабул итегез.

Чаян. Эшлекле өлкәдә зур уңыш көтелә. Ләкин ныклап уйланылмаган адым ясаудан тыелыгыз, очраклы билгеләргә игътибарлы булыгыз. Ай ахырына таба акча һәм партнерлар мәсьәләсендә аеруча сак булу сорала.

Укчы. Үткәннәр үзен сиздерергә мөмкин. Хыялларга бирелә торган чор түгел, югыйсә күп нәрсәне югалтырга мөмкинсез. Юл белән бәйле эшләр уңышлы булачак.

Кәҗәмөгез. Тотрыклылык һәм җан тынычлыгы – бу ай сезгә әнә шуларны әзерли. Салкын акыл күп кенә нәрсәләрдә ярдәмгә килер. Яңа тәкъдимнәрдән баш тартмагыз, ул финанс мөмкинлекләренә юл ачачак.

Сукояр. Идеаллардан баш тартырга туры килер. Кыю проектларга алынсагыз, отарсыз. Үз-үзегезгә күбрәк ышаныгыз, уңышка ирешү өчен бу бик мөһим. Эш өлкәсендә һәм акча мәсьәләсендә алга китеш көтелә.

Балык. Эштә яки гаиләдә бераз ыгы-зыгы килеп чыгуы бар. Шактый борчылырга туры килсә дә, бар да җайланачак. Үз сүзегездә нык торудан курыкмагыз, уңыш сезнең якта. Күбрәк ял итәргә, үзегезне кайгыртырга тырышыгыз.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА, Алсу ШАКИРОВА әзерләде.







КИНДЕРДӘ – ЧЕЛТӘР БӘЙЛӘМНӘРЕ

Аделаида Исламова: «Һөнәрем буенча рәссам буласым туганда ук язмышыма язылган булгандыр!» – ди. Бу кararга килүендә аның әнисе Фәния һәм әтисе Фәрһад Исламовларның да талантлы рәссамнар булуы йогынты ясамый калмагандыр.

Аделаида 1990 елда Казакъстанның Караганда шәһәрендә туган. Балалар сынлы сәнгать мәктәбендә укыган. Балалар музыка мәктәбендә скрипка һәм саксофон классларында белем алган, ул әле фортепианода да яхшы уйный! 18 яшендә Татарстанга килеп, Казан дәүләт федераль университетының сәнгать һәм дизайн факультетында укый башлаган. Университетта аны актив, зур уңышларга ирешкән студент буларак әле дә хәтерлиләр. Хәзерге көндә рәссам ханым үз гаиләсе белән Черногориядә гомер итә.



«Бирегә без быел, яз аенда күчендек. Ихлас хыяллар тормышка аша! Моннан берничә ел элек, әле балаларыбыз туганчы ук, Ренат белән шушы ил буенча сәяхәт иткән идек, – ди Аделаида. – Шулчак мондагы ямьгә, гүзәллеккә исебез китте! Искиткеч матур ил! Рәссам өчен дә төпсез илһам коесы! Шул вакыт мин ярымҗимерек пристань янәшәсендәге югарылыктагы бердәнбер йортка игътибар иттем һәм аның аша тыйнак образ барлап, әлеге күренешкә гашыйк булдым. Бу йорт эпик таулар, кипарислы, наратлы куе парк фонында Тиват ярыннан бик яхшы күренә, анда кайчандыр Австрия–Венгрия хәрби базасы урнашкан булган, ахрысы. Ә менә куәтле фантазияләремдә исә ул минем хыялым йортына әверелде. Шулай итеп, «Хыял йорты» дигән картинамны иҗат иттем. Әлеге әсәр – Черногория хакындагы серияләремнең башлангычы, аннары инде «Петровацтагы йорт», «Будва – иске кала», «Будва бухтасы төне», «Котор күренеше» әсәрләре дә язылды. Шушы сериямне алдагы көннәрдә дә дәвам итәргә җыенам».

Аделаиданың Черногориядәге тагын бер иҗади темасы песиләр белән бәйле. Бирегә хуҗасыз хайваннар аз икән, ә булганнары арасында песиләр – иң күбе, шуңа да ул аларны сурәтли дә башлаган. Аннары гомере буе гел мәчеләр генә ясаган Бөекбритания рәссамы Луис Уйэнны да искә төшергән.

Аделаида Фәрһад кызының кызыклы иҗаты күпләргә мәгълүм. 2019 елда ул үз картиналары белән Луврда узган Халыкара яшь рәссамнар күргәзмәсендә дә катнаша. Мәскәүдә оештырылган «Яшьләр-2021» күмәк күргәзмәсенә аның хезмәтләре дә сайлана. Моннан кала, талант иясе кул эшләнмәләре остасы буларак та таныла, иҗат иткән интерьер уенчыклары дөньяның күп илләрендәге шәхси тупланмаларда саклана.

Аделаиданың берсеннән-берсе матур картиналарындагы сурәтләр әйтерсең лә төрле төстәге бихисап нечкә сызыклар-җепләрдән үрелгән. Бу плентанизм – үрү ысулы... Рәссам аларны шушы аталыштагы ысулда, яктылыктөс гаммасын ассызыклап иҗат иткәч, киндерләрдә челтәрдәй бәйләмнәр хасил була. Аның үзенчәлекле картиналарын тамашачылар озаклап карарга ярата. Яшь рәссамыбыз Аделаида Исламова алдагы елларда безне башка серияләре, башка ысуллардагы яңа әсәрләре белән дә сокландырыр әле, чөнки аңа, таланттан кала, гаять тырышлык, ихтыяр көче, оптимистик рух та хас!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА


АДЕЛАИДА ИСЛАМОВА

PRESSA



КУЛАЙ БӘЯДӘН КАБАТЛАНМАС ЗӘРКӘН

Казан, Р. Зорге ур., 67; Бутлеров ур., 29; Чистай ур., 15/16; Восстание ур., 62.
exclusive.kazan www.exclusive-jewelry.ru РЕКЛАМА

